# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

## ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ

Повесть

I

Бер атна эчендә кызга ике яучы килде. Беренчесен Нурый карт ошатмады, җиңел бер сылтау белән кире кайтарды:

— Бик мәшәкатьле чагым, — диде, — менә хәзер өй кузгатырга торам, җир-урман алдым; быел туй ясаулар турында уйларга чамабыз килмәстер, — диде.

Икенчесе Бикьярдан, Шибай кантуннан[1] иде. Бусы күңеленә бик ятты, каршы әйтергә сүз тапмады, моны башкодадан да яшерә алмады:

— Үзең дә зур, сине җибәргән кеше дә зур... Аптырабрак калдым: быел андый өлкән эшләргә кул сала алмабыздыр дигән идек; җиңел генә кире сугарга көчем җитми, хәзергә өзеп әйтә алмыйм, анасы белән сөйләшик, кардәш-ыруга да киңәш итим, — диде. Үзе тел төбеннән кызын бирергә теләвен бик аңлатты. Ләкин һичкем белән киңәшмәде, ике тәүлек буена уйланды да, өченче көнгә чыккач, иртәнге чәйдән соң хатыны Фәтхиягә әйтте:

— Анасы, — диде, — кодалар акча белән килерләр. Аш-су әзерләргә кирәк, — диде.

Ананың йөрәге урыныннан кузгалды, тезләре калтырый башлады, коты очып, иренең күзләренә карады, куркып сорады:

— Бу нинди сүз? Нинди кодалар ул? Нурый бер сүз белән бетерде:

— Гөлбануны бирәбез, зур җиргә катнашабыз, берүк адәм алдында оятка калырлык булмасын, аш-суыңны карап әзерлә!

Картның йортында башланган хәзерлекләр белән бергә Гөлбануның бирелү хәбәре тиз арада күршеләргә иреште, аннан чыгып, өйдән өйгә, урамнан урамга китте, кичкә каршы, бөтен Караюрганы әйләнеп, зураеп, гайбәтләр дә кушылып, кызның үзенә дә килеп җитте. Моңардан аның эченә ут кабынган кебек булды, кая басканын, ни эшләвен онытты, бер өйгә керде, анда үзенә урын тапмыйча, яңадан тышка чыкты; шулай, үзен кая куярга белми әйләнгәләгәндә, су беткәне күзенә чалынды; бу яхшы сылтау иде; әнкәсеннән сорап, тиз-тиз киенде-ясанды, битләренә кершән якты, иннек сөртте, күзенә бик аз гына сөрмә тартты да, калын шәлен ябынып, көянтә-чиләген күтәреп, күрше җиңгәсе Мәфтухага керде.

Җиңгәсенең үз эше башыннан ашкан иде, хәзер генә суның кирәге дә юк иде, шулай да кире кайтара алмады, бер карау белән кызның күзендәге, дерелдәгән

[1] *Кантун* — патша заманындагы Башкортстанда кечерәк бер территориянең сайланып куелган түрәсе.

тавышындагы куркуны сизде:
— Хәзер, җаным, — дип, ашыгыч-ашыгыч аягына киез ката, өстенә сырган бишмәт киде дә, әле бозлары эреп тә бетмәгән чиләгенең суларын чапчакка[1] бушатып, Гөлбану белән коега барырга чыкты.
Зур урамнан тыкрыкка борылу белән, кыз бер-ике сүз әйтте дә үз тавышына үзе буылып елап җибәрде. Коега барып җиткәнче дә, анда кар-боз эчендә катып утырган коеның сиртмәләрен шыгырдата-шыгырдата су чыгарганда да, өйгә кайтканда да Гөлбану, үзенең кайгысын сөйләп, туктамый елады, аерылганда, яңадан кабатлап:
— Җиңгәм җаным, бүгеннән калмый күр; ничек кенә. булса да күр, картлар йоклагач та, бакча ашасыннан, көрт буйлап уң як тәрәзәгә килсен, мин көтәрмен, — диде. Үзе эченнән: «Асып куймаслар әле, бер рәнҗерләр, бер каргарлар да бер туктарлар», — дип уйланып, үзенең сөйгән егете Лотфыйга ябышып чыгарга күңелен беркетте. Шул кискен уй белән, тулы чиләкләрен күтәреп, үзенең туе хәзерләнгән өйгә кайтты.

II

Кышның кыска көне кызга бик озын тоелды. Караңгы төшеп, кич булгач, атасы белән анасының чәй эчүләре гаҗәп озак сузылган кебек булды. Сәкедән чынаякларны җыеп алгач, Фәтхия карчык тагы әллә нинди сөлгеләр, ашъяулыклар турында сүз кузгатып, баш әйләндереп бетерде. Болардан котылуга, Гөлбану әткәләренең теге якка кереп ятуларын гына көтте дә үз тәрәзәсенә, пәрдәдән урам якка таба күрсәтеп, нечкә кызыл тасма асты, чигә торган кулъяулыгын алды да ялгызы тәрәзә алдына эшкә утырды.
Бүген көн әйбәт кебек иде. Көндез кояш чыкты, кар өсләре бик матур булып ялтырап яттылар. Тик менә кичкә таба гына әзрәк җил күтәрелде, кечкенә кисәкле йомшак ак мамыклар кебек кар ява башлады, аннан буран күтәрелде; хәзер инде каты җил бертуктаусыз кар белән уйный, аны туздыра, өйләргә, азбарларга, кибәннәргә китереп сылый, өя башлады. Кыз ялгызы бераз куркынып утырды, тәрәзәнең бернәрсә күренмәслек булып туңып китүе дә аны борчыды, бу һәммә нәрсәне каплап, морҗалар арасында сызгырып уйнаган каты буран эчендә яңлышып башка тәрәзәгә бара күрмәсен дип тә тынычсызланды.
Шулай көтә-көтә ярты төн үтте; җил-буран басылды, мамык яфраклар кебек йомшак эре кар яварга тотынды, ләкин егет килмәде. Беренче әтәч кычкырды — һаман килмәде, икенче әтәч кычкырды — һаман килмәде, инде менә өченче әтәч кычкырды — һаман килми дә килми. Бу ни хәл? Җиңги күрә алмадымы?

[1] *Чапчак* – су тутыру өчен зур кисмәк.

Әллә тәрәзәмне саклыйлармы икән, шуңар күрә килә алмый йөриме икән? Берсенә дә җавап булмады, кыз утлы-ялкынлы тойгылар эчендә төнне үткәрде, ак таңны күз йоммыйча, бер тамчы йокламыйча каршы алды. Эшләргә дип алып утырган чигү-каюларына кул да тидерә алмады.

Иртән торганда да, бергәләп чәй эчкәндә дә ата-анасының күзләренә карамаска тырышты, сүзгә дә катнашмады. Нурый картның, актык чынаягын каплап, дога кылып, йортка чыгып киткәнен көтте дә:

— Әнкәй, кичә ал җепләремне матур җиңгиләрдә калдырганмын, шуларны гына барып алып кайтыйм, — дип, анасыннан сорады.

Фәтхия каршы әйтмәде, аның үз башы хәсрәт белән тулы иде, күп сөйләшсә, түзми елап җибәрүдән курка иде. Күтәрелеп карамый гына җавап бирде:

— Бар барсаң, тиз генә барып кайт. Озак йөрмә: һаман өйдә юк дип атаң тирги башлар... — диде.

Гөлбану аягына пима, өстенә калын бишмәт киде, башына үзе бәйләгән ак мамык шәлен ябынды да җиңгәсенә барырга йортка чыкты.

Ләкин тиз ычкына алмады.

Анда, бөтен юлларны, азбар буйларын каплап киткән кар эчендә, үз алдына кычкырып, сукранып, Нурый карт йөри. Ялчыларның берсе киң агач көрәк белән сукмаклар сала. Икенчесе зур бер ак сарыкны кечкенә азбарның тар ишегеннән куып кертергә маташа. Хуҗа ачуланып аңа кычкырды, сарык, яңадан ычкынып, урам капкага таба акырып йөгерде.

Ялчылар кичә ындырдан азбарга чана белән печән ташыдылар. Актык китергәннәрен бушатып, малларны карап, үзләре ашап-эчеп ятканчы ярты төн җитә язды, икесе дә эштән чыгып арганнар иде. Аш өенең сәндерәсенә сузылу белән үлек кебек йоклап киттеләр. Башка вакыт берничә тапкыр, алмашып, азбарга карарга чыгалар, сыер бозауласа, сарыклар бәрәнләсә, туңмасын дип өйгә кертәләр иде. Бүген, үкенечкә каршы, бик ару аркасында, уяна алмадылар, карарга чыкмадылар; өч сарык бәрәнләгән, яңа бәрәннәрнең берсе иртәнгәчә туңып үлгән. Нурыйның һәммә кешегә ачуланып, йорт буенча тиргәнеп йөрүе менә шуннан иде. Гөлбану күренүгә, ул моңа да кычкырды:

— Кызым, анаңа әйт, мал суя торган пычакны казан читенә ышкып бирсен, — диде.

Гөлбану, мондый бәхетсезлеккә очраганга әрнеп, кире керде, анасыннан зур пычакны кайратып алды да атасына илтеп бирде. Бу вакыт инде теге үлгән бәрәне өчен әле анда, әле монда чабып бакырып йөргән зур ак ана сарыкны кечкенә азбарга кертеп япканнар иде; карт, җиңен сызганып, үлгән бәрәннең тиресен тунарга хәзерләнә иде, кызыннан пычакны алды, йөзен карады да

эшенә тотынды. Гөлбану тиз-тиз атасы янында китү ягын карады.
Матур җиңгәләренең йорты янәшә, ике арада кечкенә ишек кебек кенә капка да бар. Туктаусыз яуган кар мондагы сукмакны күмеп киткән. Кыз, озын кунычлы пимасы белән йомшак карны ерып, күрше йортка чыкты да урамга буй дүрт почмаклы, салам түбәле өйнең ишегенә таба йөгерде. Ахрысы тәрәзәдән күреп калгандыр, хуҗа хатын үзе атлыгып Гөлбануга каршы ишек ачты да, өйгә алып кермичә, кире:
— Анда гайбәтче карчык утыра, әйдә монда, — дип, келәткә таба тартты, тавышын акрынайтып, ашыгып әйтте: — Гөлкәем, син миннән күрә күрмә! Бардым, эш харап бит, — диде дә ни булганын сөйләп бирде.

III

— Бардым, гөлкәем, бардым. Туры кибетенә кердем. Беләсең аның шаркылдык ярты акыл җиңгәсен: мине күрүгә, шул ахылдап килеп чыкты. Ни булды? дим. Сорама инде, сорама, ди, урта бармак кебек, ялгыз үскән яшь нарат кебек егет иде, әрәм генә булмаса ярар иде, хәле бигрәк авыр, ди. Нәрсә бар, иплэп әйт, дим. Җә, ди, (яшерәсе юк, синең нигә йөргәнеңне беләм ич, әйдә үзең кереп күр, ди. Мине өстерәп кибет аша эчке өйләренә алып керде. Керсәм, гөлкәйгенәм, һушым-акылым китә язды, әйтерсең кабыгы суелган калын бүрәнә, Лотфыйның уң аягы менә шулай булып шешеп ята. Үзе ыңгыраша. Ни булды, бу нихәл, дим. Авызы, теле кибә икән; тәнем ут кебек яна, ди; чынаяк чокырыннан су эчеп, иреннәрен юешләтте дә ни булганын әйтеп салды:
— Менә, җиңги, ди, синнән яшергәнне эт ашасын, ди, күңелемдә ни булса, телемдә шул, ди. Мин, ди, менә Гөлбануны алырга дип әзерләнеп йөргәндә, шулай харап булдым бит, ди. Менә, ди, туганым җиңги, ди, абзый да белә, алардан минем яшерен серем юк, көзгә туй итәрмен, яшь кәләшне төшерергә аерым яңа өй булсын дип уйладым. Шуңа дип боярдан урман алдым, үзем карап кистердем, быел кыш ташып куеп, җәй буе кипкәч, көзгә буратмакчы идем. Абзый әйтеп калды: үзләре ташырлар, син нигә анда азапланып йөрисең, монда кибеттә дә кеше юк, диде. Күрәсем баргадыр — йөрәгем ашкынды, көн бик әйбәт иде, уйнап-шаярып, зур калын озын бүрәнәләрне салып бәйләдек тә, ат чаптырып, кайтырга чыктык. Текә таш бармы? Шуннан төшеп килгәндә, атымның бавыргалыгы[1] өзелде. Ул, түбән таба чананы тыя алмыйча, алдагы ат өстенә барып менде. Минем чана түбән таба салулап китте дә аның бүрәнәсенә мине китереп кысты, ди. Мин һушымнан язганмын, бер атның бүрәнәсен ташлатып, мине чанага салып алып кайттылар, ди; сынганмы, чыкканмы — әле

[1] *Бавыргалык* – җигелгән атның корсагы астыннан үтеп, бер тәртәдән икенче тәртәгә бәйләп куела торган каеш.

белгән юк, менә шулай бакырып ятам, ди...

Гөлбану бөтен бу газаплы эшләрне үз тәненнән, үз күңеленнән кичерде, әрнеп, җиңгәсен бүлде:

— Ходаем, нигә соң инде моңарчы останы чакырмыйлар? Харап бит бу... — диде.

Матур җиңги тагы алып китте:

— Чакыртмаган кая. Шул сәгатьтә үк Зариф остага ат белән чапканнар. Гөнаһ шомлык бит, бер кире китсә китә ул, өйдә юк, ди, зур улына кәләш алганнар икән, кич кенә шуның туена киткән, ди. Аннан тагы Карамалы остага чапканнар, бер кире китсә китә бит, гөнаһ шомлык: бу да өендә юк, ди, калада берәүнең кулымы, аягымы чыккан икән, ди, шуны духтырлар төшерә алмагач, Карамалы остасын алдыртканнар, ди; инде менә хәзер көненә ничә белешеп, боларның кайтканнарын көтәләр...

Салкын һавада нык өшүләренә карамастан, өйгә, гайбәтче карчык янына керергә теләмәделәр; сүз, сизелмәстән, Гөлбанудан җиңгигә күчте; ул, күзләрен сөртеп, тагы алып китте:

— Шулай икән, гөлкәем, хатын башына бер бәхет күләгәсе тими икән, менә минеке дә бу арада юк-бар сүз белән бик теңкәмә тиеп йөдәтә башлады. Тапкан бер сүз, Ходай бала бирми, ди, нәселебез корый, ди, ат дүрткә тулса, сарык егермегә җитсә, чәчкән игенем ун дисәтинәдән артса, Аллага тапшырып, икенче хатын алырмын дигән идем, мин дигәнне Ходай артыгы белән бирде, инде ни эшлибез, ди дә тора бит...

Хатын үз тормышының бу авыр кайгысын, ярым елап, ярым каргап, кайта-кайта сөйләде; башына төшкән бу хәсрәттән ничек котылырга аптыравын әрнеп кабатлады.

Ул ирен күрми, белми барды. Кавышкач, зөфафның[1] беренче көненнән үк, бөтен йөрәге белән аңар бирелде, аны яратып, сөеп китте. Бик сөешеп өч ел гомер иттеләр, бәхетләре елдан-ел үсә барды, ләкин аларның якты көннәре өстенә бер кара болыт килеп капланды, һичнәрсә шуны тарата алмады: хатынның баласы булмады. Баштагы өч елда моны ничектер уйламадылар, дүртенче, бишенче елларда хатын үзе эченнән көенде, Алладан елап сорады, им-том итүче, сихерләүче, сихер кайтаручы, күрәзәлек кылучы, өшкерүче-төкерүче карчыкларның берсен дә калдырмады, һәммәсеннән шифа эзләде. Ләкин берсе дә ярдәм бирмәде, ире һаман шаяртыбрак булса да әйтә башлады; менә кичә инде бөтенләй өзеп сөйләде:

---

[1] *Зөфаф* (кичәсе) — кияү белән кәләш кушылган төн.

— Җә, хатын, — ди, — сиңа сүзем бар. Җиде ел сабыр иттем бит: ат та, иген дә, сарык та миң әйткәнне узып китте, болай миңа синнән башка хатын кирәге юк, баласызлык харап итә бит; инде ни эшлик, мин кайтканчы уйлап куй, — диде дә, бер йөк арыш төяп, тегермәнгә китте.

Гөлбану бу турыдагы сүзләрне тыңлады, ләкин аңламады; бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыга тордылар. Киленнең кайгылы хикәясе бетәр-бетмәс, ул үзенең хәсрәтенә кайтты:

— Җиңгәкәем, мине ни эшләтерләр инде? — диде дә сүзен бетерә алмады, күз яшенә капланып, кире үзләренә йөгерде; ике арадагы читәнгә җиткәч, йомышы исенә төшеп, яшьле күзләрен җиң белән, итәк белән сөртә-сөртә: — Миң ул карчык янына елаган күз белән керәсем килми. Минем чигү җепләремне чыгарып бир, — диде.

Хатын, өйгә кереп, кызның сораганын алды. Гөлбану, ал җепләрен җиң эченә тыгып, өенә китте.

Аның башын караңгылык каплады. Йөрәге, ниндидер авырлык белән кысылып, кайгы дулкыны күкрәгеннән бугазына таба омтылды, еламаска тырышты, ләкин көче җитмәде; ул кайтып кергәндә әнкәсе Фәтхия сәке буенда ялгызы ниндидер сөлгеләр, чигүле намазлыклар, чолгаулар актарып тора иде, кыз башкача әйтергә сүз тапмады, аны уйлап та тора алмады:

— Әнкәем, бирмәгез аңа... — диде дә, үксеп елап, анасының күкрәгенә ташланды.

Ана йөрәге мондый бер хәлнең булуын алдан ук сизенгән иде, Гөлбануга бертөрле дә юаныч әйтә белмәде, киресенчә, үзе йомшарды, күзләренә яше килде:

— Бәгырем, балам, ни генә эшлим соң?! Атаң бит! Мин үзем дә белми калдым, ни генә кылыйм соң, бәгырем, балам! — диде. Кызын күкрәгенә алып кысты.

Шул арада тыштан аяк тавышы килде, Гөлбану сикереп торды, ишектән кергән атасына, күз яшьләрен аз гына да яшермичә, елаган күзләре белән батып карады да, җиңе белән битен сөртә-сөртә, аш өенә таба чыгып китте.

Монда өйдә ата белән ана арасында бу турыда беренче тапкыр озаклап сөйләшү барды.

IV

Нурый карт үзенең озын гомерендә җиде хатын алды. Боларның берсе, ел ярым гына торгач, баладан үлде. Икенчесен, күзләрен ирләрдән ала алмый, уйнашчы бер нәрсә булыр бу дип . аерып җибәрде. Өченчесе, көндәш көне — эт көне дип, талашып, сугышып, барлык бирнәсен, мәһәрен ташлап, үзе качты. Арада берсе уңган, үткен, ләкин яман телле иде. Карт берне әйткәнче ул унны өлгертә

иде. Нурыйның ирлек тамыры кузгалды, бу кәнтәйне өйрәтим әле мин дип, эт урынына кыйнады, күкрәгенә менеп аягы белән таптады да кышкы суыкта, күлмәкчән көйгә карга чыгарып ыргытты; шуннан хатын авырып китте, җүтәлләде, яз көне, карлар эреп, елгалар ташкан чакта гүр иясе булды. Шулай аның алты хатыны төрлесе төрлечә таралып беттеләр, арада иң түземлесе Фәтхия булып чыкты. Бөтен утыз еллык каты тормышны башыннан кичереп, тик ялгыз ул гына калды. Ләкин аның да Алладан, язмыштан, иреннән куркып, кырыкка телгәләнеп беткән йөрәге, иң аз җилләргә дә селкенергә әзер торган усак яфрагы кебек, иң кечкенә кайгы дулкыннарына да каршы тора алмас дәрәҗәдә таушалган иде инде.

Шулай да кызы белән елашып, сөйләшеп үткәч, чыдамады, гадәттән тыш зур бер батырлык күрсәтте. Гөлбану яшен сөртә-сөртә аш өенә чыгып китү белән, Фәтхия иренең күзләренә кыю карап әйтте:

— Ходаем, миңа гына түгел, синә да бала ич! Нигә әз генә дә кызгана белмисең?! Иртә-кич өзгәләнә бит. Җә аңа бер нәрсә эшләтермен, җә үземне суга ташлармын, бирмәгез мине... ди. Әллә әзрәк сабыр итәсеңме? Алган акчаны кире кайтару илдә юк эш түгел бит!?

Карт үзенең хатынына ачу катнаш кызгану белән, мыскыл белән карады:

— Син, карчык, юкны сөйләнеп баш катырасың! Утыз ел тукыдым, бер мыскал да акыл кермәде үзеңә! Имеш, елый! Еламыйча кем кияүгә бара!? Борынгыдан килгән йола инде. Менә үзең еламадыңмы? Без кемнән ким гомер иттек? Аллага шөкер булсын, ничаклы дәүләт ясадык, ничә бала үстердек! Насыйп булса, менә хәзер инде төпчегебезне кияүгә бирергә торабыз... Бу бәхетләр һәркемгә насыйп була алмый ул...

Карчык ни дияргә дә белмәде. Каршы әйтергә сүз тапмады. Дәүләт ясаулары дөрес, бала үстерүләре дә дөрес, утыз ел бергә гомер итүләре дә дөрес. Ләкин бәхет дигәне ничектер, аны белеп булмый. Карчык үз янында, үз йөрәгендә бу сүзнең мәгънәсен тапмады. Үзе аңламыйча ук, бөтенләй икенче яктан китереп, тел ачты:

— Анысы алай да бит, атасы, елауның елавы бар шул. Ул төпчек булып, иркә үсте. Азрак үзсүзлелеге дә бар. Берәр нәрсә кылып ташламагае иде дип куркам мин, — диде. Тагы өстәде: — Егетен белмим, нинди нәрсәдер? Әмма безгә кодагый булачак, Гөлбануга каенана булачак Сабираны бик беләм. Аны исеме белән атамыйлар, Әремтел дип, Әремтел Сабира дип йөртәләр. Мин менә шунысыннан куркам. Гөлбану бит шул йортка төшәр, шул аждаһаның кул астында гомер итәр... Мин менә шуннан куркам... Әле бирү хәбәре таралып җитмәде, хатын-кыз арасында сүз китте инде, очраган берсе әйтә: урта бармак

кебек кыз үстердең, инде терeлəй тəмуг утына салырга итəсең икəн, əллə кияү чыкмас дип курыктыгызмы, дилəр... Атасы, əллə бераз сабыр итикме? Кызыбыз картаеп бармый бит, менə синтəбердə генə уналты тулып, унҗидегə чыкты... Быел йорт-җир мəшəкате дə күп...
Карчыкның сүзе шулай акты да акты. Лəкин ул үзенең йөрəк төбендə яткан соңгы серен иренə əйтергə телəмəде.
Кыз ничаклы яшереп маташса да, ана сизə иде, баласының күңеле кая таба, кемгə таба барганын күреп тора иде. Ул башта моңа аптырап карады, азып-тузып китмəсен, яман телгə элəкмəсен, аты-чабы чыга күрмəсен, Ходаем, дип борчылды. Гөлбану аулак өйлəргə барырга сораганда, бик сайлап кына, кешесенə карап кына җибəрə торган булды. Яз көне, елга буена, чирəмгə киндер агартырга барган чакларда, кичлəрен кер тукмарга йөргəн вакытларда, каз өмəсенə, урак, печəн өмəлəренə чакырылганда, җəй көне тауга, яланга чыкканда, суга киткəндə, сабан туйлары булганда ананың йөрəге бер дə тыныч кала алмады, үзе бик белгəн, бик ышанган кызлар белəн генə җибəрергə тырышты: бергə бар, бергə кайт, берүк аерылма дип, колагына кат-кат тукып торды, йөргəн егете бар , имеш, дигəн сүзне беренче тапкыр ишеткəндə, ана коелып төште, харап булдым бугай, дип хафаланды. Лəкин егетнең кем икəнен белгəч, бераз гына җан керде, үз эченнəн: «Ярамаслык түгел, төсе, буе бар, байлыгы бар», — дип, тəкъдирдə язылган булса, яучы килсə, бирү ягын тотарга уйлап куйды. Ананың күңеленə аеруча ошаган тагы бер əйбер бар иде: егет ялгыз, анасы күптəн үлгəн, каенана дигəнең бер дə булмас. Үземнең киленем яман, кызымның каенанасы яман, дилəр; ничаклы əйтсəң дə, каенана каенана була инде. Егетнең ялгызлыгы — Фəтхия əби өчен аерым бер зур бəхет иде. Мəфтуха килен читлəтеп сөйлəнеп тə йөри, шул егетне мактап телгə ала. Менə бу кышны үткəрсəлəр, алдагы көзгə, бəлки, Аллага тапшырыр идек...
Бу уйлар карчыкның дөньяда һичкемгə əйтмəгəн, əйтми торган эчке серлəре иде. Карты белəн сөйлəшкəндə эшнең менə бу яклары да аның күңеленə килə торды. Лəкин бу хакта иренə бер сүз дə əйтмəде, əйтүне зыянлы тапты. Нурый картның башына нык кереп утырган бер караш бар, ул əйтə: «Сөеп алган, сөеп барган бəхетсез була, — ди. — Алла ни язган булса, тəкъдирендə кем булса, шуңа барырга кирəк», — ди.
Əгəр кызының егет белəн йөргəнен белə калса, иң элек Фəтхия карчыкның үз өстенə буран күтəрелер: «Ана булып, кыз үстерүең шулай икəн?!» — дияр дə хатынын эштəн чыгарып кыйнап ташлар. Аннан инде ул егеткə бирергə башы-аягы белəн каршы килер. Ана боларның һəммəсен алдан күрде, кызның мəхəббəте кебек əйберлəр турында авыз ачмады, бөтен эшне үзенə якын яктан,

каенана ягыннан, әрем тел, гыйфрит, аждаһа ягыннан уратып китерде.
Бу турыдагы сүзләр бер көндә, бер төндә генә бетмәде. Ир белән хатын аулак калган саен моңа әле киңәшеп, әле әрләшеп, һаман яңадан-яңа кайта тордылар. Акча алынды, мәһәр килешенде, шимбә көн туйга килергә дип, бу яктан өндәүләр барып кайтты. Туйга ничә чана, ничә кеше киләчәге билгеләнде. Шәрип ахунның шимбәгә никахка вәгъдәсе алынды. Ләкин ана һаман тынычланып бетәргә үзендә көч таба алмады, һаман да, бер яктан, кызының яшеренеп-яшеренеп елауларыннан йөрәге кысылса, җаны әрнесә, икенче яктан, һәрбер уңайда ире белән әрләшә бирде. Арага улларын да кертте, алар белән киңәшеп карады, ләкин болар бер сүз дә, бер ярдәм дә итә алмадылар, ул хакта аталарына каршы авыз ачарга берсенең дә батырлыгы җитмәде. Санаулы көннәр үтте дә, Фәтхия әби, ахыр килеп, җиңелде: «Инде Алланың үзенә тапшырдым. Тәкъдирдән узып кая барасың? Ходайның язганы шулдыр», — дип, үзенең киреләнүләреннән туктады. «Илаһым хуҗам, үзең хәерен насыйб ит, бәхет бир, мәхәббәт бир», — дип дога кылуга бирелде. Шул догалар, шул туй хәзерлекләре эчендә шимбә көнне каршы алды.

V

Таңнан башлаган кар туктамады, яуды да яуды. Җир йөзе йомшак аклык белән капланды. Киң яланнар, биек таулар, урманнар, болыннар — һәммәсе карның үзенә бер яңа матурлыгы белән түшәлеп агардылар. Агачларның ботаклары яңа, йомшак ак мамыкларга төренделәр, калын-калын ак мендәрләр кебек, үз авырлыкларын үзләре күтәрә алмый түбәнгә таба салына башладылар. Зур елгалар әллә кая, төпкә, боз астына качтылар. Юллар, сукмаклар югалдылар. Өйләрнең, азбарларның, ындырларга тезелгән кибәннәрнең түбәләре — һәммәсе карга күмелделәр.
Нурыйның ялчы малае — озын буйлы, ябык, яшүсмер Мифтах, — өй йомышларыннан бушамады, аны әле Фәтхия әби, әле Мәфтуха килен бертуктаусыз йөгертә тордылар. Зур ялчы Минһаҗ, колаклар туңмасын дип, бүрекне басты, чабата бавын ныгытты, тышсыз иске тун өстеннән билбауны кысып бәйләде, күн эченнән җылы бияләйләрне киде дә, киң агач көрәкне алып, туй килгәнче тизрәк капкаларны, юлларны көрәргә чыкты. Ул, үзалдына шаярып:
— Их, Гөлбану касмак яраткан икән! Туе нинди буранга туры килә! — дип, сукраныбрак, урамга караган зур такта капканын юлларын ачып бетергәндә, малай-салай, кодалар каршы алырга дигән булып, җыела да башладылар. Бала-чага артыннан кардәш-ырулар, күрше-күләннәр агылдылар. Йорт халык белән тулды, малайлар бер-берен егып, кар сибешеп уйнарга тотындылар. Минһаҗ

тиргәнде:
— Бер көрәгәнне яңадан туздырасыз, шайтан балалары, — дип куып карады, ләкин җиңә алмады; берсе кайдандыр иске ярык көрәк табып чыгарды, икенчесе алама бер себерке тапты, ялчыга булышабыз дигән булып, шаярып, кычкырышып, тагы яманрак буран кузгаттылар, җыелган халыкның өстенә кар сибеп бетерделәр. Шулай уйнап, шаярып котырганда, берсе кычкырып җибәрде:
— Туй килә, туй килә! Туй килә!
Башка балалар бу тавышны эләктереп алдылар, бернәрсә аңламастан, кычкырышып, урамга ташландылар. Чыннан да, анда, урамның күпергә таба очыннан дүрт-биш чаналы кунаклар болай таба чаптырып киләләр. Нурыйның зур улы Төхфәт тә халык эчендә иде. Ул, ничек болай бик иртә соң бу дип аптырабрак, шул якка карады, башкалар да гаҗәпсенә төштеләр. Тегеннән алды-артлы җигүле атлар кар эченнән җилдереп болай таба очалар гына. Төхфәт, өйгә таба йөгереп:
— Әткәй, тизрәк бул, килделәр, — дияргә ташланганда, аны бертуктаусыз челемен тартып, каядыр үтеп барышлый гына монда туктаган Шәвәли карт кисте:
— Нигә кычкырасың? Күрмисеңме? Шибай атлары түгел болар, сукыр... — диде. Үзе түбән очка тимерлеккә таба китә бирде.
Монда җыелган халык та, кунаклы чаналар якынрак килгәч, таныдылар. Дүрт чана, алдагысына очлап ике ат җигелгән. Башкаларына берәр, һәр чанага юрганнар, мендәрләр эченә батып, ирле-хатынлы ике кеше утырган. Тик иң соңгысында гына ике егет. Атлар, тирләп боз-кар белән катып беткән булсалар да, бирешмәделәр, озын урам буенча кызу йөгертеп, югары очка, кар яудырып, шилап үттеләр. Малайлар, иң арттагы ялгыз чанага мыскыллап кар бәреп:
— Кияүнең аты арган, кияүнең борыны туңган, — дип кычкырып озатырга өлгерә алмадылар, шул ук яктан, шул ук юлдан, зур кара ат җигелгән, ирле-хатынлы ике кеше утырган өлкән ялгыз чана яңа көрәлгән юлдан, карны чаж-чож ярдырып, Нурый карт йортына килде дә керде.
Бу көтелмәгән ялгыз кунактан һәммәсе аптырап калды.
Гадәттә, кайбер вакыт туйга килә торган кодалар аш чанасын алдан җибәрәләр. Шул түгелме дип уйларга да булмый, монда бер хатын да бар. Җыелган халык, бу кем, бу кем дип, бөтенләй кар белән сыланып беткән зур чананы, күзе, бите, авызы, иреннәре, бөтен гәүдәсе бозланып каткан зур кара атны, киезләр астыннан толыпларын, шәлләрең күтәреп чыга алмый торган ир белән хатынны тирәләп алдылар.

Иң элек зур ялчы танып кычкырды:
— Пәрәмәч! Шәйхел, синме? Синең кайтыр көнең бармы? — диде. Чанадагы зур калын киезне карлары белән бер якка каерып ташлады да тагы өстәде: — Бәхетле авыз икәнсең, малай! Сеңелеңне бирделәр, туйның үзәгенә чумдың бит!
Чанадан таза, ныклы зур толыпны кага-кага ир күтәрелде, ялчыга карады:
— Нихәл, исәнме? Син, Минһаҗ, һаман монда икәнсең?.. — диде.
Ялчы көлеп кычкырды:
— Монда булмый кая барасың? Өйрәнгән бай сугышырга яхшы диләр бит! — диде.
Ул арада хатын да карлы туны, бозлы шәле белән чанадан төште. Ялчы бөтенләй шашты:
— Бак, малай! Мәрхәбә, син түгелме? Бөтенләй байбикә булгансың лабаса! Монда синең әнкәң ачтан аяк суздлы, атаң исән, әле яңа гына сукрана-сукрана тимерлеккә китте... Менә ничек, ә?..
Хатынның сүзе-җавабы ишетелмәде. Өйдән матур җиңги Мәфтуха йөгереп чыкты да, яулыгының бер чите белән авызын әз генә каплар-капламас рәвештә барып, халыкны ерып, тыгызлап, чанадан төшкән хатынга килеп тотынды:
— Әй генәм, Мәрхәбә, синме? Менә бәхет! Гөлбануның туена кайтып төштең ләбаса! Тик инде җиңел аягың белән килә күр! — диде дә, кайбер кечкенәрәк әйберләрен күтәреп, үзен өйгә таба алып китте.
Йорт эчендә кар ерып барганда да, баскычтан күтәрелгәндә дә, ишек төбендә аяклардагы пималарны какканда да сүз һаман тик туй турында гына, кыз белән кияү турында гына булды.
Кунак хатынының сорауларына каршы Мәфтуха үзенең әрнүен яшерә алмады:
— Сорама инде, әй генәм. Йөрәгем бик өзелә. Нурмөхәммәт бабай, берәүгә дә белдермичә, теге Бикьярның Шибай кантун улына килешкән дә куйган.
— Начар җир димени?
— Начарын, яхшысын белгән юк инде. Егетен дә бик мактап бетермиләр, каенана бик этавыз нәрсә, ди, Гөлбануга бер дә якты көн бирмәс, диләр...
Сүзләре бетә алмады, өйнең хатыннар ягына керделәр. Бүлмәгә суык һава тулып китте. Фәтхия әби туй кирәгенең актык хәзерлекләрен бетерергә ашыгып йөри иде, кунак хатынны күргәч, бөтенләй әрнеп куйды, өстенә күтелмәгән шомлы күңелсезлек капланган кебек булды: «Ходаем, бу гына җитмәгән иде инде?! Кайдан килеп чыкты тагы бу бәхетсезе?» — дип өзгәләнде. Ләкин ул эченнән ризасыз булганда да тыштан кешегә начар, каты йөз күрсәтә алмый иде:

— Нихәлең бар, килен, исән кайттыңмы? Шәйхел кая? — дип сораша башлады.

VI

Бу кунак килен Нурый картның куып чыгарган улы Шәйхелнең хатыны иде. Моның ире — Фәтхиягә үги ул була. Үз анасы баладан үлгәч, Шәйхелислам менә шул Фәтхия кул астында үги бала булып, эт урынында кыйналып үсте. Фәтхия болай йомшак күңелле, изгелекле кеше кебек танылса да, көндәшенең баласын ярата алмады, аны күрү йөрәген кайната, юк-бар сылтау белән типкәләп куып чыгарырга ашкына торган булды. Ун яшькә җитәр-җитмәс малайны, ичмаса күземнән югалсын дип, күрше авылның «мәптегенә» илтеп ташлатты. Анда да ашарга искергән арыш икмәге белән күгәргән ярмадан башка әйбер җибәрмәде. Ләкин малай усал иде. Үги анадан килгән ашамлыкларын юк хакка сата иде дә бодай күмәче ала иде. Аннан һәр атна кич басу капкасына чыга да, берәр базарчыга утырып, Караюргага кайта иде. Өйдә туйганчы сыйлана, мунча керә, өс-башын алыштыра да, анасының ялчыдан җиктергән начар утын чанасына утырып, икмәкләр, ярмалар төяп, шимбә көн тагы «мәптеккә» китә. Алдагы атнада тагы кайта. Үги анасы тагы ялчыдан илтеп ташлата.

— Кайтма, сабак калдырып йөрисең, — дип, анасы күп таяклады, үги ананың чыраларыннан аркасында, беләкләрендә кара янмаган урын аз калды. Ләкин малайга һаман да гыйлем йокмады. Ул аз-маз кул куярлык, ак өстендәге караны кыенлык белән танырлык булгач, унҗиде яшендә укуны бөтенләй ташлады. Бер кышны авылда мал карап, егетләр белән сугышып, кызлар белән шаярып үткәрде. Атасының өсәгеннән әллә ничаклы арышны урлап, кибетчегә ярты хакына сатты. Ике тапкыр тотылды, оялмады, кызармады, атасы белән туп-туры:

— Үзең базарлык бер тиен дә бирмәгәч, урламый ни эшлим? — дип телләште.

Нурмөхәммәт каты холыклы крестьян иде, баласының болай оятсызлануына чыдамады, акылга утыртыр өчен тагы таяк белән, каеш чыбыркы белән кыйнады. Шәйхел бераз юньләнгән кебек күренгән иде, ләкин озакка бармады. Тирә-якның ярлы егетләре яз, көз Уралга, тау эшенә — алтын, бакыр, тимер казырга — кәсепкә йөриләр. Атасы белән сугышкан саен ул да эченнән шуны уйлый иде. Бервакыт тегермәнгә ике йөк бодай тарттырырга алып барды. Шуннан сигез потын урлап, ярты хакына сатты, ике сум илле тиен акча ясады да билетсыз, бер кәгазьсез, шул ярлыларга ияреп, Уралга, кәсепкә юнәлде.

Карт эченнән каргады, тышыннан сер бирмәде: йөрсен, дөньяның ачысын-төчесен татыр, акылга утырыр дип сөйләнде. Үги ана Фәтхия бөтенләй тынычланды:

— Алдыннан арты яхшы... Йөргән җирендә дөмегеп калса, бигрәк тә яхшы, — дип уйланды.

Ләкин егет дөмекмәде, алты айдан кире кайтты. Тәмәке тартырга, отыш уеннары уйнарга өйрәнгән. Аягында зур итек. Өстендә кара чикмән. Башында урыс калдыгы бер кара эшләпә. Кулында ике телле шәп гармун. Менә Шәйхел шулай юньсезләнеп кайтып төште.

Үги ананың йөрәге әрнеде, ата да бик хафаланды, ләкин ни эшләсәң дә, бала бит, туган бала бит! Куып чыгарсаң, тагы китәр, тагы бозылыр; Ходай үзе сакласын, азып-тузып, әллә кемнәргә катнашып, диненнән дә язар. Алланың бер каһәредер дип, Нурый түзәргә булды. Тик егетнең кулы кәкрелегенә юл бирмәскә тырышты. Тегермәнгә дә, базарга, калага да аны җибәрмәде, иген сату эшләренә аны якын китермәде. Шулай этле-мәчеле кышны үткәрделәр.

Яз тагы югалды. Җиде айдан тагы кайтты. Шулай бер-бер артлы еллар үтә барды. Егеткә сызылып мыек чыкты. Зур абзасы гаскәри хезмәттә булып, энеләре унсигезгә җитмәгәнгә, җиңел генә солдаттан да котылды. Ата белән үги ана моңа бик әрнеделәр. Кирәген алалар, менә моның кебекләрне калдыралар. Патша да белми икән! Ләкин көчләп җибәрергә юл булмады. Егет никрут чагында, уйнап, җырлап, биеп, атасының өсәген[1] бушатып, әллә ничә тапкыр кызлар янында тотылып, кыйналып йөрде-йөрде дә яз көне тагы китәргә җыенды. Атасыннан юлга акча сорады, байлыгыңнан миңа өлеш дип, бер ат сорады. Нурый әйтерлек җирен калдырмады, эттән алып эткә салып сүкте:

— Атаң үлмәс борын йорттан мал даулыйсың, оятсыз... — диде.

Талаш зурга китте, егет ата дип юл куймады, үзенең усал теллелегенә барды. Ахыр, бер аш ашап утырган чакта, кызышып, үзен үзе югалтты, аш куйган табынга төкерде дә каргап, рәнҗеп чыгып китте.

Аның турында бу соңгы кайтуында, өйләнергә йөри имеш, Челем бабай кызы Мәрхәбәне алмакчы имеш, дигән суз таралган иде. Эш шулайрак булып бетте дә.

Атасы белән талашкан көнне ул Нурыйда күп еллар ялчы булып торган Челем бабай — Шәвәли (Шаһвәли) картны очратты:

— Сиңа сүзем бар. Әйдә әле монда, — дип бүрәнә өстенә утыртты да туп-туры әйтте: — Шаһвәли бабай, син миңа кызың Мәрхәбәне бир! — диде.

Карт аз гына да гаҗәпсенү күрсәтмәде, янчыгыннан яфрак тәмәке чыгарып, челемен ипләп тутырды, чуаш дусы биргән чакмак ташы белән яндырды, куе төтен җәеп тарта башлады, Шәйхелнең битенә карады:

— Сиңа, — диде, — ничек кыз бирәсең? Бай дисәң — малың юк, атаң куып

---

[1] *Өсәк* – келәттә ашлык, он һ.б. салып саклау өчен ясалган зур агач әрҗә

чыгарды. Эш белән дөнья көтәр дисәң, кулыңда бер һөнәрең юк, сиңа ничек кыз бирәсең? — диде.

Шәйхел җиңелмәде:

— Син нәрсә, мине әллә бер хатын туйдыра алмаслык булдыксыз егет дип беләсеңме? Менә күрерсең, кызыңны миңа бирсәң, үзең дә карт көнеңдә миндә җылы почмак табарсың!

Сүз озакка сузылды. Бабай икенче тапкыр челеменә яфрак тәмәке тутырды, чакмак таш сугып яндырды, куе төтен таратып тартырга тотынды. Ахыр барып, болай бетерде:

— ...Андый эшне минем карчык белә инде!.. Кызым карышмаса, миңа нәрсә? Өйләнә бир! — диде.

Челем бабайның өе авылның читендә, ярлы урамның күпергә караган башында иде. Балчык белән сыланган бу читән өй яртылаш җиргә казылган, түбәсе туфрак белән тигез капланган. Анда әремнәр, алабуталар үсеп утыралар. Карындык тәрәзәләрнең тик югары яклары гына җир өстенә чыкканнар.

Егет белән карт менә шунда килделәр. Карчык әйдә юк икән, кибетче Хәйруллаларга үзенең эрләргә алган йоннарын илтә китте, ди. Өйдә Мәрхәбә кыз ялгыз иде. Чит егетне күргәч качмады, сүз дә эндәшмәде, исәнләшмәде дә. Авызының бер читен яулык почмагы белән әзрәк каплаган сымак итте дә ара-тирә кунакка астыртын күз ташлап куйды. Кызның аягында ак оек, яңа ак чабата. Өстендә кызыл француз күлмәк. Башында яулык, янында яңа алынган алсу чәчәкле матур шәл тора.

Ул һәр җәйне читкә, боярга ялланып урак урырга китүчеләргә кушылып бара да анда берничә атна эшли. Үзе тапкан акчасын үзенә өс-баш ясарга тота. Үткән җәй шулай, читкә барып ялланып, печән-урак эшләүчеләр белән йөреп, ундүрт сум алып кайтты. Шуңа яулык алды, шәл алды, күлмәк ясатты, иннек белән кершәнгә, сөрмәгә дә өлеш калды; җитмәсә тагы атасына кәләпүш, анасына бер яулык алып бирергә дә артты. Аның нияте бер чулпы белән беләзек тә эшләтү иде. Ләкин көннәр бик яңгырга кергәч, ташлап кайттылар. Кыз бу хыялларын киләсе елның җәенә күчерде. Бүген күршедә аулак өй бар. Әнкәсе кич белән шунда җибәрергә сүз бирде. Кыз, көннең үткәнен көтә алмыйча, шул аулак өйгә барырга бизәнеп, ясанып, киенеп куйган иде. Ул Нурый картларга көнлекләп эшкә баргалый иде. Утауда, печән җыюда, уракта, ындырда ашлык сукканда Шәйхел белән күп очраштылар. Ләкин үзләренә килүгә бераз гаҗәпсенде.

Атасы, өйгә кереп, утырыр-утырмас әйтә салды:

— Кызым, — диде, — сиңа яучы китердем. Яучы да үзе, егет тә үзе, менә кара, — диде.

Мәрхәбә дәшмәде, боларга бер яны беләнрәк утырып, алъяпкычының почмагын бер бөкләп, бер сүтеп маташты. Карт тагы сорады, кыз һаман дәшмәде. Өченче тапкыр сорагач, алъяпкычының чите белән уйнап, кызарды, аягындагы чабатаның башына күзләрен текәп, акрын, оялчан тавыш белән:

— Менә инде син, әткәй! Андый эшне мин кайдан белим?! — диде.

Егетнең күңеленә җылы керде. Мәрхәбәнең җавабын: «Мин каршы түгел, үзең теләсәң ни эшлә», — дип аңлады.

Ул арада кызның анасы Мәргыя әби үзе дә кайтты. Егетнең ни эшкә килгәнен белгәч:

— Яшь башың белән ил йоласын бозып йөрисең, берәрсен яучы итеп җибәрсәң ни була, — дигәләп, Шәйхелне орышты.

Ләкин ахыры шулай бетте: әбинең өч тавыгы бар иде. Берсе, симереп, юньләп йомырка да салмый башлаган иде. Кызыннан тоттырды да, иреннән суйдырды да, иплэп йолкып, тазартып, казан асты. Никах өчен муллага ике як иллешәр тиен табып бирергә булдылар. Челем бабай өзеп куйды:

— Безнең ахун бик комсыз, ач күз нәрсә... бер сумны азсыныр, мин аңар баштан ук әйтермен, күбен банлардан алырсың, безнең артыкка хәлебез юк диярмен, — диде.

Егетнең мәһәргә бер тиене дә юк иде. Карт аңар да җаен тапты:

— Мулла сорамаса, шулай кала бирә, язарга кирәк дисә, әйтерсең: мәһәр йөз сум диярсең, барын да биреп бетердем диярсең. Мин алдым диярмен дә тамга салырмын, мулланың ни эше бар? Алганмы, юкмы?

Бу, әлбәттә, бик җитте. Мулла, тавыкны ашап, бер сумга ихлассыз гына бит сыйпап, мәһәр түләнгән дип язып китте. Кыз бүген аулак өйгә бармады, аның урынына егет куенына, зөфафка керде. Бер атна торгач, әби-бабай белән исәнләшеп, елашып, егетнең кәсеп иткән җиренә, Уралга киттеләр. Хәлебез төзәлгәч кайтырбыз, диештеләр.

Шәйхел, алтын, тимер казуны ташлап, башкорт эчендә аз-маз алыш-биреш итеп маташты. Алатау дигән бер башкорт авылында нигез ясап утырырга чамалады. Агач савыт, аркан, чыпта эшләре белән азапланды. Ләкин күңеле туймады, хатын да Караюрга буйларын бик сагынды. Бераз юнәеп, кеше арасында күренерлек өс-баш ясагач, болар туган илгә бер әйләнделәр. Ир атасы белән килешү ягын тотарга уйлады: берәр имана (монда «душ» диләр) җир биреп, өй салырга әзрәк булышса, шунда, җәмәгатьтән урын сорап, төпләнергә ниятләнде.

Ләкин Нурмөхәммәт якын китермәде. Улының сәламен алмады, очраганда исәнләшмәде. Йортына аяк бастырмады. Ир-егет ачудан, әрнүдән тиреләренә

сыймас булды, яңадан хатыны белән Алатауга, башкорт эченә китеп, үзенең кәсебенә чумды.

Икәүләп көн-төн эшләделәр. Актык әйберләрен сатып акча ясадылар да алыш-бирешне киңрәк кул белән әйләндерергә тотындылар. Боларның ишкән, иштергән арканнары, ясаткан бөятләре, тәгәрмәч тугымнары, алап, чуман, чиләкләре, күчәр, көрәкләре, бөккән, бөктергән чана табаннары зур базарларга таба юл салды, аннан инде Тамъян-Катай, Верхурал, бара торгач, Эстәрле, Ырынбур якларына таба озату өметләре ачылыр кебек булды..

Шуның белән болар анда азрак тамырлану ягын карадылар.

Заманында Шәйхел үзе үткен, уңган, шаян егет иде. Эштән бушаган araларда башкортның яшьләре белән уен-көлкегә катнашты; аларга кушылып, кымыз мәҗлесләрендә көр тавыш белән, башкортның нәкъ үзе булып, «Ашказар», «Сакмар», «Шәүрәкәй» җырларын көйләде. Ир урталары белән аш-суга чакырышты... Бал әчетеп, дуслар белән эчте, сыйлашты. Яшь Мәрхәбә бик тиз арада бер башкорт хатыны кебек булып үзләште дә китте, аларча сөйләште, сөт, катык, май, каймакны алардан өйрәнеп ясады. Алар белән кунакка чакырышты, симез елкы казылыклары, сары майда гына пешкән бәлешләр белән сыйлашты; өстенә, башкорт хатыннарыныкы кебек билен, күкрәген тәңкәләтеп, бишмәт тектерде, башкорт киленнәре кебек кушъяулык (бөркәнчек) ябынды. Күрше тауларга җәй көннәрендә хатын-кыз җыелып уен-көлкегә чыкканда, Мәрхәбә дә калмады, матур башкорт җырларын моңланып-моңланып җырлады, кыска, җиңел, шат көйләргә такмаклап биеде.

Шулай болар икесе дә нык үзләштеләр. Алатауның иң каты иске башкорт карчыгы Үлмәсбикә әби дә кайбер вакыт:

— Татар димәссең! Шулай ипле нәмәләр! — дип, иң югары мактау сүзен әйтеп куйгалады.

Илнең башы олы атай Бурангыл карттан да болар хакында кимсетеп әйтелгән сүз чыкмады.

Бу инде бер татар килмешәге өчен, әлбәттә, зур шатлык эш иде. Көн итәргә зур уңайлык иде. Ләкин болар һаман да тынычланып бетә алмадылар. Бигрәк тә Мәрхәбә үзенең туган илен сагынып йөдәде. Ул мондагы тук тормышны мактап сөйли-сөйли иде дә:

— Алаен алай да бит, Караюргага берсе дә җитә алмый шул.

— Туйган җирдән туган җир артык шул.

— Чит җирдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул, дип белми әйтмәгәннәр шул, — дип куя иде. Аннан инде җиләк җыйган таулар, уйнап үскән елгалар, печән җыеп, урак урып йөргән яланнар берәм-берәм аның теленә керәләр,

сагынып сөйләнә башлыйлар. Кайбер вакыт күз яше белән дә бетә.
Караюргадан Уралга яз, көз кәсеп эзләп килгән ярлы егетләрне күп очраттылар. Алып кереп кундырдылар. Симез ит белән, кымыз белән, бал белән сыйлап кунак иттеләр. Шуларның берсенә Шәйхел үзенең серен ачты:
— Син, Вилдан абзый, минем карт белән иплəп сөйләшеп кара әле. Гомергә чит җирдә каласы килми, әткәй фатихасын бирсә, җиреннән, малыннан әзрәк өлеш чыгарса, мин туган илгә кайтып үземә бер оя корыр идем, — диде.
Нурыйдан ачык җавап килмәде. Шулай да хәзер бөтенләй үк кире какмас кебек сизенде. Сүз арасында берәүгә әйткән имеш:
— Ярар, акылга утырып җитсен әле, карарбыз, — дигән имеш.
Менә шул җылы хәбәр аларны кыш көне, кузгатып, Караюргага кайтарды. Яз, көз, җәй эшнең кызу чагы була. Кәсепне ташлап, бару-кайтуы ике атналык юлга чыгып булмый. Кыш бушрак килә. Менә шуңардан файдаланып, өс-башны карады, тиешле бүләкләрне урыс авылындагы зур базардан барып алды да, үз чанасын, үз атын җигеп, карлы-буранлы көннәрдә, олы юллар белән Урал тауларын үтә-үтә, туган иле Караюргага кайтып төште.
Алар Гөлбануның бирелгәнен ишетмәделәр, бу шимбәне туй көне дип бер дә белмәделәр. Нурый карт йортына тулган халыкны күргәч, матур җиңги Мәфтухадан кияү турындагы хәбәрләрне ишеткәч, Мәрхәбә бөтенләй каушап калды, үги каенанасы Фәтхиянең болай теләр-теләмәс каршы алуын күргәч, аның бу борчылуы тагы да артты. Ләкин ул, төп асылда, мондый теләми каршы алуларына очрармын дип алдан ук хәзерләнгән, ире аны, таяклап кугангача, һәммә нәрсәгә, һәммә шелтәгә түзәргә, баш иярга юл буенча өйрәтеп кайткан иде. Үги каенананың күңелен алырга, туры үзенең киленлек, кардәшлек тойгыларын күрсәтергә ашыкты. Каенанасының беренче сорауларына җавап бирә-бирә үк, үзенең зур букчасын чиште. Аннан бер-бер артлы әйберләр тартып чыгара башлады:
— Әнкәй, син миңа ачуланма инде. Без анда да ач түгел. Тик менә ата-ананың фатихасын алыйк дип кайттык, — диде, букчадан зур мамык шәл тартып алды.
— Әнкәй, менә моны сиңа алдык, бүләк булсын, безгә фатихаңны бир, — дип, Фәтхиянең кулына салды.
Карчыкның карт күзләренә нур кереп китте, күңеленә дулкын йөгерде, гомерендә күрмәгән җылы мамык шәлне, балалар кебек шатланып, шунда ук ябынып карады. Тәне рәхәтләнгән кебек булды, үзе дә сизеп өлгермәде:
— Рәхмәт, балам, бик рәхмәт, — дип, үги киленнең аркасыннан какты; кулын күтәреп, дога кылды.
Кунак хатын туктамады:

— Менә бусы әткәйгә, — дип, дүрт аршин кара постау чыгарды. Аның артыннан: — Менә бусы каен сеңелем Гөлбануга, — дип, зур матур шәл тартып алды. Бу инде үзенең аллы-кызыллы чуклары, сарылы-зәңгәрле җирлеге белән бөтен бүлмәне нурлы төсләр дулкынына тутырды.
Мәрхәбә тагы ниләр алып маташа башлаган иде, Мәфтуха туктатты:
— Җә, башкаларын соңыннан... — диде. Үзе арада иң матур әйбергә — аллы-зәңгәрле шәлгә сокланып катты, күз нурларын уйнатып, ялкынлатып, шәлнең әле бер буен, әле икенче буен җәеп, дулкынландырып карый бирде.
Фәтхия әби бөтенләй эреде, Гөлбануга дигәнен үз өстенә каплады, атанықын кулына тотты да тегендә, ирләр ягына чыгып китте. Бу бүләкләр белән картның рәнҗүле күңелен йомшартырга, туй арасында тавыш чыгартмау җаен карарга теләде. Ләкин анда ирен тапмады, ул, киенеп, йортка чыгып киткән иде.

VII

Урамда малай-шалай туй килә дип юкка шаулашкан чакта, хуҗа өйдә иде, кызыл саплы үткен пәке белән, кодалар килгәнче дип, көзге алдында мыегын кырып маташа иде. Көтелмәгәндә карлы-буранлы чана килеп кергәч, ул да бераз гаҗәпсенде, аш чанасы түгелме дип, төрле бизәкләр белән бозланып туңган тәрәзәнең бер читеннән йортка күз ташлады. Анда ерак юлдан килгәнгә ошашлы ирле-хатынлы ике кеше күргәч, аптыравы артты, мыегын астан да, өстән дә тиз-тиз генә төзәтеп, эшең бетерде дә, бүреген, кара тышлы тунын, кыска яңа киез катасын киеп, йортка чыкты. Бу вакыт кунак хатын матур җиңги белән өйгә кереп киткән иде. Чанадан төшкән ир, зур толыбының якасындагы, җилкәсендәге карларын кага-кага, Нурмөхәммәткә каршы килде. Туңган тавыш, өшегән авыз белән:
— Әссәламегаләйкем! Әткәй, исәнлекме? — дип, калын җиң эченнән ике кулын сузды.
Карт:
— Вәгаләйкемәссәлам, — дип, сәлам кайтарды, күрешеп, бит сыйпады да шуның артыннан ук кунакка шелтәле караш ташлады, шелтәле тавыш белән: — Син икәнсең! Бик вакытсыз йөрисең! — диде.
Шәйхел мондый сүзләрне көткән, алдан хәзерләнгән иде, үзен югалтмады:
— Ачуланма, әткәй, мал дауларга кайтмадым. Фатиханны сорарга кайттым, үз бәхетем үземә җитә минем, — дип, атасын йомшартырга тырышты.
Карт үзенең кунак улына карамады, аяк астындагы зур кар кисәген пимасы белән тибеп бер читкә таба этәреп җибәрде дә тагы баягы шелтә белән җавап кайтарды:
— Җитсә, бик яхшы! Синең даулашуыңнан курыкмыйм мин! Үзем исән чакта

бер тиен бирмәм. Мин үлгәч, тияреңне алырсың, — диде дә, тагы бер кисәк карны тибеп, өстәде: — Менә, үч иткән кебек, туй белән тыгызланган чакта килеп тыгыласың бит, — диде.

Кунакның йөрәгенә бераз җылы керде. Ул атасының куып чыгармавын күрде. Ачык итеп әйтте:

— Үзем дә күрәм, әткәй! Вакытсызы — бик вакытсыз булды инде, без белмәдек шул... Күңел киң булса, урын тарлыгыннан курыкмыйм мин, ага-эне күп, бер хатыным белән абзыйларга барсам да сыярмын, син тик безгә фатихаңны гына бир, — диде.

Карт нидер әйтмәкче булган иде, урамдагы балалар, тагы дөнья куптарып:

— Туй килә, туй!

— Туй килә, туй! — дип акырышырга тотындылар. Авылның түбән очыннан кыңгырау тавышы ишетелде; ул тиз якынайды, кучер: «Һа-а-ай!..» — дип кычкырып, чыбыркы шартлатып җибәрде, Нурый капкага каршы чыгарга өлгерә алмады, икешәр, өчәр, берәр ат җиккән дүрт-биш чана, кар-буран туздырып, алды-артлы чабышып, йортка килеп тә керделәр.

## VIII

Атлар, азбар буеннан урап, яңадан өйнең баскычларына таба килеп тукталганда, чаналар тирәсе каршы алучы ирләр, хатыннар белән тулып китте.

Алды-артлы өч ат җигеп, кучер утырган өлкән чанада карт кода Шибай кантун белән аның хатыны карт кодагый Сабира иде. Боларны Нурмөхәммәт белән Фәтхия ике яклап каршы алдылар, исәнләштеләр, чанадан төшәргә булышлык итештеләр. Икенче чанада Шибайның кияве Әфтәх белән кызы Хәерниса иде. Боларны Нурыйның күптән аерылган зур улы Төхфәт белән аның хатыны Мәрфуга каршылады. Өченче чанадан Шәйхел, матур җиңги Мәфтуха, кунак килен Мәрхәбәләр, мыж килеп, исәнләшеп, әйбер алып кайнаштылар. Дүртенчесе — аш чанасы иде. Анда тик ялгыз егет утырган; моңа зур ялчы ярдәмләште; башка ирләр, хатыннар аның һәртөрле күчтәнәчләр белән тулы төргәкләрен, сандыкларын иплән өйгә кертештеләр. Гадәт буенча, кияү өндәүчеләрдән Чокыр Хәбипнең йортына төште. Яхшы бер ат җигеп, кияү егете белән икәве бер чанада килделәр; никах укылганчы шул өндәүче өендә калачак, аннан кыз хатына киләчәк.

Туй килер алдыннан өйләрне җыештыру эше зур мәшәкать булды, бик күп көч, вакыт алды. Нурыйның урамга буе белән салынып, салам белән ябылган алты почмаклы өе икегә бүленә. Ике якка аерым ике баскыч белән ике ишек керә. Төнгә караган як — ирләр ягы дип, ак-өй – кунак өе дип йөртелә. Туй хәзерлеге вакытында Фәтхия әби бу якка аеруча күп көч түкте. Иң элек, тыгызлыйлар

дип, сәкеләрне чыгартты. Бар җирен юдыртты, мичен акшарлатты, ишектән түргәчә зур ак киез түшәтте, аның өстенә йортта сугылган чуар палас җәйдерде, түргә таба тар корама юрганнар салып, берничә мендәрне сибеп ташлады. Стеналарны кызыллы-аклы сөлгеләр асып бизәде. Электә үзләрендә Мәккә белән Мәдинә[1*] сурәте генә бар иде, өйгә ямь бирә дип, базардан тагы зур ике шәмаил алдыртты. Боларның берсендә Айя Суфия мәчете[2*], берсендә Истамбул күпере[3*] иде. Боларны асып җибәргәч, өй бөтенләй икенче төс алды. Ишек төбендәге савыт-саба шкафын чыгартты, Гөлбануга бирнәгә алынган зур сәгать белән көзгене түр як стенага беркетте; болар инде бөтенләй ачып җибәрделәр. Бу чаклы ук матурлый алмаса да:

— Кодагый бик телчән нәрсә, диләр, гаепләп китмәсен, — дип, өйнең хатыннар ягын да булдыра алган хәтле төзәтте, бизәтте, чибәрләтте. Монда да сөлгеләр, эленгән намазлыклар, түшәлгән киез, паласлар, мендәрләр теге яктагыдан күп ким түгел иде.

Җыелган халык, уен-көлке белән кычкырышып, шатланышып, шаярышып, атларны тугара, чанадагы әйберләрне бушата калдылар, хуҗа ирләр, хуҗа хатыннар килгән кунак кодаларны, кунак кодагыйларны: «Әйдәгез менә моннан, менә моннан», — дип тарткалый-тарткалый, ирләрне ирләр ягына, хатыннарны хатыннар ягына алып кереп киттеләр. Өй эче кодалар, кодагыйлар белән, салкыннан кергән туннар, шәлләр, толыплар, шарфлар, карлы бүрекләр белән тулды, һәр ике як та исәпсез-хисапсыз исәнләшүләр, шаулашулар, хәл сорашулар белән капланды. Өшеп килгән кунакларга ике якта әзерләнгән чәйне эчкәндә, чынаяк артыннан чынаяк өчен берберен бик каты кысташканда, тагы берне, тагы берне дип эчәргә, коймактан, майдан, пәрәмәчтән житешегез дип димләшкәндә бу өзлексез сүз, тавыш тагы да көчәя төште.

Никах мәҗлесенә килергә тиешле илле кеше алдан ук чакырылган, хатыннарга да шул ук бервакытта килергә хәбәр ителгән иде. Кодалар, юлдан килеп, исәнлек-саулык сорашалар, сәламләшәләр; кысташлар эчендә икешәр, өчәр чынаяк эчеп, самавырны алуга, чакырылган кешеләр берәм-берәм агыла да башладылар.

Иң элек чалмасы, таягы, ярлы туны, таракан ашаган читеге белән Фәйзулла мәзин килде. Ул кереп, кодалар белән күрешеп, исәнлек-саулык сорашуга, утырып дога кылырга өлгермәде, берьюлы сәлам биреп, берьюлы сәлам алып, дүрт мужик бергә килеп керделәр. Болар артыннан үзе белән бергә икенче мәҗлестән хәзер генә чыккан унлап кешене иярткән мулла Шәрип ахунның зур таза гәүдәсе, бохарача калын ишеп чалынган зур ак чалмасы, шәл якалы тун эченнән ялтыраган яңа яшел чапаны тәрәзә аркылы күренде.

— Хәзрәт килде, хәзрәт килде, — дип, яшьрәкләр урыннарыннан тордылар, хуҗа үзе, ишек ачып, баскычка каршы ук чыкты. Болар белән бергә өйгә әллә ничаклы суык һава керде, исәбе-хисабы булмаган әссәламегаләйкем, исәнмесез, саумысыз, исәнмесез, саумысызлап, кодалар керде.

Муллага иң түрдән, карт кода Шибай кантун яныннан урын бирделәр, аркасына таянып утырырга мендәр салдылар. Мулла, һәммәсе белән исәнләшеп, сәламләшеп беткәч, кулларын җәеп, ярым кычкырып, дога кылды да һәр ике коданы туй белән котлауга ошаганрак сүз сөйләп китте, Ходай хәерен насыйб кылсын, дип бетерде.

Кунаклар бер-бер артлы агылып тордылар. Шәрип ахун үзенең күптән түгел мөфти хәзрәтне күрүен, бичара иптәш мулласы Гыйззәтнең бер хаталык сәбәбеннән указдан мәхрүм калуын кызганып сөйләде. Кунак кода Шибай кантун бу эшнең төбен яхшы белә иде, шулай да каршы әйтмәде: «Шулай инде, хәзрәт, бәндәнең аягы тайгач, егылмый калуы сирәк була», — диде. Ахун, халык авызында үзенә каратып сөйләнгән кайбер гайбәтләр белән бәйләнешле бу эшне бер якка калдырып, сүзне туйлар, никахлар, мәҗлесләр тирәсенә күчерде.

IX

Бу ике мулла Ырынбур Каргалысында бер мәдрәсәдә укыдылар. Үзләре авылдашлар иде. Гыйззәт ач торып, аяк бозып солдаттан калды да шул арада гына үлгән атасы урынына указ алды. Шәрипнең исәбе башкача иде: зур калаларның баерак бер мәхәлләсен өмет итә иде. Дөньяга чыгарга ашыкмады. Каргалыдан Казанга, Кышкар мәдрәсәсенә барды. Анда даменла[1] Исмәгыйль заманында моназир[2] шәкерт булып, «Сөлләм»нән «Хикмәт»кәчә[4*] үтте. Аннан Троицк юлы белән татар сәүдә кәрванына ияреп Бохарага барды, өч ел хөҗрәдә[3] калды. Ләкин уйлаганы булмады, Бохарадан яшел чапан киеп, зур чалма чалып кайтса да, очраган мәҗлесләрдә зур дәгъва белән һәркемне элеп алып, селкеп салса да, якын арада гына зур калаларда буш мәхәллә барлыгы күренмәде. Форсат килер, вакыты белән күчәрмен, үзем теләгән зурын да табармын дип, үз авылына имам булды: Гыйззәткә караганда моның гыйлеме дә, телгә, сүзгә осталыгы, даны, исеме дә югары иде. Тартышмады, теге мәхәллә дә беренчелекне моңа бирде. Гаетләрне, җомгаларны Шәрип укыды. Тик фидияләрендә генә тигез өлеш алу ягын каерды. Ләкин Шәрип моңа канәгатьләнмәде: зур авылның бай үзәк мәхәлләсендә ялгызы патша булырга

---

[1] *Даменла* — мәдрәсәнең башлыгы булган мулла.
[2] *Моназир* — мәдрәсәләрдә оештырыла торган бәхәсләрдә катнашучы.
[3] *Хөҗрә* — мәдрәсәдә торак бүлмәсе.

теләде. Үзенең ераграк, фәкыйрь кардәшләреннән, безнең Гыйззәт муллабыз эчә, биш вакытка мөсаһәлә кыла[1], күп вакыт җомгаларда читтә йөреп кала дип, кәгазь бирдерде. Ләкин Гыйззәт дөньяның нинди күчәр өстендә әйләнгәнен үзенчә аңлый торган бер адәм иде. Гошергә җыелган ашлыгын бер сатып, утыз көмеш акча ясады, мөфтигә ике симез күркә, бер пот сары май, бер батман кәрәзле ак бал, казыйга ике симез каз, бер бүре тиресе алды да Уфага китте. Анда бер атна ятып, сары йортта[5*] кирәк кешеләрен күреп, бу юлга шелтә белән генә котылып кайтты.

Ләкин бу коры шелтә Шәрипне туйдырмады; аңа зур бай мәхәлләнең хәзинәле диңгезендә берүзе йөзәргә кирәк иде. Тагы ике фәкыйрьгә унар пот арыш, берәр сум акча бирде дә Гыйззәтнең бер хатасы турында эш кузгаттырды: «Яше тулмаган кызга никах укыды», — дип, кәгазь бирдерде.

Тикшергәч, чыннан да, никах укылган чакта кызның ике ае тулмаганлык беленде, шуның аркасында мулланың указы алынды. Шәрип ялгызы калды, тиздән мөфти аңа ахунлык дәрәҗәсе дә бирдерде. Бу турыда, адәм сөяге өстеннән атлап йөри дип, начар гайбәтләр таралып киткәнгә, Шибай алдында бу хәлләрне аеруча озаклап, тәмләп сөйләде, ләкин очлап бетерә алмады.

Хуҗа Нурый карт тыгызланып утырган мәҗлескә күзен йөртте дә мулланың сүзен бүлде:

— Хәзрәт, — диде, — киләсе кеше килеп бетте, башламыйсызмы? — диде.

Ахун зур гәүдәсе белән кузгалды, симез ботлары өстенә ипләнебрәк утырды да, эһем... эһем... итеп тамак кырды, акрын, йомшак тавышын бераз борынга җибәреп:

— Ярый алайса! Аллага тапшырып, башлыйбыз, кызның, кияүнең вәли-вәкилләре хәзердер бит, — диде. Үзе Шибай кодага борылды: — Кияүнең вәли-вәкиле сез буласызмы? — дип сорады.

Карт:

— Бәли[2], без булабыз, — дигән сүз белән җавап бирде.

Кызның вәли-вәкиле дигәне атасы Нурмөхәммәт иде. Ахун аңарга әйтте:

— Кызның ризалыгы бармы?

Хуҗа Нурый мәҗлестән тышта, мич буендарак аягүрә сөялеп тора иде. Мулланың соравына каршы түргә таба кузгалып, кулларын уды:

— Бар, хәзрәт, бар. Әткәй биргән кешегә мин риза дип тора... — диде.

Ләкин рәсми яктан мулла өчен бу гына җитмәде. Ул мәҗлестәге адәмнәрдән

---

[1] *Мөсаһәлә кылу* — җиңел карау, вакытында үтәмәү.

[2] *Бәли* - әйе

икәвесенең барып, кыздан ризалык сорап килүен тиешле тапты. Болар ук шаһит булып дәфтәргә кул да куячаклар.

Хуҗа аңа-моңа карышмады. Күз белән күрсәтеп, ишеккә якынрак утырган ике кешене — Хаҗиморат белән Вәлиморатны торгызды. Болар чикмәннәрен, бүрекләрен киеп йортка чыктылар.

Тышта буран тукталган. Кар да яумый. Караңгы төшкән, һава бик салкын, ерак күкнең хисапсыз йолдызлары бриллиант, алмас булып яналар.

Коры суык шәһитләрнең битләрен, колакларын чеметтерде. Болар чикмәнгә төренә биреп азбарга йөгерделәр, акрынлап-акрынлап, кунак атларны, карый-карый, бушандылар да аш өенә керделәр. Анда үги килен Мәрхәбә бәлеш майлап маташа иде; башкорт булып беткәнсең икән дип, аны шаярта-шаярта комган белән кулларын юдылар, майланып беткән тастымалга сөртенделәр дә, салкын һавада сикергәләп, кире мәҗлескә керделәр.

Ахун чалма башын күтәрде, һәр ел, гомер буенча бу эштәге хәйләне ачык белгән хәлдә, бөтенләй чын тавыш белән сөаль бирде:

— Сорадыгызмы? Ризамы?

Хаҗиморат белән Вәлиморат берьюлы, бер тавыштан җавап кайтардылар:

— Сорадык, хәзрәт, сорадык, риза, бик риза, ди, әткәй-әнкәй биргән кешегә риза, ди.

Мулла үзе белән алып килгән букчасын тәрәзә төбеннән алып, күк тышлы метрика дәфтәре белән каләм-карасын чыгарып куйды. Сүзне мәһәргә күчерде. Кызның, кияүнең вәли-вәкилләре сүзеннән мәҗлескә шул аңланды: мәһәр алты йөз сум. Моның яртысы хәзер бирелә. Сиксән сумы акчалата, калганы әйбер белән. Алты йөзнең өч йөзе алга, бурыч булып языла, Нурмөхәммәт тә, Шибай да шуңа ризалар.

Шәрип ахун башта хуҗага карады:

— Кызың Бибигөлбануны өч йөз сум мөгаҗҗәл, өч йөз мөәҗҗәл[1], — барлыгы алты йөз сум мәһәр бәрабәренә Мөхәммәтзакир бине Шиһабетдингә риза булып бирдеңме?

Карт:

— Риза булып бирдем, — дип җавап кайтарды. Мулла кунак кодага борылды:

— Угылың Мөхәммәтзакирга өч йөз сум мөгаҗҗәл, өч йөз сум мөәҗҗәл, — барлыгы алты йөз сум мәһәр бәрабәренә Бибигөлбану бинте Нурмөхәммәтне риза булып алдыңмы?

Шибай кантун күкрәк тавышы белән бөтен мәҗлес өстеннән гөрләп әйтте:

---

[1] *Өч йөз сум мөгаҗҗәл, өч йөз мөәҗҗәл* — өч йөз сумы туйгача бирелгән, өч йөз сумы бурыч булып язылган мәһәр.

— Бәли, риза булып алдым, — диде.
— Шәһитләр, ишеттегезме?
Хаҗиморат белән Вәлиморат: «Ишеттек, ишеттек», — диештеләр. Ахун дәфтәрен ачып язды да бу икегә кул куярга бирде. Болар, иске «мәптектә» дүртәр ел гына ятып, бик күп таяк-чыбык ашап чыксалар да, язу белмиләр иде. Берсе (> — ) рәвешендә сәнәк тамга, икенчесе (□ — ) рәвешендә көрәк тамга салды.
Кызның кияүгә бирелүе рәсми шуның белән бетте. Мулла дәфтәрләрен, кара-каләмнәрен кире букчасына тыкты, һәр туйда, һәр никахта, шулай бeлә торып, кыздан барып сорамауларын ачык күрә торып, ике ялган шәһитнең риза дип әйтүе буенча эш итүен уйлады, ләкин озак тукталмады, чалмасын төзәтте, йомшак юрганга тезләнеп утырды да акрын танау тавышы белән:
— Әлхәмделиллаһи, әлхәмделиллаһи, әлхәмделилаһил-ләзи, әнникяхе сөннәти... — дип, никах хотбәсен башлады.
Бу гарәпчә иде. Бер кеше дә бернәрсә дә аңламады, тизрәк бетсә иде, тизрәк аш килсә иде дип теләп утырдылар. Ишеккә якынрак урнашканнардан бер мужик йокыга китте, башы калгый башлады, борыны әче-әче сызгырырга тотынды. Аны төртеп уяттылар. Мулла үзенең меңгердәвен суза бирде.

X

Ирләр белән бер үк вакытта теге якта хатыннар мәҗлесе бара иде. Бөтен никахны алар да ишек аркылы ишетеп тордылар. Мулланың хотбәсе буенча Фәтхия әби, һичбер нәрсә дә аңламаса да, үзен тыя алмады, — елап, үксеп, яулык белән туктаусыз күз яшьләрен сөртә-сөртә утырды. Үзен дә уйлады, актык кызы икәнен дә, каты каенанага китүен дә уйлады. Бәхетле булырмы икән, тәкъдирдә ни генә язган икән дип тә соранды. Шулар барлыгы җыелып килеп, аның карт күңелен йомшарттылар. Никах хотбәсе беткәнче хәсрәтле ана шул дулкыннар эчендә кайнады.
Теге якта акча шалтырый башлау гына хатынны бу уйлардан чыгарды.
Нурый карт каты куллы, саран мужиклардан санала, ләкин бүген бик артык сынатасы килмәде, каршы якның исемле Шибай кантун булуы да, мәҗлескә бөтен Караюрганың зурлары җыелуы да бераз сыкратып, аның кесәсен киң ачтырдылар.
Хотбә бетеп, дога кылынуга, ул табынга җәелгән зур ашъяулыкның бер башын читкәрәк каерып куйды да, тезләнеп, хәзрәтләр алдына таба сузылды, алдан әзерләнгән садакаларын үзенең күптән, алдан билгеләп куйган исәбе буенча өләшә башлады. Никах укыган Шәрип муллага өч сумлык яңа кәгазьне төртте; бу инде саран Нурый өчен бер дә аз түгел иде. Фәйзулла мәзиннең өлеше бу

тирәнең бай туйларында да илле тиеннән күп артмый иде. Юмартланган хуҗа аңар да бер сумлык бер көмешне сузды. Бу аңа бик ярап калды: аның хатыны ничә анлардан бирле һәркөн: «Туныма тышлык ал, туныма тышлык ал, кеше күзенә күренерлегем калмады, хәерче кебек йөрим», — дип, моңың колак итләрен ашый иде. Кергән бер садаканы дөньяның көндәлек хаҗәтләре йота барганга, моңарчы остабикәсенең ул тавышыннан котыла алмады; ләкин менә бу атна эчендәге туйлар, никахлар, мәҗлесләрдә ул инде, башка кирәк-яракны бер якка ташлап, һәрбер кергәнне шул тышлыкка каратып җыя барырга уйлады. Тагы ике никах бар. Алар иллешәр тиен бирерләр, аннан соң менә Сәлимә карчык үлем алдында, хәл эчендә ята, кичә дә ясингә чакырдылар. Бүген-иртәгә үләр. Аның фидиясенә кара башмакларын бирсәләр, мәзингә бер өч тәңкә җыелыр, — менә шулай тартып-сузып торгач, алдагы атнаның базарынача кирәк акча тупланыр. Шулай уйлап, мәзин бер сумлык тәңкәне кесәсенә тыкты.

Нурый, тезләнгән көе кузгала биреп, чит мәхәлләләрнең муллаларына берәр сумнан, мәзиннәренә иллешәр тиеннән таратып чыкты. Тагы ике фәкыйрь мәчет карты бар иде, — аларга да бишәр тиеннән ике бакыр төртте. Шуның белән бу зур эшен бетереп, аякка басарга өлгерә алмады, кияүнең атасы өлкән кода садакага дигән акчалары өчен бишмәт кесәсенә тыгылды.

Шибай карт заманында зурлык, байлык белән гомер итте. Башкорт эчендә кантун булып торган чакларында һәркайда үзен өлкән тотарга, халыктан кадер-хөрмәт иттерергә гадәтләнеп калды. Башкорт җирләрендә кантун-лыклар бетерелгәч тә ул, гәрчә элекке байлыгы кимесә дә, элекке дәрәҗә китсә дә, һаман да бөтенләй егылудан ерак иде. Иген белән, җир-су белән, умарта белән дөнья көтте. Электән бергә ашап, бергә эчкән урыс түрәләре дә бөтенләй ташламадылар, кирәк чакта арка терәк булдылар. Инде сакалы ап-ак булып, яше җитмешкә җиткән карт һаман да ил эчендә үзенең олылыгын саклап килә алды. Тирә-якта аларның авыллары Бикьярны: «Көяз», — дип, «Бикьяр көязләре», — дип, «Бикьярлар кебек көяз», — дип мыскыллабрак сөйлиләр. Шибай картта да бу көязлек бар. Туйга килгәндә дә ул атларының, чаналарының, киемнәренең, күчтәнәчләренең кеше алдында оятка калмаслык булуына бик тырышты; үзенең бик кадерләп саклаган иң яхшы казакиларын киде, читеген төзәттерде; сәгать бавы өзелгән иде, көмешче киявеннән аны эшләтте, каладан яңа Казан кәләпүше алдырды. Никах хөтбәсеннән соң садака өләшүгә дә, бу туй өчен муеннан бурычка батуына карамастан, бик нык әзерләнде. Хуҗа кода үз эшен бетереп аякка басуга, ул иң элек уң як кесәгә тыгылды, аннан бер сумлык бөтен көмешләрне учлап алды да башта Шәрип ахунга икене сузды, чит мәхәллә муллаларына берәрне төртте; аннан сул кесәгә

тыгылды, илле тиенлек көмеш алып, Фәйзулла мәзингә бирде; күкрәк кесәсеннән чыгарып, бүтән мәхәллә мәзиннәренә утызар тиен, ике мәчет картына бишәр тиенлек бакыр таратты. Садака артыннан бөтен мәҗлес күзен калмый карап торды; һәркем монда гаеп эзләүчән, чыккач гайбәт сөйләргә, көләргә әзерләнүчән була. Ләкин Шибайныкын ярыйсы таптылар, тик Фәйзулла гына чын күңеленнән рәнҗеде. Үз эченнән: «Көяз туңмас — калтырар», дигәннәре менә шул инде, бу картның даны юккарак чәчелгән икән. Башка мәхәллә мәзиннәренә егермешәр тиен дә җитәр иде, әмма төп коданың, кызның мәхәлләсендәге карт мәзинне чит мәхәлләнең имамнарыннан кимсетмәскә кирәк иде, туңбаш мужик шул, кантун булып ил таларга өйрәнгән, менә шундый нәрсәгә өйрәнә алмаган», — дип, озак әрнеп шелтәләде. Садакалар соңында бөтен мәҗлес кул күтәреп дога кылганда да явыз шайтан аның күңеленә һаман шул шелтәләрне сала торды. Ләкин бөтен мәҗлестә һичкем аның эчке рәнҗүен сизмәде, — киресенчә, һәммәсе бик мактап, зурлап, һәр ике якка бәхет, мәхәббәт теләп, умарта корты кебек гөжжж... килеп сөйләшә, шаулаша башладылар. Шул шау-шу эчендә баягы шаһитләрнең яшьрәге Вәлиморат акрын гына торды, чикмәнен, бүреген, чабатасын киде дә өндәүче Чокыр Хәбип йортына, кияүдән никах сөенчесе алырга дип чыгып йөгерде. Монда мәҗлеснең аш-сулары башланды.

Иң элек кодаларның ашларын, туй күчтәнәчләрен мәҗлескә чыгарып күрсәттеләр. Тупасрак, саграк тормыш белән көн иткән караюргалар алдында көяз бикьярларның китергән аш-сулары чыннан да искитәрлек булды. Табынга сыйдыра алмый аптырадылар.

— Менә бусы өлкән кода Шиһабетдиннеке.

— Менә бусы Әфтәх коданыкы.

— Менә бусы Алтынбай коданыкы, — дип атый-атый, чыгарылган әйберләр мәҗлес халкы алдында тау-тау булып өелде.

Арада иң шәбе, әлбәттә, Шибайныкы булды. Аның майлары тулышып торган ике симез казы белән симез күркәсе, өсләренә каклар, җимешләр сибеп пешерелгән дүрт зур ләвәш күмәче, кечкенә дүрткел тау кебек торган, өсте-читләре кәнфит белән чәчәкләнгән зур ике баллы бавырсагы — тагы әллә ничаклы оста әзерләнгән аш бүләкләре мәҗлеснең күзләрен уйнаттылар. Болар тирәсендәге бер батман ак кәрәзле бал, бер пот май, катлауланып килгән симез билдәмә, кадаклы яхшы чәй кебекләр инде бөтенләй югалып калдылар.

Чынлап хәйран булып, карап, мактап, һәрберенә: «Ай, рәхмәт, һай рәхмәт, бик зур килгәннәр икән, кызыбызга зур хөрмәт күрсәткәннәр икән! һай рәхмәт, бик рәхмәт!» — дип туктаусыз шаулашып, мулла артыннан кул күтәреп дога

кылдылар да кодаларның күчтәнәчләрен кире теге якка чыгардылар. Аннан инде мәҗлесне сыйлау өчен йорт хуҗасы Нурый картның ашларын бирә башладылар.

Бусы инде Фәтхиянең һөнәрләре, байлыклары, тырышлыклары иде.

Мәҗлес югары, түбән ике табынга аерылды.

Югарысында Фәйзулла мәзин, түбәнендә Хаҗиморат табынчылык кылдылар. Зур кызыл ашъяулыкны болар җәйде, ишектән түргәчә сузылган тоташ салфитны болар таратты, тәрилкә-кашык, тоз, борыч, икмәк, катык — һәммәсе болар каравы белән кирәгенчә урнаштырылды.

Иң элек ике зур агач табакта өсте май белән капланган токмачлы шулпа чыгардылар. Чүмечләр туктаусыз әйләнде. Бер-бер артлы тәрилкәләр зур табакка йөреп торды, тәрилкә-кашык тавышы белән өй тулды. Токмач артыннан йомшарып пешкән симез билдәмәләр килде. Болар турамаган иде, Фәйзулла мәзин белән Хаҗиморат гаҗәп бер осталык күрсәттеләр: тиз-тиз пычак уйнатып, итне, бәрәңгене, салманы турап, кызу, кайнар шулпа белән өстәл хәзерләп куйдылар. Икенче табынчы бүлә торды. Тагы тәрилкәләр табын уртасындагы сай таштабактан әйләнеп йөри торды, тагы кашык-пычак тавышы белән мәҗлес капланды. Билдәмә артыннан симез каз белән симез үрдәк, аннан бәлеш, иң ахырдан никах ширбәте килде. Бу соңгыларда Фәтхия әбинең бөтен утыз ел хатынлык гомерендә җыйган барлык һөнәрләре чыкты. Бәлешне ашаганда мактап бетерә алмадылар: «Тәме-тәм, телеңне йотарсың, төбе, камыры кетердәп тора», — диешеп, зур таба төбендә тик оятлык кына калдырдылар. Ләкин аннан да бигрәк ширбәт булды. «Төпчегем бит, актык кызым, актык туем», — дип тә уйлады; «Бикьярлар үзләре хәерче булса да, көяз халык, гайбәтчел халык, гаепләп китмәсеннәр», — дип тә тырышты; «Сабира кодагый бик телчән, бик шелтәчән нәрсә диләр, аш-суының юне юк, кызлары да шулайдыр, — дип, — яманларга урын таба алмасын», — дип борчылды. Шулай янды, көйде, бар белгәнен эшләде; иң ахырдан, менә рәхмәт төшкере, теге яңа гына кайткан үги килен Мәрхәбә дә ширбәткә оста булып чыкты: «Тукта, әнкәй, әз генә шикәрен өстик, бик әз генә чия суы кушыйк», — дип кайнаша торгач, хуҗа хатынының элекке әзерләгәненә караганда тагын да тәмлерәк ясап куйды. Мәҗлестә моңа авыз гына тидерделәр, тәмләп-тәмләп өчәр генә йоттылар, шунда да үзара:

— Фәтхия апаның кулы гаҗәп икән! Телеңне йотарсың, шундый тәмле! — диешеп, өзлексез сөйләнеп, мактап, күтәреп шаулаштылар.

Ширбәт алынуга ике табынга ике салфит җәелде. Һәркем, хәлле-хәленчә, бакырдан, эреле-ваклы көмештән акча салдылар. Тагы озаклап дога кылынды.

Инде шуның белән никах мәҗлесенең төп өлеше тәмам булды. Түбәнге табындашларның күбе кузгалып, чыгар ягын карый башлады. Ләкин хуҗа боларны туктатты:

— Рөхсәтем юк! Яше-карты – һәммәсе чәйгә калсын, — диде.

Табакларны, тәрилкә, кашык, пычак, тоз, икмәк, борыч — һәммәсен җыеп алдылар, яңа ашъяулык җәйделәр. Чәй әзерләделәр.

Гөжләп кайнап торган зур ак самавыр уртага утырды; Фәйзулла мәзин белән Хаҗиморат, чынаякларны, бал-майларны, хәзер генә табадан төшкән коймакларны, ләвәшләрне, кечкенә бәлеш, бавырсакларны тәрилкә-тәрилкә кунаклар алдына таратып, чәй ясый башладылар. Тагы чынаяклар, тәрилкәләр шалтыравы белән табыннар тулды.

XI

Көтелмәгәндә килеп төшкән үги килен бөтен мәҗлес вакытында гаҗәп дәрәҗәдә кирәкле кул булып китте.

Каенанасы башта күрешеп, бер генә җылы сүз әйткәч тә, ул, хәзер алъяпкыч бәйләп, эшкә тотынды:

— Бозар дип курыкма, әнкәй, мин анда аш-су эчендә күп кайнаштым, — диде дә хуҗа хатын өстендәге мәшәкатьләрнең яртысын үз җилкәсенә күтәрде.

Фәтхия яхшы күңелле, юаш ана булса да, киленнәре белән гомере барынча килешә алмый йөдәде. Зур уллары Төхфәтнең хатыны Мәрфуга килен бик явыз телле, үзсүзле иде. Эшкә осталыгы булса да, әче сүзе, каршы әрләшүе белән каенананың җанына тоз сала торды. Ун ел шулай этле-мәчеле көн иткәч, энесе солдаттан кайтып өйләнгәнне генә көттеләр дә, ата-ана белән талашып, бер нәрсәсез аерылып чыктылар. Тик ахырдан гына акрын-акрын ара төзәлде, Нурый аз-маз ярдәм иткәләде. Хәзер инде ата-ана, ул-килен булып катнашып, кунаклашып йөриләр. Шулай да бу Мәрфуга килен эшләп кинәндерми, көе килгәндә бик әйбәтләп булышкалый, бер нәрсә ярамаса, хәзер тырт-мырт, тырт-мырт итә дә, үпкәләп, әче телләнә башлый. Уртанчы киленнең алай начар теле дә юк, холкы да бик әйбәт. Әнкәй дип тыңлап кына тора; ләкин аның кулыннан бер эш килми; ул хәлле ата-ананың бик көтеп алган, кадерләп үстергән ялгыз баласы иде, иркә үсте. Бер эшкә дә өйрәнмәде. Каты сүз дә күтәрми. Килен булып төшкәч, бу йортта берни белмәде, орышсаң: «Ни эшлим соң, әнкәй, мине өйрәтмәделәр», — дип елый торган булды. Аның атасы кинәт үлеп китте, йорт-җире анасы кулында калды. Менә шуннан файдаланып, бу икенче улы Шәйгәрдән белән аның назлы, иркә хатыны, Нурыйны ташлап, тегендә күчтеләр. Егет хатын анасының йортына керде. Назлы, иркә килен Гыйззелбәнат та каенанадан котылды, үз анасының канаты астына кереп яши

башлады. Төп йортта хәзер Фәтхия кулында кечкенә улы Шәймәрдән белән аның хатыны Шәргыя эшлиләр. Бу килен сүзсез, талашсыз булып чыкты, кара эшкә гаҗәп батыр. Ялан, ындыр хезмәтләрендә, уракта, печәндә, ашлык сукканда ирләр белән янәшә бара. Йортның һәммә мәшәкатьләрен — сыер савумы, сарык-кәҗә караумы, кыш көне бозаулар, бәрәннәр имезүме, утын кертү, су ташу кебекләрме, көндәлек аш пешерү, самавыр кую, мич ягу, идән юуламы — һәммәсен, һәммәсен җимереп эшли, белеп, тәмләп, яратып эшли. Әмма инде әз генә нечкәрәк нәрсәгә барырга туры килсә, осталык кирәк булса, аның кулы туктый. Белүе дә юк, дәрте дә юк, кайгысы да юк. Фәтхия әби үзенең бу киленен ярата: «Безнең Шәргыя килен карар, Шәргыя килен белер, Шәргыя килен юнәйтер», — дип, аңар сылтый тора. Ләкин кадерле әйберләрдә, кунак-төшем, мәҗлес чорларында Шәргыя килен аның үзе уйлаган осталыкларын берсен дә башкара алмый. Болар һәммәсе моңарчы каенананың бер үзенә йөкләнеп килделәр. Менә бүген бу көтелмәгән үги килен генә хуҗа хатынының уң кулы булды да китте. Җитмәсә тагын, кайбер турыларда каенананың үзеннән нечкәрәк, остарак та ясап куя. Туй мәшәкате моның кебек күп сүзле бер вакытында Мәрхәбәнең болай кул астына керүе Фәтхиянең өстендәге тавын җиңеләйтеп җибәргәндәй булды. Ул үзе өлгермәгәндә: «Мәрхәбә килен, мә моны тура. Мәрхәбә килен, менә моның тозын кара. Мәрхәбә килен, мичтәге бәлешләрне алырга вакыт түгелме?» — дип, тапшыра гына торды. Кодаларның күчтәнәчләрен күрсәтергә чыгарганда да, мәҗлескә аш-су, шулпа, бәлеш, билдәмә, каз, үрдәк, ширбәт, чәй, коймак, каймак биргәндә дә, һичбер эш Мәрхәбәгә киңәшсез, Мәрхәбәнең ярдәменнән башка үтмәде. Каената йортына, хур итеп куып чыгармасалар ярар иде, дип килгән үги килен үзенең болай тиз эшкә ярап китүеннән иксез-чиксез шатланды, күптән өйрәнгән, бик яраткан бу эшләр эченә, тирән суга җибәрелгән балык кебек, рәхәтләнеп йөзеп кереп китте.

Ләкин бер генә, тик бер генә нәрсә туктаусыз аның йөрәк тамырын кимерүдән туктый алмады.

Уралдан, Алатаудан үз илләре Караюргага кайтып җиткәнче, юл буенча, Мәрхәбә белән Шәйхел киңәш корып килделәр. Туры Нурый картка төшәргә булдылар. Ерактан килгән мөсафирларны куып чыгармас, ил шелтәсеннән дә куркыр, диделәр. Моның эчендә Мәрхәбәнең үзенең аерым исәбе булды. Каената йортына кайтып төшәчәк, бүләкләр белән күңелләрен ауларга тырышачак, аннан, берәр чынаяк чәй эчеп, елашып, фатиха алгач, тиз генә үзенекеләргә — авыл читендәге читән өйгә йөгерәчәк. Ара ерак булса да, Алатауга сирәкләп хәбәр килгәләде. Анасы Мәргыя карчыкның авыруын,

кылтамак чирен[1], эченә аш үтмәвен, капкан бер нәрсәсе кире чыга торуын Мәрхәбә тегендә чагында ук ишеткән иде. Аннан, шул кылтамак чире көчәеп, кибеп үлүен сөйләделәр. Хатын юл буенча исәп йөрткәндә бу турыда да уйлады; каберенә барып, Коръән укытырмын, мәзин бабайны гына чакырып булса да, аш-чәй ясап, елын уздырырмын дип өметләнде. Әткәсенең исәнлеге турында да хәбәр килә торды. Тик апасы Гөлйөземнең ире Мортаза[*] җизнәсе хакында гына бернәрсә дә ачык беленмәде. Апасы Гөлйөзем, каенаналары белән килешә алмыйча, ире югалгач, кире Челем бабайга кайткан икән, дип бирәү сөйләде.

Үзенә туган булган менә бу хәлләр, бу хәбәрләр, бу кешеләр Мәрхәбәнең йөрәгеннән бер минут та чыкмадылар. Фәтхия әби белән бергә аш-су эчендә кайнаганда ул үзе эченнән һаман: «Менә бусын гына эшлим, менә бусын гына юнәйтим, менә бусын гына бетерим», — дип, китү ягын уйлаудан туктамады; ләкин зур туй, өлкән никах мәҗлесе аны үзенә суырганнан-суыра бирде; бер эшкә икенчесе, өченчесе ялганды; токмачка бәлеш, аңа билдәмә, аңа каз-үрдәк, аннан ширбәт, чәй килеп тоташты. Тик менә ирләргә дә, хатыннарга да зур самавырлар бирелеп, чынаяклар чалтырый башлагач кына, ул инде түзмәде, бик ялынып Фәтхия әбигә карады:

— Әнкәй, — диде, — бик тиз әйләнермен, мин үземнекеләргә кайтып кына килим, — диде.

Хуҗа хатын гаҗәпсенү тулган күзләре белән үги киленгә борылды:

— Ходаем, нинди гөнаһ булды! Шаһвәли коданы никах мәҗлесенә чакырырга оныткaнбыз бит! Менә Ходаем, үзең кичерә күр! — дип, ялчы фәкыйрь Челем бабайның читтә калуының гаебен капларга тырышты.

Мәрхәбә эшнең бу ягына кагылмады. Ул Нурый белән Челем бабай арасында алай мәҗлескә чакырышып, кодалык күрсәтү кебек хәлләрнең була алмавын ачык белә иде. Тизрәк ычкыну юлын карады. Берьюлы йомшарып киткән Фәтхия үзенең мәҗлескә чакырылмаган кода-кодагыйлары өчен дип бер ашъяулыкка пешкән итләр, кисәкле бәлешләр сала башлаган иде, килен моңа да риза булмады:

— Хәзергә кирәкми, әнкәй, менә минем алып кайтканнарым да әз-мәз бар, — дип, бер төенчекне култык астына кыстырды да чыгып йөгерде.

Бураннан соң җир-күк хәл җыярга туктагандай күренде. Ерак йолдызлар салкын һава эченнән тагы да яктырак янган бриллиантлар, алмаслар булып күз алдында уйнадылар. Мәрхәбәнең битен, колагын кичке салкын чеметеп-

[1] *Кылтамак чире* – үңәч рагы
[*] Алга таба текстта Гөлйөземнең ире Усман исеме белән аталган.

чеметеп алды. Ул бернәрсәгә дә карамады, зур урамнан сулга, кечкенә тыкрыкка борылды. Анда юл да, сукмак та юк иде. Көннәр-төннәр буенча яуган йомшак карны ерып, урыны белән бөтенләй чума-чума, арткы кечкенә фәкыйрь урамга чыкты. Тагы шундый ук юлсыз, сукмаксыз барып, авылның читенә җитте.

Тирә-як — кар диңгезе. Тирән, ак, йомшак көрт һәммә нәрсәне каплап ята. Тик ара-тирә өй, азбар башлары, биек кое баганалары гына күренәләр. Менә бер калку. Шуннан куе ак төтен чыгып, салкын тыгыз һавада аз гына да җәелмичә, таралмыйча, зур калын багана кебек, туры күккә менеп тора.

Хатын юл тапмады, тар сукмакны да югалтты. Ләкин бу аңа гади әйбер иде; төенчеген кочаклады, итәкләрен төреп тотты да, өйнең элекке төзелешен исәпләп, чама белән аның ишегенә таба шуып төште. Һәм ялгышмады. Бөтен тирә-якны күмеп киткән көрт өйнең ишеге, стенасы буйлап ярты аршин киңлегендә бушлык калдыра икән. Шуның белән ишек буен тапты, читән ишекне эчкә этәреп җибәрде; үзе чолан үтәсеннән эчке ишекне эзләп тапты, аны да этәрде; яртылай җир астына казып салынган җир идәнле, карындык тәрәзәле, балчык белән сыланган читән стеналы өйгә басып керде.

Ярым караңгы иде. Почмактагы сәкедән берәүнең ыңгырашканы ишетелде. Мич алды кызгылт ялкын белән яктыртылган. Анда ертык күлмәкле ябык бер хатын белән җиде яшьлек малай утта кызыналар. Кинәт ишек ачылып, өсте-башы бөтенләй кар белән сырылган, кулына төенчек тоткан кеше килеп кергәч, ябык хатын башын күтәреп карады.

— Кем ул? — дип сорады.

Кунак якын ук килде, өзгәләнгән тавыш белән:

— Әткәй кая соң? — дип, апасы Гөлйөземгә ташланды. Кечкенә малайны ашыгыч-ашыгыч сөйде.

Шул ук вакыт сәкедән ыңгырашкан авыру кузгалды:

— Мәрхәбә балам, син түгелме? — дип, башын күтәрде, иске чикмәне белән капланып торып утырды. Бу — Мәрхәбәнең атасы Челем бабай — Шәвәли карт иде.

Кунак хатын әткәсенә килде, аның битләрен, кулларын күз яше белән чылатып бетерде:

— Әткәй, әллә авырыйсыңмы? Ни эшләп ятасың болай? — диде.

Карт иске, кипкән тавыш белән өзеп-өзеп җавап кайтарды:

— Ятмый ни эшлим, кызым?.. Алтмыш ел эшләдем бит!.. Мин эшләмәгән нәрсә калды дисең?.. Шул җитмиме? — диде.

Аның тәне ябыгып кипкән, битендә, маңгаенда аз гына да ит, май әсәре

калмаган; карт-ябык тире, каралып, саргаеп, сөякләренә ябешкән. Эре кара тамырлары кулларында, битләрендә вак кара елан балалары кебек сузылып-сузылып капланганнар. Шулай да аның тәнендә тереклек куәте сүнмәгән иде әле. Чикмәнен җилкәсенә салды, тәмәке янчыгы белән челемен алды да мич алдына яктыга килде:

— Ярар, — диде, — күрмичә үләрмен дип кайгырган идем, кайттың, — диде. Сүзне кылтамак авыруыннан үлгән карчыгы Мәргыя әбигә күчерде: — Менә, — диде, — ананың да башка сүзе булмады, елады да сине сагынды, елады да сине сагынды, шулай елап аяк сузды, — диде. Үзе, янчыгыннан яфрак тәмәке чыгарып, челемен тутырды, мичтән утлы салам алып яндырды да, кунак кызы белән сөйләшә-сөйләшә, төтенләп тарта башлады.

Ул быел җәй күрше урыс авылында, Сашка дигән урыс крестьян баеның кыяр-кәбестә, кавын бакчасын каравыллаган иде. Шунда чәчелгән тәмәкенең яхшысын сайлап, кояшта киптереп эшләде. Ашарга беткән, ягарга салам да тапмый туңып утырган чак күп булды, ләкин шул җәйге байлык — тәмәке өзелмәде. Эч ачлыктан бик бора башлаган чакларда, ул үзенең иске дусы чуаш Емельян бүләк иткән чакма ташын чыгарып, челем кабызып тарта, шуның белән карын бераз тынычланып киткән кебек була иде. Ул яшьрәк заманда Мәсәйлебаш дигән чуаш авылында, бер карт чуаш баенда ундүрт ел ялчы булып торды, бу челемгә шунда өйрәнде. Аңа картлар да, мулла, мәзин дә бик әйтеп карады, ташла моны, диделәр; ул колак салмады, кешедән яшермичә үк тарта торган булды. Шуннан аңа балалар «Челем бабай» дип ат та куштылар. Моңа аның аз гына да исе китмәде, рәнҗергә дә уйламады. Балалар бит, әйтсәләр әйтә бирсеннәр!

Карт белән бергә аның ике кызы, башта аннан йолкып, моннан йолкып, бер әйбердән икенчегә сикереп, күп нәрсә өстеннән үтеп, сөйләштеләр. Шул сүзләр арасында кунак хатын Мәрхәбә үзенең төенчеген чиште, иң элек кызыл киҗеле ашъяулык чыгарды, аннан пешкән зур казылык, майлы күмәч, бик зур бодай икмәге алды. Боларны күреп, малайның күзләре ут булды. Бирәме икән дип йотылып катты. Гөлйөзем мич буеннан иске нәзек чалгы пычагы алып, Мәрхәбәгә тоттырды; кунак зур бер телем күмәч белән берничә кисәк казылыкны малай алдына куйды, ләкин бу ышанмады, аптырап, әнкәсенә карады. Ябык хатын, елмаеп, улының аркасыннан сөйде:

— Курыкма, ал, балам! Ят кеше түгел, синең апаң бит бу, — диде.

Бала тиз-тиз алды да ашыгып ашарга тотынды. Зурлар арасында озын-озак сүз китте.

Ябык, кайгылы Гөлйөзем, өзелеп-өзелеп, үзенең солдатта югалып калган ире

Усманны сөйләде.

XII

Караюргада ул чакларда елкылар өчен көтү ясау гадәте бар иде. Ат көтүчесе Усман дигән егет Гөлйөземнең күңелен бик яшьли сихерләде; ике ел йөргәч, шуңа кияүгә дә чыгып куйды. Шәвәли карт әйтте:

— Ашыкмау кирәк иде, кызым. Солдат буласы бар бит. Ул китеп барса, бала белән калсаң, ни эшләрсең? — диде.

Ләкин кыз моңа карамады, карарга җае да булмады: бу вакыт аның карынында Усман егеттән дүрт айлык баласы бар иде. Солдатка китеп барса, ни хатын түгел, ни кыз түгел кебек уртада калудан курыкты:

— Илдә чыпчык үлми дигәннәр, дүрт ел түзәрмен әле, — дип уйлады. Шулай уйлап, иргә барды.

Өйләнешкәч үк үзләре кебек бер ярлыга өйдәш керделәр. Боларның иманасы да, җире дә, урманы да, болыны да, кагарга бер казыгы да, мал дияргә бер сукыр тавыгы да юк, ләкин дөнья җимереп эшләргә ике пар таза кул гына бар иде. Шуның белән тормыш корырга керештеләр. Кыш ничек тә үтәр, бер җәй боярга урак-печән эшләсәк, көзгә кечкенә өй сала алырбыз, икенче җәй ат-арба алырбыз, өченче җәй үзебез ашлыкны күбрәк чәчү ягын кайгыртырбыз, — менә шулай акрынлап аякка басарбыз дип, исәп йөрттеләр. Ләкин җил бераз кире яктан исеп куйды.

Өйләнешкән көздә үк егетне гаскәр хезмәтенә алдылар. Ул зур буйлы, таза гәүдәле, карасу күзле үткен ир иде. Флотка эләкте. Патша тора торган каладан ерак түгел бер диңгез бар икән, ди, шунда сугыш караблары йөриләр икән, ди. Усманның беренче хат-хәбәрләре менә шуннан килде. «Җыен урыс арасында мин бер үзем, дигән, үзебезчә яздырырга кеше юк, дигән, миңа да урысча гына яздырырсың», — дигән.

Гөлйөзем, бу хатларны алгач, укытырга кеше тапмый аптырады. Авылда атнага бер тапкыр базар була. Шунда күрше авылның яшь учителе Шакир мирза дигән берәү килгәли. Хатын шуны сагалап торды, шуңардан ялынып укытты, шуңардан ук иренә хат та яздырды.

Еллар үтте. Инде кайтыр чагы якынлап килә иде. Менә бервакыт хәбәр-хәтер киселә. Җәй, көз, кыш, яз — бер-бер артлы кичәләр. Усман үлеме, тереме? Диңгезгә баттымы? Балык йоттымы? — һичбер нәрсә билгеле түгел. Кайгы-хәсрәттән кая ташланырга аптыраган Гөлйөзем ни эшләргә белми башын югалтты. Бераздан бер сүз таралды: Усман белән бер калада хезмәт иткән урыс егете кайткан, имеш, ул белә, имеш, диделәр. Хатын кечкенә баласын алды да шуны эзләп күрше авылга китте. Солдат тиз табылды, ләкин ул татарча белми,

хатын урысча бер сүз дә аңламый иде. Бернәрсә сөйләшә алмыйча кире китәргә торганда, Бикьярның бер кырыктартмачы татар сәүдәгәре туры килде, ул аз-маз урысча сукалый икән. Егет шуны кычкырып чакырды, безгә тылмач бул, диде, үзе күргән-белгәнен сөйләп бирде. Кырлайчы[1] татарның урыс солдат егет теленнән алып хатынга аңлата алганы шул булды:

Бу урыс Усман белән бергә солдатка алынганнар. Бергә хезмәт иткәннәр. Ел тулып, котылыр вакыт җиткәч, бергә-бергә кайтырга дип дәртләнеп йөргәндә, тегене тотып ябалар. Нәрсә өчен? Һичбер ни белмим, ди.

Хатын, бу зур бәхетсезлектән елап, шешенеп, акылдан язып кайтты. Эшнең башын, ахырын, үзәген белә алмый мие, йөрәге әйләнде. Шәвәли карт үзе моңа катнашып бакты. Белгән-күргәннән сорашты. Ләкин төпле бер әйбер чыгара алмады. Тик теге эт авыз урядникның гына исерек баштан базарда сүгенеп утырганын сөйләделәр:

— Әйтә, имеш, ди, Челем картның кияве Усман да бик сикеренгән иде, анда кирәген биргәннәр үзенә, дип әйтә, имеш, ди. Ике бозауга кибәк аера алмаган башы белән ул маңка малай анда патшага каршы матрослар тозагына барып капкан, имеш, дип әйтә ди. Менә шулар белән җиде кеше арасында Усманны да тотып япканнар, имеш, дип әйтә ди. Анда, дип әйтә ди, тау өстендә дүрт почмаклы таш койма бар, имеш; шуның бер почмагында мылтыклы солдат тора, имеш, кеше якын килсә, сорамый-нитми ата, имеш, дип әйтә ди. Бу койма эчендә тагы шундый бер таш койма бар, имеш, аның да дүрт почмагында мылтыклы дүрт солдат тора, имеш, моның эчендә тагы койма, тагы дүрт солдат, имеш, менә шуның эчендә калын стеналы биек сары таш пулат бар, имеш, шуның кечкенә тәрәзәләре бар, имеш, болар бары да беләк калынлыгы тимерләр белән коршалган, имеш, дип әйтә ди. Усманны менә шул тимерле тәрәзә эчендә бер бүлмәдә, бер ялгызы тимер богауларда саргаеп, кибеп утырганын күргәннәр, имеш, ди. Аннан соң, ди, җиде кешене берьюлы алып чыкканнар да, имеш, ди, таш коймага терәгәннәр, имеш, ди; кырык солдат берьюлы кырык мылтык төзәп, берьюлы атканнар, имеш, дип әйтә ди. Урядник әйтәдер, ди: мин аңа монда чакта да әйттем, дип әйтеп әйтә ди, син, егет, чамалап маташ, бер эләгерсең, иллә-мәгәр нык эләгерсең, дип әйтеп әйттем мин аңа, дип әйтә ди, ул минем сүземне колагына да элмәде, дип әйтеп әйтә ди...

Тол хатын Гөлйөзем белән Шәвәли карт бу авыр язмышны озаклап, кабатлап сөйләгәндә, Мәрхәбә һаман күзеннән яшен сөртә-сөртә утырды; шуның белән бергә төенчеген бөтенләй чишеп, аннан бүләкләрен чыгара торды. Иң элек атасына бер калын бишмәтлек белән сырырга ике кадак төя йоны бирде;

---

[1] *Кырлайчы* – вак-төяк белән сәүдә итүче

кечкенә малайга түбәтәй, бишмәтлек, апасы Гөлйөземгә күлмәклек, тагы шундый нәрсәләр өләште. Боларны күргәч, карт, челемен бер якка ук куеп, кызына гаҗәпсенеп карады:

— Нәрсәләр бу чаклы?! Әллә анда ирең кеше суеп мал җыямы? — дип көлде.

Кунак хатын Уралда, Алатауда үзләренең ничек көн итүләрен, кәсепләрен, чана табаннарын, бөятләрен, тугымнарын сөйләде; дәртләнеп, андагы курайларны, кымызларны, җәй көне тауга чыгуларны тезеп китте; ләкин ахырын көтелмәгәнчәрәк бетерде:

— Шулай да, — диде, — монда кайтыр идек; Караюрганы бик сагынабыз, җиренең ямен тапмыйбыз, суының тәмен тапмыйбыз, — диде.

Гөлйөзем ялгыз фәкыйрь тормыштан 'бик йончыган иде. Сеңелесенең бу якка тартылуы аңа бер иптәш бирер кебек булды:

— Сагынсаң, нәрсә тора? Җыен да кайт, — диде. Мәрхәбә актык серен ачты:

— Сөйләмә, апа! Кайтыр идек, бик кайтыр идек. Ирем әйтеп тора: атай фатиха бирсә, җиреннән әзрәк өлеш чыгарса, бик кайтыр идек, ди...

Аңарчы тик сабыр утырган карт кинәт хахылдап көлеп, кулларын җәеп җибәрде:

— Их... Их!.. Менә инде исәп!.. Җаны бугазына килсә, яртылай гүргә керсә, анда да ул Нурый эттән бер адым җир ала алмассың! Мин аңарда җиде ел ялчы булдым, җилкәм чиләнгәнче эшләдем, актыкта тияремне басып калды: кигән чикмәнемне суеп алды! Менә кем ул синең каенатаң! Шәйхел тиле икән! Юк исәп белән йөрмәсен, бирмәс, бирмәс! — диде.

Карт, тагы эчкәрәк китеп, кыска ачы сүзләр белән Нурыйны сүгә башлаган иде, ишек ачылды, анда байның ялчысы — ябык, яшүсмер Мифтах килеп керде:

— У... Шәвәли бабай, үзеңне көрт басып бетергән бит! Чак таптым!.. Кунак җиңги, әйдә, сине Фәтхия әби чакыра, тиз генә килсен, ди, аннан, ди, мин үзем аны теләсә ат белән илтеп куйдырырмын, ди.

Гөлйөзем, чиләк белән кар кертеп, чәйгә эретер өчен казанга салды, кунак сеңелесе китергән күчтәнәчләр белән улын, атасын сыйларга әзерләнә калды. Мәрхәбә яңадан киенде дә, сез йоклаганчы килермен әле дип, яшь ялчы белән бергә чыгып китте.

Карга бата-чума, Нурый картның туйлар, кодалар кайнаган йортына кайттылар.

XIII

— Бар, киленкәем, тиз, кияү бүлмәсен кара. Минем кулым тими, адәм алдында оятка калырлык була күрмәсен берүк!..

Фәтхия карчык үзенең кунак киленен шулай каршылады. Мәрхәбә болай үз итүгә эченнән бик шатланды, каенанасының һәрбер йомышы, һәрбер шелтәсе

аның бу йортта аяк баскан туфрагын ныгыта кебек булды. Аталарыннан кар ерып кайту белән хуҗа хатынның мондый зур эш тапшыруы аның башын күтәрде, ул, тиз-тиз йортка чыгып, кияү бүлмәсенә йөгерде.

Түбән оч Хәмит дигәннең Нурый картка бераз бурычы бар иде. Шул ярлыланып бетеп, авылдан өмет өзеп, үзенең эшләп йөргән җиренә — агач заводына бөтенләй күчеп китте. Башкача түли алмагач, Нурый аның өен басып алды. Зур түгел. Барынча нык кына булып чыкты. Шибайдан яучы килеп, мәһәр акчасын алгач та карт, башкалар кебек, кияүне кышкы челләдә салкын келәткә ябарга ошатмады, нәселле, затлы кешенең баласы бит дип, менә шул Хәмиттән калган өйне тиз генә төзәттерде. Кыз белән кияүне никахтан соң шунда ябарга хәзерләделәр.

Каенананың әйтүе буенча Мәрхәбә ашыгып килеп кергәндә, өй әйбәт тазартылган, җылынган, җыештырылган, үзенчә чибәрләнгән иде. Ләкин хатын яратып бетмәде, кияү бүлмәсенең тагы да матуррак булуын кирәксенеп, эшкә тотынды. Назлы килен Гыйззелбәнат белән матур җиңги Мәфтуха шунда кайнашалар иде. Мәрхәбә, үзенең килендәшләренең эшен яратмыйча кинәт хәтерләрен калдырырга теләмәде, берәмләп башлады. Иң элек шунда файдасызга аяк арасында буталып йөргән назлы килен Гыйззелбәнатны моннан матурлап куды:

— Иркәкәем, син Гөлбану янына бара күр. Никах-туй көнендә кызлар башларын югалтучан булалар. Ни кияргә, ничек бизәнергә белми йөдәп бетәләр. Син аңа булышырсың, — диде, берәмләп санап өстәде: — Киясе күлмәген карый күр: алымы, гөлеме килешер — шуны сайларсың; чәчен үзең тара, үзең иплән үр, чулпыларын үзең иплән так. Йөзекләрен, беләзекләрен, алкаларын үзең кидер. Алтыны бармы, көмешеме — үзең карарсың, битенә кершәнне үзең як, иннекне үзең сөрт, сөрмәне үзең тарт, югыйсә, каушап, калтырап бетәр; елый күрмәсен, уен-көлке сөйлә, — диде.

Гыйззелбәнат чит килennең болай өйрәтеп маташуына бер дә гарьләнмәде. «Челем карт кызы боларны кайдан белеп бетерде икән, теле телгә йокмый, сайрап тора лабаса», — дип гаҗәпсенде генә. Үзе киенү-ясану эшләрен бик яратканга, бик теләп каенсеңле Гөлбануны кияү өчен, зөфаф өчен әзерләшергә йөгерде.

Матур җиңги Мәфтуха белән икәү генә калгач, үги килен сорады:

— Кая соң Гөлбануның бирнәләре? Күптер бит?

Зур өйдә кунакларга тыгызлый дип, кызның бирнәләре, өшәнчекләре белән тулы ак калайлы зур ике сандыкны монда, кияү бүлмәсенең ишеге төбенә күчереп куйганнар иде. Мәфтуха күрсәтте:

— Нигә булмасын, менә ике сандык тулы, — диде, яшерен ачкычларны тартып чыгарды. Ачтылар да актарырга тотындылар. Монда чыннан да бөтен крестьян байлыгы иде.

Нурый үзе дә, сукрана-сукрана булса да, яз, көз, һәр базарда диярлек, төпчек кызының тегү-чигүләре, киндерләре өчен кирәк җепне, җитенне, киҗе мамыкны, буяуны, дебетне алып бирә торды. Ул киреләнгән, саранланган чакларда Фәтхия карчык яшерен йомырка сатып, яшерен иген сатып җыйган яшерен акчаларына кызының бирнә кирәкләрен җиткерергә тырышты. Гөлбану, ундүрт яшеннән алып, һәр яз берничә ай киндер сукты, үзенә, булачак киявенә сөлгеләр, ашъяулыклар, күлмәкләр, чаршаулар, чыбылдыклар әзерләде. Каенанага, каенсеңелләргә, кайнишләргә бүләкләр ясады. Җир ачылып, үлән кипкәч, боларны үзе кебек кызлар белән елга буенда, яшел чирәмдә, кояшта киптереп агартты, аннан җәйге кичләрдә иптәшләре белән җыелып тукмадылар. Көз, кыш килсә, тегүгә, чигүгә, каюга утырды. Мамык шарфлар, шәлләр бәйләде. Менә шулай итеп, унҗиде яшенә кергәндә кызның өшәнчеге, бирнәсе бик бай булып әзерләнеп җитте.

Мәрхәбә, мондый эшләрдә бик күп кул җылыткан хатын кебек, ике сандыкны берьюлы ачып ташлады да кочагы-кочагы белән әйләндерә башлады. Иң элек матур эшләнгән тәрәзә пәрдәләрен тартып чыгарды. Матур җиңги кыенсынды, бераз уңайсызланып елмайды:

— Без дә үлчәп карадык та, болар зурлар шул, килмиләр, — диде.

Мәрхәбә җиңелмәде:

— Киленкәем, инә белән җеп тап, бер-ике урыннан чәнечсәң тора бирер, мондый ак әйбердә беленми ул, — диде. Тәрәзәләргә үлчәде дә атлап-атлап берничә чәнечте; вак кадаклар белән чүкеч, нечкә җеп таптырды; шулай юнәйтеп, дүрт тәрәзәгә бу пәрдәләрне корып җибәргәч, өйгә икенче төс үк кереп киткән кебек булды.

Мәфтуха бу кунак килендәшенең уңган кулыннан аз гына да көнләшмәде. Гөлбану өчен, аның бүлмәсенең матурлыгы, кияүгә ошарлык төзелүе өчен ул елан авызыннан зәһәр эчәргә риза кебек иде, Бик яратты, балалар кебек очынып куанды, кычкырып мактады.

Мәрхәбә туктамады, тәрәзә пәрдәләре килешеп урынлашкач, стеналарда ямьсезләнеп эленгән сөлгеләрне берәм-берәм тартып төшерде, тагы бирнә сандыкларында актарынырга тотынды:

— Тукта әле, — диде, — ак җирлек өстенә зәңгәр белән, кызыл белән эшләнгәннәре юкмы?.. Биш көре белән сугылып, озын чук салындырган киң сөлгеләр юкмы? Тукта, күк өстенә кызыл, кара өстенә яшел төшергәннәр

табылмасмы?..

Шулай сөйләнә-сөйләнә эзләгәннәрен таба торды, һәрбер тапканын чыгарып сала бирде. Тәрәзә башларына, ике тәрәзә араларына тагы кадаклар кактырды. Тагы җепләр үткәрде, шулай өйнең бөтен ялангач стеналарын киҗеле сөлгеләр, чигүле намазлыклар белән бизәп бетерде. Кияү бүлмәсе ак, кызыл, кара, яшел, саргылт-зәңгәр, күгелҗем-кара, сыек миләүшә төсләре дулкыны эченә батты. Матур җиңги карап туймады, Гөлбану өчен шатланып бетә алмады; мактый-мактый, ятакка килеп тотындылар, монда эш начар түгел иде. Киң агач ятакның өстенә тау-тау өелгән түшәк-ястыкларны, мендәрләрне яңадан кабартып җәйде, юрганны түбәнрәк салындырды, киҗеле япманың кызыл төстәгесен ак белән алмаштырды да кечкенә мамык мендәрләрне өскә күпертеп куйды.

Түрнең сул ягында сәке бар. Хатын әйтте:

— Бу килбәтсез, тупас нәрсә урынына матур гына, җыйнак кына өстәл белән ике генә урындык куйган булсалар, нинди чибәр буласы икән. Инде аны алмаштырып торырлык вакыт калмады, Нурый картның тискәрелеге шул... — дип тиргәнә-тиргәнә, киез өстендәге йорт эше чуар паласны сәкенең читенәчә салындырып, киңәйтеп җәйде. Аның өстенә юрганның чибәррәген алып түшәде, стенага таба терәп, тар корама юрганнар япты да ике кечкенә мамык мендәрне, кабартып, почмаккарак куйды. Мәфтуха боларга да сокланып карады, җәннәт кебек булды бит, инде шул җитәрдер, дип уйлады. Ләкин үз алдына, үз башына дөнья көтеп, Алатауның туйлары эчендә кайнаган Мәрхәбә әле һаман канәгатьсез иде:

— Килендәшкәем, кая соң Гөлбануның чаршаулары, чыбылдыклары? — диде дә, җавабын көтмичә үк, бирнә сандыгына тыгылды, эзләгәннәрен бер-бер артлы тартып алды.

Тагы тиз-тиз кадаклар кагып, җеп үткәрделәр; чыбылдык кияү белән кызның ятагы өстенә менеп асылды. Монда бөтенләй аерым йокы бүлмәсе кебек, наз-иркәлек бүлмәсе кебек аулак булып китте. Зур киҗеле, кызыл чаршауларның берсен мич алды яныннан каршы стенага тартып, өйне түрдән ишеккә таба аркылы бүлделәр. Кергән кеше дә туры урынны күрми, ишек ачу белән суык һава да түргә, кияү белән кызга бәреп бармый. Үзе чибәр дә чыкты.

Болар шулай ашыгыч рәвештә кияү бүлмәсен зиннәтләп бетереп барганда, теге ябык яшүсмер ялчы Мифтах килеп керде:

— Кунак җиңги, сиңа Фәтхия әби әйтте, тегендә, өндәүче Чокыр Хәбип йортында кияүнең атын җигә башлаганнар инде, дип әйтте, бик нечкәләмәсеннәр, тизрәк булсыннар, дип әйтте, — диде. Үзе чыгып китте.

Ул арада назлы иркә килен Гыйззелбәнат үзенең каенсеңелесе Гөлбануны теге

өйдән, курчак кебек ал-кызылга киендереп, битләренә кершән, иннек ягып, күзенә сөрмәләр тартып, алдына, артына чалдор-чолдыр тәңкәләр тезеп, бу өйгә китереп тә җиткерде.

Мәрхәбә башка берәүне дә кертмәскә дип ишекнең келәсен элде. Үзе, иркәләп, сөеп, кызның өстендәге сырма бишмәтен салдырды, түргә, лампа утына якын куеп, курчак караган кебек, Гөлбануны әйләндереп-әйләндереп карады. Матур җиңгинең күзләрендә шатлыктан нур уйнады; ул үзенең каенсеңелен оҗмахтагы хур кызы кебек, сарайдагы хан кызы кебек чибәр тапты, һәммә нәрсәсен аерым мактап, туктаусыз сөйде, сөенде. Мәрхәбә дә яратты, тик бер генә нәрсә аның эчен пошырды: кызның күзләрендә, битендә аз гына елау эзе бар. Бу бераз гына бозып тора. Моны үзенә әйтмәде, өстендәге алсу күлмәген, беләге тулы беләзекләрен, башындагы кызыллы-яшелле зәңгәр шәлен, күзендәге сөрмәсе белән бит алмасы өстендәге кызыл иннеген яратып-яратып карады; матур, бары да бик матур, бик килешле, бары да коеп куйган кебек, диде. Гөлбану бу мактаудан күңелләнде, үзенә сокланып карап, көзге алдында әйләнде, күзенә, битенә елмаю чыкты, шуның белән баягы елау эзе бөтенләй югалып ук китте.

Шул минутта тышта капка төбендә бик каты: «Гөрссс!.. Гөрссс!..» — иткән тавыш бу кечкенә өйнең тәрәзәләрен чылтыратып җибәрде.

Гөлбану куркып агарынды, егыла язып, җиңгәсенә тотынды. Тагы бер тапкыр аттылар. Шуның белән бергә йортта ирләрнең, бала-чагаларның кычкырынулары, шау-шулары көчәйде, болай таба килгән кебек булды. Шул шау-шу эчендә мылтыкның каты тавышы белән өй тагы бер тапкыр дер селкенде; чананың кар өстеннән чаж-чож итеп кияү өенә килеп туктаганы ишетелде. Кызның коты очты, тез буыннары калтырап, чаршауның эч ягына, сәке читенә утырды. Матур җиңги Мәфтуха аның биленнән кочаклап тотты, куркудан, каушаудан йөрәге чыгарга барган, бөтен тәне дерелдәп торган кызның яныннан китмәде.

Тышта, ишек төбендә тавыш күбәйде; малайлар кияү белән сатулашырга тотындылар. Эчтән бикле ишекнең келәсенә кулын салып, вакыты җиткәч тиз ачып җибәрергә әзерләнеп, Мәрхәбә бусагада торды.

Тышкы яктан малайлар һаман киреләнделәр:

— Җизни! Ишек бавы бер акча, безнең апай мең акча! — дип, кулларына бирелгән егермешәр тиенлек көмешкә риза булмадылар, тыш яктан ишек бавын җибәрми тордылар.

Кияү тагы берәр көмеш салды, балалар һаман усалландылар, шул ук сүзне кабатладылар:

— Җизни! Ишек бавы бер акча, безнең апа мең акча!
Егет өченче тапкыр бирде. Малайлар шатлыктан сикерешеп чаптылар. Кияү ишек бавын тартып җибәрде; эчтән кунак килен keләне ычкындырды; өйгә зур толыплы, кама читле бүрекле таза бер егет керде; аның белән бергә үк кияү егете, тагы берничә ир, берничә яшүсмер керделәр. Тыгызланып җыештырылган, зиннәтләнгән кечкенә өйдә урын җитмәде.
Закир кияү, гадәт буенча, каршы алган җиңгәләр белән исәнләште дә, сәкегә утырып, дога кылды. Өйдәгеләрнең һәммәсе аның белән кул күтәрде, урын тапканнары утырды, тапмаганнары чүгәләде, сөялде — дога шулай тәмам булды. Шуның белән кияүне озата кергән егетләрнең, ирләрнең эшләре бетте; үзләренең өлкән бурычларын үтәгән кебек, һәр ике якка күп бәхет, тигез мәхәббәт теләп, чыгып киттеләр.
Өйдә кияү, кыз, өч җиңги калдылар. Мәрхәбә осталык белән булышты. Егет аның ярдәме белән зур толыбын салды, бүреген алып сандык өстенә куйды, башындагы, Казан Печән базары эше, матур калын укалы кәләпүшен төзәтеп киде. Шул ук вакытта чаршауның эч ягыннан Мәфтуха килен үз алдына дер-дер калтырап торган Гөлбануны алып чыкты, егет белән кызны күрештерде.
Бу — аларның үз гомерләрендә беренче очрашулары, беренче күрешүләре иде.
Яшь бикәч, бераз каушый төшеп, үзенең битеннән шәлен ачкач, егетнең күңелендәге барлык шикләре югалды; ул бер караудa яратып китте, алдан өйрәткән барлык гадәт-йолаларны онытты, зур кулы белән кызның аркасыннан алып, үзенең күкрәгенә кысты, Гөлбануның башыннан, шәленнән үбә башлады.
Агалары, җиңгәләре, яңа өйләнгән иптәш егетләре туйга китәр алдыннан Закирга бик күп нәрсәләр өйрәтеп маташтылар. Өлкән җиңгәсе Мәрфуга кат-кат тукыды:
— Бәхетле булыйм, хатыннан уңыйм дисәң, — диде, — кыз хатына кергәч, кәләшең белән күреш тә ике рәкәгать намаз укы, бу — борыннан килгән йола, — диде. Егет елына ике гаеттән башка вакыт сәҗдәгә ятканы юк иде, бу киңәшне җилкәсен кашыбрак тыңлады, шулай да үз эченнән: булдырып булса, тырышып карарга кирәк дип, исәпләп карады. Ләкин Гөлбану хатына кереп, кызга кавышкач, моны бөтенләй хәтереннән үк чыгарды... һәркайда билбау, чолгау белән бик азапланалар. Закирга бу турыда да күп тукыдылар. Шул ук өлкән җиңги Мәрфуга колагына кисеп керде:
— Хатының балавыз кебек булыр, аягыңа олтан булыр, йөргән җиреңә туфрак булыр, — диде. Нечкәләп өйрәттеләр.
Егет кыз хатына барганда үзенең билбавын да бик чуалтып бәйли, очларын адәм табалмаслык итеп яшереп куя. Киявен чишендерә башлагач, яшь бикәч

билбауның очын таба алмыйча, тапкач ычкындыра алмыйча газап чигә. «Шуны да чишә белмисең, булдыксыз», — дип, егет үзенең яшь кәләшенең яңакларыннан уңлы-суллы чапкаларга, ут чыгарырга тиешле. Чолгауны тыгызлап урый, читекне, итекне тыгызлап кия. Кыз боларны чыгара алмый азаплана. Тагы шелтә, тагы уңлы-суллы чапкалау, тагы яңаклау...

Болар инде гади әйберләр иде. Ләкин болай якыннан гомерендә беренче тапкыр мондый яшь чибәр кыз күргән егет аларны да онытты. Билбауны үзе үк чишеп ташлады. Өйрәтелгәннәр хәтеренә дә килмәде.

Ул арада җиңгиләр, түрдәге сәкегә чәй әзерләп, гөжләп кайнаган самавырны кертеп куйдылар. Майдан, балдан, ләвәштән, вак 'бәлештән, коймактан, каймактан, дөньяда үзләре белгән, күргән ничаклы тәмле ашамлыклар, кадерле сыйлар булса, һәммәсен китереп тезделәр. Кияүнең тамагына аш бармады, авызы берсенең дә тәмен тоймады, оялып, калтырабрак азапланган Гөлбанудан күзләрен алмыйча, бер генә чынаяк чәй эчте дә бал-май тәрилкәләренә иллешәр тиенлек көмешләр тезде. Киленнәр аңладылар, бик каты кыстап карадылар да, чәйне җыеп алып, үзләре ашыгыч югалдылар. Егет үз бәхетенә чумды...

Туй, никах, өйләнү тирәләрендә баштарак сүз бик күп, бик төрле булган иде, кайберәүләр егетнең котын очырдылар. Караюргалар — бары да черегән кара байлар, үзләре тупас, пычрак, диделәр. Гөлбану турында әйтелмәгән сүз калмады: бите табак кебек, авызы иләк кебек, күзе мәченеке кебек, аяк атлавының юне юк, диделәр. Икенчеләр: ну, егет, кызның асылын эләктердең, буйга дисәң Идел камышы кебек зифа, йөз дисәң тулган ай кебек, нур уйнап, балкылдап тора, күзендә ялкын уйный, авызы — уймак, йөреше — аккош йөреше, дип, күккә күтәрделәр. Егетнең йөрәге янды; караңгы төндә, ат иярләтеп, дус егет Гыймран белән Караюргага кыз күзләргә, булачак хатыны Гөлбануны һич булмаса читтән, тәрәзә аркылы бер күрергә теләп, ике тапкыр килде. Ләкин туры китерә алмады, берсендә, эләгеп, кыйналудан чак котылды. Сүзләрдән, гайбәтләрдән башы чыкмады. Бүген йөрәге каты сукты, ни күрәм дип икеләнеп керде һәм бер күрү белән җаны тынычланып, күңеле белән кызга бирелеп үк китте. Җиңгәләренең чыкканын түземсезлек белән, кызган баш, кайнаган йөрәк белән көтте. Алар чыгуга ишекне үзе барып бикләде дә, әле һаман каушавыннан, дерелдәвеннән котылмаган яшь бикәчен кочаклап алды. Маңгаеннан, күзләреннән, бит алмаларыннан, иреннәреннән туктаусыз суырып-суырып үбәргә тотынды. Бу котырган иркәлекләр эчендә кыз үзен югалтты, — тәкъдир шулдыр, Ходайның язганы шулдыр, дип уйланып, юанып, егетнең кочагында эреде, җаны-тәне белән эреде.

Бу хәзерлекләр, бу туйлар эчендә, бу никах сөенечләре арасында Гөлбануның

күзендә яшь, күңелендә кайгы иде. Нигә болай икән, нигә Лотфи юк икән дип эченнән туктаусыз әрнеде. Кая барыйм, башымны ташка орыйммы, Илаһым хуҗам, дип үкседе. Ләкин хәзерлекләр арткан саен, туй кайнашы көчәйгән саен кызның күңелендәге Лотфи каядыр артка, томан эченә табарак китә барды.

Мылтык тавышларын, ишек бавы өчен сатулашуларны, килеп кергән секундларны ут эчендә кичерде. Җиңгәсе китереп күрештергән чакта үзен яхшылап аңлый да алмады, чәй алдында егетнең туктаусыз сөеп каравы аз гына хәтерендә калды. Аңа елмаерга тырышуын да бик аз гына исләде. Егетнең беренче кочаклавы, озак үбүе аның миендә нәрсәнедер әйләндергән кебек булды. Лотфый әллә кайда, ак томан эчендә югалды, аңардан тик йөрәкнең әллә кайсы бер төпке катлавында нечкә, акрын җылылык, сагынуга, кызгануга ошаган бер якынлык кына калды. Үзен-үзе белмичәрәк, яратып, теләп Закирга елмайды, иркәләнүгә ошаш бер хәл эчендә киявенең йөзенә, күкрәгенә капланды. Шуның белән каушаулар да бетте, ике арадагы пәрдәләр дә югалган кебек булды... Зөфаф кичәсе шулай үтте.

XIV

Кыз белән кияүнең яңа тормышка караган беренче таңнарын ишек төбендә балалар шаулашып каршы алдылар. Көннең суыгына карамастан, кеп-кечкенә кызлар, туңып-калтырап беткән бәләкәй малайлар өшегән та-. вышлары белән:

— Җизни, пәке бир.

— Җизни, кершән бир.

— Җизни, сабын бир, — дип, ишек шакылдаталар.

Гөлбану белән Закир үзләренең җылы, чибәр өйләрендә, йомшак түшәк, ястыклар, мендәрләр, юрганнар эчендә бер-беренә иркәләнешеп уяндылар. Кыз лампыны күтәрде, бүлмәне яктыртты, иренең кечкенә бүләк сандыгын үзләренең ятакларына ук алып килде. Шаяра-шаяра актардылар, дәрәҗә-дәрәҗә бүлделәр.

Туй үткәч тә Гөлбану үзенең иптәш кызларын бүләк чәенә чакырачак. Һәммәсенә, дәрәҗәсенә карап, исле сабыннар, хушбуйлар, иннекләр, кершәннәр өләшәчәк. Иң элек менә шуңа дигәннәрен аерып бер якка куйдылар. Ага-эненең, якын кардәшләрнең балалары бар. Болар өчен дә үзенә дәрәҗә белән аердылар. Калганнары инде икешәр-өчәр тиенлек арзанлы пәкеләр, арзанлы сабын, арзанлы кершәннәр, иннекләр иде. Һәрбер сораганга бирә китсәң, болар да җитмәс, саклыкка байтак конфет, байтак бер тиенлек, ике тиенлек вак акчалар куйды.

Вакытның җиткәнен сизеп, киленнәр дә килделәр. Матур җиңги тыштагы балаларга үзе бүләкләр өләште, аларны таратты да кияү белән кызны мунчага

чакырды. Егет анда да сабынга, сөлгегә, җәймәгә көмеш акчалар салды. Кеше күрмәсен, ояткa калмыйк дигән сыман, туннарга, шәлләргә төренеп мунчадан кайтканда, өй тагын чибәрләнеп җыелган, сәкегә кичәгедән дә баерак, тәмлерәк, сыйлырак итеп чәй хәзерләнгән иде. Кунак килен беренче чынаякны ясады да, кияү белән кызның хезмәтенә Мәфтуханы калдырды, үзе, йөрәгендәге тирән бер борчуга чыдаша алмыйча, ирен эзләп китте. Карт коданың төпкә җигеп килгән зур күк атының койрыгын кискәннәр, диләр. Күп түгел-түгелен, бик аз гына, беленер-беленмәс кенә кисә алганнар. Шулай да бу зур, бик зур мәсхәрә инде!

Кунак килен кичә аз вакыт эчендә дә эшнең чамасын сизгән иде. Күршенең бер гайбәтче карчык бу заманның яшьләрен каргап утырды-утырды да әйтә салды:

— Менә, — ди, — теге кибетче Лотфый дигәннәре, аягына басып җитмәгән, ди, миңа дигән кызны алды, ил алдында хур итмәсәм, исемем Лотфый булмас дип күкрәк суга имеш, ди, — дип сөйләп рәнҗеде.

Мәрхәбә моны иренә әйтте, ире Шәйхел үзенең агасы Төхфәткә ирештерде; кечкенә энеләре Шәйгәрдәнне чакырып, өчәү киңәшләштеләр дә, туй үтеп киткәнче, дүрт төн буенча, караңгы кичтән якты таңгача капкада, азбарда кизүләп каравыл торырга булдылар. Төхфәт урысчалап сүгенде, бер кулыңа имән казык тот, куеныңа үткен балта кыстыр да, кем булса да кызганма, башын чап та өз, җавапка үзем барырмын, дип гайрәт орды. Бу беренче төнне үзе башлап каравыллады, капканы дегеткә буямасыннар, кияүнең, кодаларның ат койрыкларын кисмәсеннәр дип, бик белдермичә генә, почмакларга ышыклана биреп, урамнан, азбардагы атлардан күзен алмады. Шулай сагалап торганда, өй белән биек көрт арасында бер карачкыл күренде, коймадан капкага таба бер кеше яшеренебрәк ташланган кебек булды. Төхфәт, казыгын селтәп, балтасын тотып, шунда атылды; ләкин теге карачкыл йөгереп качты; бераз баргач, сул якка, кечкенә тыкрыкка, аннан ындырлардагы салам, печән өемнәре арасында югалды. Төхфәт артыннан бармады, кире кайтып, капканы карады. Юк, бер зыян да юк, такталар, баганалар ап-ак утыралар. Бер тамчы дегет тә яга алмаган. Моңа шатланып 'бетмәде, тегендә, азбар эчендә, атларның берничәсе берьюлы пошкырды, берсе шартлатып нәрсәгәдер типкән кебек булды. Каравылчы ирнең йөрәгенә ут кабынды, казыгын күтәреп, азбарга ташланды. Анда атларның һәммәсе, куркышып, бер почмакка өерелешкәннәр. Зур күк ат нукта белән улак өстендәге калын өрлеккә бәйләнгән; үзе куркынып, дулап туктамыйча, әле бер якка, әле икенче якка сикеренә; аның тирәсендә бер кулына таяк, бер кулына камчы тотып, ниндидер бер ак чикмәнле, басынкы бүрекле крестьян кайнаша. Төхфәт тавышсыз гына килде дә, сиздермәстән,

кулындагы имән казык белән сугып екты, тагы урысчалап сүгенде. Тагы берне, тагы берне өстәде; җирдә, каткан ат тизәкләре эчендә ыңгырашкан ак чикмәнле крестьян сакчының аякларын кочаклады:

— Төхфәт абзыкайгынам, мине үтермә, мине үтермә! Мин гаепле түгел, барын да әйтеп бирәм, — диде.

Төхфәт, яман сүгенеп, аның күкрәген, битен, башын таптады; ләкин казык белән балтага ирек бирмәде. Ак чикмән үлми калды, тик аның уң кулы каерылды. Бите, башы җимерелеп, шешеп, кара кан белән катты.

Бу — түбән очның бер ярлы крестьяны иде; аны Басма Шайҗан дип йөртәләр. Аякка торгач, Төхфәткә ялынды, балтаңны калдыр, инде тимәсләр, син мине өемә илт, сөйләрмен, диде.

Өенә барышлый, яшеренеп аракы сату белән азаплангалый торган Җәгъфәрдән бер яртыны алып чыкты; кайту белән иң элек эчте, аннан сөйләп бирде:

— Менә бит, Төхфәт абзыкай, ничек харап булдым, — ди. — Кибетче Лотфый Әскәр белән безнең икебезне яллады. Эчереп, акча биреп яллады. «Менә, — диде, — синең миңа ун дүрт сум бирәчәгең бар, шуны йолармын, эшең барып чыкса, бер дисәтинәгә җитәрлек бодай орлыгы бирермен», — диде. Без нәрсә? Юк кеше бит, юкка алдана бирәсең...

Ахырда Төхфәт белән шулай киңәштеләр: Басма Шайҗан бу эшне берәүгә дә сөйләми; сорасалар, бите, башы, кулы эчеп сугышканнан шулай 'булды, ди. Әгәр инде берәүгә-берәүгә сүз чыгарса, менә имән казык, менә үткен балта! Төхфәт үзе килеп, Шайҗанның муенын чабып өзәр!

Җепнең очларын шулай нык яшерделәр.

Ләкин без капчыкта ята алмады. Бу сөйләшләр Шайҗанның хатыны Миңленисаның колагына чалынды. Ул бик тырышса да түзә алмады, теле кычытып, бик зур сер итеп, Миңлезифага гына сөйләде. Миңлезифа да тырышып карады, ләкин көче җитмәде, бик зур сер итеп Хәернисага гына әйтте. Ул апасыннан сер яшерми иде, апасының дус килендәше бар иде; килендәш үзенең сердәш кодачасына гына әйтте. Шулай, идән астыннан чәчелеп китте дә барды.

Иртә белән караңгылы-яктылы вакытта кунак килен Мәрхәбәнең куркынып ире Шәйхелне эзләве менә шуның өчен иде. Төхфәт белән икесен бергә тапты. Һичкемгә белгертмәскә сүз куештылар. Кодалар да, кияү белән кыз да — һич кем дә бер нәрсә дә белмәсен, койрыкны юньләп кисә алмаган, тик уң ягыннан бер уч чаклысын гына кыркып алган. Иплəп таратып җибәргәндә, тотып нечкәләп карамасаң, күренерлек тә түгел. Тагы бер чара да кылдылар: көннәр салкын, өшемәсеннәр дип кунак атларны ябуларга булдылар; әзрәк койрыгы

кыркылган күк атка иң зур ябуны биреп, аны да төшеребрәк, киселгән урынны каплабрак куярга киңәштеләр. Шулай итеп ил мәсхәрәсеннән котылмак булдылар.

Ләкин барып чыкмады.

XV

Гөлбануныкы белән бер көндә Алачык Садрый кызының да туе килде. Шәрип ахун үзенең балдызы белән баҗасын, кияве белән кызын чакырган икән. Фәйзулла мәзиндә кайнагасы белән бабасы кунакталар. Чокыр Хәбипкә дә туйның икенче көнендә кайнише белән хатыны килеп төштеләр. Шулай авылда, һәр йортта диярлек, парлы кунаклар бар. Нурый белән Садрыйнныкына башка тагы дүрт туй бергә кушылды. Һәр өйдә аш, чәй, мәҗлес. Кодалар, кодагыйлар, ир-хатын кунаклар, таң иртәдән башлап ярты төнгәчә өйдән-өйгә мәҗлескә йөреп арып бетәләр. Фәтхия, әлбәттә, кодагыйлары белән бергә, аларга юл башлап, бу мәҗлесләрдә йөрергә тиешле иде. Һәммәсенә үзе өлгерә алмады, байтак урыннарга, бигрәк, безне вак санады, килмәде дип үпкәләмәслек кешеләргә, кодагыйлар белән бергә үзенең күптән аерылып чыккан зур килене усал Мәрфуганы җибәрде. Тик аңа барган, кайткан саен әйтә торды:

— Телеңне тый! Кодагый белән юк-барга әләгешеп барма, — диде.

Килен гомер буе талашып, әрләшеп яшәгән каенанасының сүзен бу турыда тиешле тапты:

— Ярый, әнкәй, тырышырмын, — диде. Ләкин бик тырышса да, булдыра алмады.

Бер зур мәҗлестә Сабира кодагый:

— Безнең нәсел алай, безнең нәсел болай, — дип, үзләрен бик югары күтәреп китте.

Бу урынсыз кәпәренүләргә Мәрфуганың эче пошты, әз генә зәһәр белән чәнчеп куйды:

— Җә, Сабира кодагый, бик кабарынма инде, сезнең нәселне дә беләбез ләбаса, — диде.

Кайбер тыйнаксызлар хи... хи... хи... итеп көлделәр. Сабира кызарынды, илдә йөргән гайбәтләр турында тел ачмакчыдыр дип, катырак бәреп ташлады:

— Харап икән! Беләбез дигән буласың?!. Син иң элек үзеңнең Саесканыңны бел! Аннан соң кеше гайбәтенә керешерсең! — диде.

Бу инде чыннан да каты әйтү булып чыкты. Мәрфуга үзенең каенанасы әйткән сүзләрне онытты, хурлыгыннан кая керергә урын тапмады. Бу «Саесканны» тик кенә бөтен мәҗлес алдында күтәреп калырга көче җитмәде, әрләнеп җавап кайтарды. Талаш кызып китте.

Бу — Нурый картның бөтен нәселенә тагылган бер кушамат инде шулай! Кечкенә чагында Нурыйның бабасы бик ярлы иде. Анасы белән ятим үсте. Өстенә иске-москыдан ямаштырган әйберләрдән башканы күрә алмады. Бервакыт, бүтәнчә бер кием дә рәтли алмагач, анасы үзенең унбер яшьлек улы Сөләйманга җыен калдыклар' дан ямап бишмәт ясый. Моның арты кара, ике җиңе ак, күкрәге кара, култык аслары да ак туры килә. Бу кораманы киеп урамга чыгуга, малайлар:

— Ала саескан, ала саескан, ала саескан, — дип мыскыллап көләргә тотыналар.

Бора торгач, «ала»сы төшеп югала, «саескан» исеме малайга кушамат булыпябышып кала. Зурайгач, бай крестьян булгач та төшми. Сөләйманнан нәсел буенча Нурыйларга күчә. Кимсетеп әйткәндә: «Саескан» дип, «Саескан Нурый» дип, «Саескан Нурый Фәтхиясе», «Саескан Нурый балалары» дип йөртәләр. Моңа үзләре хурланалар, хурланган саен ул үткенләнә бара, аның саен ныграк ябыша бара.

Зур мәҗлес алдында Сабираның чәнчүе — менә шуңа таянып иде.

Мәрфуга бурычлы булып калырга теләмәде, «саескан»га каршы «кәҗә» гайбәтен атарга уйлады, ләкин Фәтхия карчык үзенең киленен тыйды:

— Син яшь кеше. Өлкән кодагыйга юл куя белмисең! — дип шелтәләде.

Мәрфуга телен тешләп торды. Ләкин, бу үчне кайтармый калмам дип, эченнән зәһәрләнеп ант эчте.

Караюрга хатыннары арасында эшне талашка җибәрмәскә тырышучы Фәтхия булса, Бикьяр кодагыйлары арасында тиргәшләргә әрнүче — Сабираның кияүдәге кызы, Әфтәх коданың хатыны — Хәерниса кодача булды. Ул арада каты сүз чыгарырлык һәр әйберне үтеп китәргә, телләшү башланса, сүзне икенче якка тартырга барлык көчен түкте. Фәтхия кодагый белән Хәерниса кодагый, бу турыда сүз берләшкән кебек, бер уңайдан, бер якка таба сөрделәр. Ләкин теләгәннәренә ирешә алмадылар. Әремтел Сабира белән усал килен Мәрфуга туйның актык көнендә, кара-каршы бәрелешкән ике көчле өермә кебек, бер-берсенә ташландылар. Ни чыкмаса, һаман шул кунак килен Мәрхәбәдән килеп чыкты. Ул, көн-төн аш өендә, кияү бүлмәсендә кунаклар сыйлау белән, аш-су хәзерләү белән кайнашып, мәһәрләрне, бүләкләрне карый алмаган иде. Ирләр мәҗлестә чакта бер бушрак араны тапты да, хатыннар янында таратып-таратып, мәһәргә килгән күлмәкләрне, шәлләрне, читекләрне, бишмәтлекләрне актарырга тотынды. Аңа усал килен Мәрфуга да килеп кушылды. Мәрхәбәнең сакланыбрак әйткән кайбер ятмауларын ул күтәреп, чөеп җибәрде:

— Әйтерең бармы? Менә ике шәл сөйләштеләр. Берсе йомшак кәҗә

мамыгыннан булыр диделәр. Менә мә, менә мә, китергәннәрен кара: мамыкмы? Бу ялган җеп бит! Адәмнән дә оялмыйлар, Алладан да курыкмыйлар, — диде. Тагы, актара торгач, күлмәклекләргә җитте: — Менә күр, алты күлмәкнең берсе йон, берсе асыл булыр, дигәннәр иде. Китергәннәрен кара, уракчыга бирә торган начар ситсы бит бу! Җитмәсә тагын үзләре, әллә кем булып, борын күтәреп, көязләнгән булалар...

Сабира кодагый тышта иде. Мәрфуганың сүзләре вакытында комганын күтәреп керде. Кулын сөртә-сөртә, колагының бер читен болар ягына салды, түргә барып, намазлык алып, иртәнге намазны каза кылырга әзерләнде, ләкин усал киленнең чәнчүләре аның йөрәгенә барып кадалды, канын кайнатты, башын томан белән каплады. Ул, үзен-үзе белмичә, намазлыгын атып бәрде:

— Син тагы нәрсә битсезләнәсең? Мәһәрнең нәрсәсе ярамаган? Затсыз, Саескан! — дип кычкырды.

Мәрфуга түзмәде, Фәтхия әбигә биргән вәгъдәләрен онытты, яман талашка кереп китте:

— Нәрсәсе ярасын? Менә бу мамык шәлме? Менә бу йонмы? Бездә мондый әйберне ялчы хатыннарга гына бирәләр, — дип, шәлләрне, күлмәкләрне кодагыйга таба ата башлады.

Бөтен өй тавыш, талаш, тиргәш белән капланды. Сабира кабат-кабат:

— Саескан, — дип, — затсыз кара мужик, — дип акырынды.

Аңа каршы Мәрфуга, бөтен җаны белән хурланып, хәзинәсендәге актык зәһәрен чыгарып сипте:

— Җә, бикә, әллә кем булма! Беләбез синең атаңны да! Кәҗә Солтан! Кәҗә Солтан! Кәҗә, кәҗә, кәҗә! Менә кем кызы син! Җитмәсә тагын, кешене мыскыл иткән була! — диде.

Сабирага бу сүз көтелмәгән дәрәҗәдә авыр хурлык булып төште. Шундый бер кушамат бар шул: «Кәҗә», диләр!

Аның атасы Солтан заманында сунарчы булган, диләр. Бервакыт үзенең бер дус адәмендә эче балны эчеп, кызыбрак чыккан да, зур мөгезле ак кәҗәне болан дип, поши дип, аты белән куып киткән, диләр. Авылдагы дошман байлары, җәй, кыш мәптектә[1] ятучы бер аксак хәлфәгә тутырган тавык, илле тиен акча биреп, зур бәет чыгарттылар. Бу бәетне, өйдән өйгә кереп, садака җыеп йөрүче бер сукыр хәерчегә ятлаттылар. Халыкка бик кызык тоелды. Бер тиен акча, ике йомырка биргән һәркемгә сукыр хәерче Солтан турындагы бәетне укып чыга торган булды. Шуннан Солтанга — Кәҗә Солтан дип ат куштылар, бу кушамат балаларына да күчте, нәселенә җәелде.

---

[1] *Мәптектә* - мәктәптә

Мәрфуга киленнең бик әрнеп, зәһәрләнеп ташлаган «кәҗә» сүзе кодагыйның менә шул авыр ярасына барып чәнчелде. Ул үзен бөтенләй югалтты, кызы Хәерниса кодачаның тынычландырырга тырышуларына карамастан, хатыннар теленә керә ала торган барлык начар сүзләрне бер-бер артлы ата башлады, тагы шул: «Саескан», — дип тә кабатлады:

— Бу Саесканнарны кода итеп адәм хуры булдык, — дип өстәде, ләкин, ахыр барып, һичкем көтмәгән нәрсәгә җитеште: — Оятсыз... битләр! Үзегез тишек чиләк белән сату итәсез, җитмәсә тагын мәһәр алай, мәһәр болай дип сүз кузгаткан буласыз! Кеше тикшергәнче үз кызыгызны карар идегез, адәм хурлыгы бит: атыбызның койрыгын кистердек, ат койрыгы кистердек бит! Ни йөзең белән хәзер Бикъярга кайтырсың?! — дип акырды.

Башка сүзләре кадалып китсен иде, әмма ат койрыгы дигәне белән һәммә кешене үтерде. Кунак килен Мәрхәбә дә, усал килен Мәрфуга да бу сер яшерен саклангандыр, кодаларга, кодагыйларга барып ирешмәгәндер дип уйлаганнар иде; талаш вакытында ул начар гайбәт кабарып килеп чыккач, ялангач эссе тәнгә сиздермәстән бозлы су китереп бәргән кебек булды. Мәрфуганың теле буталды, авызына үткен, зәһәр сүз килмәде.

— Җә, бик исең киткән! Туйда андый хәл була ул, син үзеңне бел, Кәҗә... — дип, мәгънәсезгә шаулап, тавыш белән, шау-шу белән үзенең җиңелгәнен капларга теләде.

Шул арада ишек ачылды, тыштан теге якка ирләр кайтып керде. Шибай кода бусагадан аягын атлауга аптырап катты, хатыны Сабираның дулавын ишетеп:

— Бу ни тавыш? — диде.

Хатыннардан һичкем бу якка йөзен күрсәтмәде, ләкин ишек-чаршау аркылы әрләшүдән берсе дә тыелмады; иң элек Мәрфуга җавап кайтарды:

— Карт кода минем сүзне гаепкә ала күрмәсен, мәһәр ким килгән, шуны әйткәч, Сабира кодагый сүз күтәрми, — диде.

Шибай кода, үзе киң күңелле булудан бигрәк, шулай күренергә, гадәтенчә, зурлык күрсәтергә ярата торганнардан иде.

— Нәрсә ким килгән? Иплэп карарга кирәк! Орлыгы Бохарада түгел ләбаса! Алдырырбыз, — диде.

Ул сүзен бетереп җиткермәде, теге яктан — чаршау ишек аркылы, үзе күренмичә, Сабира зәһәрләнде:

— Син дә таптың сүз! Атыңның койрыгын кистеләр, улыңны хур иттеләр, бу затсыз Саесканнарга катнашып, дөнья йөзенә күренерлегебез калмады, — дип кычкырды; баскан җиреннән, женләнеп, тагы өстәде: — Булмас, булмас, атакайгынам! Бу хурлыкка чыдар хәлем юк! Әйдә, койрыксыз атыңны җиктер

дә кайтып китик. Бер минут тора алмыйм мин бу Саесканнарда...
Түр якта, идән уртасында катып, Нурый карт тора иде. Сабира аңардан тартынды, юкса, хәзер ире Шибай янына чыгып, аны өстерәргә тотыначак иде.
Шибай картның ачудан маңгаена салкын тир чыкты, чигә тамырлары калкып каралдылар. Үз өендә Сабира болай котыра башлаганда картның гомерлек бер гадәте бар: каеш чыбыркысын яки намаз таягын ала да битләрен, аркаларын, кабыргаларын изгәнче, кара яндырып, шештереп бетергәнче кыйнап ташлый. Үзе арыгач, артык кыйнарга хәле калмагач, өйдән чыгып китә. Сабира елый-елый да, аягына басып, эшенә тотына. Шуннан берничә атналар буенча майлаган кебек йомшак, ал да гөл кебек чибәр йөри. Бүген дә карт ишек төбендәге калын таякка, чөйдәге каеш чыбыркыга, гадәтенчә, берничә күз төшереп алды; ләкин үзен көчлек белән тыйды, яңа катнашкан кодалар алдында, туй көннәрендә базар төшерү була дип уйлады. Гадәттәге ачулы тавышы белән хатынына кычкырды:
— Син нәрсә бер сүз белән баш әйләндерәсең: имеш, ат койрыгы да, ат койрыгы? Өч бөртек кыл өзелгән икән — аннан җир-күк җимерелерме? Кара халык — кара сарык, дип белеп әйткәннәр. Безнең мужик — юньсез ул! Улым Закир килеп әйтсә, — эткәй, мин алдандым, дисә, менә шунда гына ышанам мин... Бетмәс монда гайбәтче карчыклар сүзе...
Тегендә Сабира тагы чәчрәргә тотынган иде, Чокыр Хәбипнең ялчысы, кулына чыбыркы тотып, бусагада калыкты:
— Кеше килеп бетте, сезне генә көтәләр, — диде.
Нурыйның да, Шибайның да, яшь кодаларның да бер кашык кабарга урыннары юк. Иртәдән бирле, ашаганнары кире килеп, минут саен кикереп, «Әлхәмделилла!” әйтеп йөриләр иде. Ләкин бармаска ярамады, комган белән азбарга йөреп килделәр, кулларын юып, сөртенделәр дә мәҗлескә киттеләр. Анда да ирләр белән хатыннар мәҗлесләре бер үк вакытта үткәрелә, кодалар белән бергә кодагыйлар да чакырылганнар иде. Бәлки бераз күңелен йомшартырмын дип өметләнеп, Фәтхия әби үзе Сабира кодагый янына барды:
— Җә, кодагый, туй үпкәсез булмас, дигәннәр. Син авырга алма инде. Безнең Мәрфуга килен йөрәк авырулы хатын ул. Йортыма төшкәннән бирле, менә уналты ел инде, минем белән дә әрләшмәгән көне аз аның, — диде.
Сабира җавап бирмәде, тик торды, бераз утыргач:
— Ярар, хөрмәтеңә рәхмәт! Туйга килеп, гомеремдә ишетмәгәннәрне Караюрга Саесканнарыннан ишеттем, — диде дә почмакка таба барып, капланып утырды. Фәтхиянең бик хөрмәтләп әйткән сүзләренә дә җавап кайтармады. Шулай бераз кара ачуына батып утырды-утырды да шул турыда стенага ясалган агач

шүрлеккә сузылды.

Анда ике зур, калын китап бар иде. Беренчесен тартып алды. Тузан тузды, борчалар, кандалалар, тараканнар коелып төште. Бу — кульязма Коръән иде. Нурый карт моны, йөз ел элек бер айгыр биреп алынган, имеш, дип сөйли иде. Хатын карады да кире куйды, икенчесен алды; анысы Казан басмасы, зур кулда «Мөхәммәдия»[6*] китабы булып чыкты. Сабираның күңеле күтәрелде. Ул яшь чакта абыстайга күп еллар сабакка йөргән иде. Егетләргә хат яза дип, язу өйрәтмәсәләр дә, «Әфтияк»не[7*], Коръәнне күп укыды, аңардан бигрәк «Таһир-Зөһрә»не, «Бүз егет»не[8*], «Мөхәммәдия»не, үз моңына үзе дә елап, башка кызларны да елатып, укырга бик яратты. Әле дә, яратып карап, сурәтләреннән үтеп: «Чөн адәм җәннәтә керде...» дигән урынга тукталды, ләкин тәмләп укып китә алмады. Әле яңа гына кичергән әрләшнең зәһәре аңа тынычлык бирмәде, ирексез, ат койрыгы күз алдына килде.

— Бичара төпчегем бәхетсез булды, — дип, Закирын кызганды. — Бу Саесканнарга нинди генә шайтан китереп кушты безне? — дип әрнеде.

Ул улын өйләндерү турында аның башка исәбе бар иде. Карамалының кибетче Шәрәкәй кызын бик мактадылар, үзе дә әйбәт, бирнәсе, өшәнчеге дисәң, бетен тирә-якта бер, диделәр. Сабира үзенең карт апасы аркылы сүз дә салдырды. Бик кире кагар кебек күренмәделәр. Хатынның бөтен күңеле, җаны менә шул Карамалы кызына бағланган, шуны үзенә килен итәргә, шул зур йортта кодагый булырга йөрәген беркетеп куйган иде. Ләкин Шибайның юньсезлеге хатынның исәпләрен җимерделәр. Тегеләр барлыгы сигез йөз сум мәһәр сорадылар. Дүрт йөзе туй вакытында бирелеп бетәр, моның ике йөзе килешкәч тә, акчалата булыр, диделәр. Шибай моңа күнә алмады: «Улыма бай кызы алам дип үзем бөлер хәлем юк, алайга минем көчем җитми, барлыгы — алты йөз, өч йөзе никахка бирелеп бетәр, моның сиксән сумы — килешкәндә», — дип кырт кисте. Тегеләр төшмәделәр, бу менмәде. Шулай итеп, Сабираның корган бөтен исәбе юкка чыкты. Баштан ук, туйга килгәндә *ук,* өчтән дә, тыштан да һаман шул Саесканнар дигәнне кабатлый торды; мәһәр турында талаш кузгаткач, ат койрыгын кистерү кебек хурлыкка калгач, аның җаны үзенә урын тапмады; ул үзен дә, улын да бәхетсез дип, алданганнар, адәм көлкесенә калганнар дип көенде.

Алдына яшь чагында укып, моңланып өйрәнгән «Мөхәммәдия»не ачып, Сабира үзенең менә шул бәхетсезлеге, шул тирән авыр кайгысы турында борчуга чумды.

Фәтхия әбинең күңеле башта ук бик тынычсыз иде. Бүгенге талаштан, бүгенге ат койрыгы белән бәргәләшүдән соң ул инде үзен дөньяның иң бәхетсез бер

адәме, иң бәхетсез бер анасы итеп тойды. Чокыр Хәбипләргә ашка барып кайткач чыдамады, аш өенә чыгып, ялгызы озак елады. Гөлбану аның кадерләп үстергән төпчеге иде. «Туйда ук шундый талашлар, шундый сүзләр чыгарган бу явыз каенана аңа нинди көн бирер? Кадерле балам бу аждаһа кул астында ничек гомер итәр?» — Менә шуларны уйлап озак үкседе.

## XVI

Шундый талашлар белән туйның актык ярты көнен үткәрделәр. Төш авуга озату ашына утырдылар. Майлы шулпа белән токмач, симез билдәмә, зур кисәкләрдә китерелгән суык каз, сары май эчендә йөзеп пешкән өлкән бәлеш — бүгенге сый барлыгы менә шулар булды. Тик болар артыннан Фәтхия карчыкның көяз кодалар, кодагыйлар алдында мактанычлы җимеш суы бирелде дә гөжләп кайнап торган зур көмеш самавыр китерелде. Чәй янына атлан май, кәрәзле ак юкә балы, төеп, майга катнаштырылган шомырт, вак бәлеш, эссе коймак белән каймак чыгарылды; шуңа башка нәрсә өстәлмәде. Чит кунаклар юк, тик якын кардәшләрнең кайберләре, өндәүче Чокыр Хәбип, аннан теге Мәфтуха киленнең ире, Фәтхия карчыкның туган энесе ончы Фәсхи генә килде. Картлар, туй кебек зур, авыр бер мәшәкатьне үткәргәннән соң тынычланып, хәл җыйган кешеләр кебек, түрдә, юрганнар, мендәрләр өстендә аяк бөкләп утырып, каймаклап чәй эчә калдылар, яшьрәкләр бер-ике чынаякны бушаттылар, бит сыйпап, дога кылган сыман иттеләр дә йортка чыктылар.

Анда туйны озатырга җыелган малайлар, озын чыбыркыларны шартлатып, кыңгыраулы дугаларны шалтыратып, бер-берен карга егып, шаулашып уйныйлар иде. Шәйхел бу дүрт көн эчендә атасы белән бер авыз ачып бер сүз сөйли алмаса да, куып чыгармавына күзе җитте, шуңа күрә бу йортның төп кешеләре белән үзен бер уңайдан санап, кодаларны озату эшенә тотынды. Шунда җыелган озатучылар белән бергә кодаларның чаналарын, камыт, ыңгырчак, дилбегә, дугаларын чыгарышты. Атларны берәм-берәм тотып, камытлашу эшләренә дә катнашты. Чаналарның төпләренә яңа саламнар түшәде, йорт уртасына, кар өстенә арканнарны, чыбыркыларны, дилбегәләрне сузды; уйнар чак түгел хәзер: «Йөрмәгез монда, шайтаннар», — дип, маланларны куды. Өзлексез шартлатып, колак яңгыратып бетергән бер малайдан карт коданың зур озын чыбыркысын тартып алды да алгы чананың үрәчә башына элеп куйды. Малай, күзен яздырмый, Шәйхелнең бер якка борылганын гына сагалап торды да шунда ук элмәсен ычкындырды, чыбыркыны кулына алып, урап-урап шартлата башлады. Ләкин чыбыркы бик озын иде, малайның исәбеннән ерак китте, камытланып куелган яшь кара айгырга тиде, — бу, сикереп, уйнаклап, тезгенен, чөелдереген таптый-таптый

азбарга качты. Шәйхел тагы кычкырынды, малай куркып йөгерде, ләкин чыбыркыны кулыннан ычкындырмады.

Ул арада тегендә чәй эчеп, яшь кодалар килеп чыктылар. Шәйхел бераз куркыбрак карады: Бикьяр кодалардан Шибайның зур улы Алтынбай белән кияве Әфтәх тә, Нурыйның өлкән улы Төхфәт белән өченче улы Шәйгәрдән дә — һәммәсе кызмачалар иде. Шәйхел үз булып уйланды: «Күбрәк төшергәннәр бугай, картлар сизмәсә ярар иде», — диде.

Нурый карт үз гомерендә эчемлекне авызына капмады. Улларын да шулай үстерергә тырышты. Башта аз гына сизенсә дә бик нык кыйнап, таяклап карады, ләкин тыя алмады, егетләр, туры килгәндә, өмәдә, калага барганда, ара-тирә төшергәли торган булдылар. Ул, бер минекеләр генә түгел бит дип, теш кысып, моңа акрын-акрын күнде. Тик эчкегә салышып, йорттан малны, игенне әрәм-шәрәм итә күрмәсеннәр, ил каршында хур булмасыннар дигән якны алга куйды. Бу туй булыр алдыннан үзенең күптән аерылган, заманы белән күп талашкан, инде килешеп, дөнья көтә башлаган зур улы Төхфәтне чакырып әйтте:

— Син зур була бел! Исерткеч белән маташмасыннар, күз-колак бул, — дип, боерык бирде.

Төхфәт атасының бу сүзенә үзенең җилкәсен кашыды, телдән:

— Ярар, тырышырбыз инде, әткәй, — диде, эченнән; «Бер бездән генәмени?» — дип куйды.

Шул көнне үк хатыны Мәрфуганың: «Каенатайга әйтәм, җир йотсын әгәр, барам да әйтәм», — дип, усал сүзләнүенә карамастан, үзе үк күрше рус авылының Сашкага барды да бөтен бер чирек акны алып кайтты. Моның өчен сигез пот арыш сатарга туры килде. Картның төп йортында калган Шәйгәрдән дә йокламады: үзара яшь кодалар белән күңел ачып утырырга җай чыкса дип, бер шешә кайтартты. Тегеннән килгән кодалардан Шибайның кияве Әфтәх тә хатынының шәлләре, күлмәкләре арасына букчага бер савыт тыгып килгән икән. Иртәдән алып кичкәчә өзлексез барган аш, чәй, кунак мәҗлесләреннән бушамадылар. Иркенләп утырырга, кәеф корырга җайлары табылмады, аз гына төшереп алган чакларда хатыннары һаман: «Фу... авызыңнан эт исе килә, дөнья сасытып йөрисең», — дип, сукрана тордылар. Шулай да кодалар, качып-посып, ара-тирә каккалауга җай таптылар. Картлар сизмәде түгел, ләкин ике якныкы бертигез булганга, күрмәгәнгә салыштылар.

Асылда, бөтен туйны иң дус, иң күңелле үткәрүчеләр — менә шул яшь кодалар белән яшь кодачалар булды. Болар мәһәр өчен дә талашмадылар, ат койрыгыннан бер-ике бөртек кыл киселүгә дә исләре китмәде, әгәр аз гына җай чыкса, картлар мәчеткәме, кая китеп, аулак калсалар, хәзер уйнап-көләргә,

җырлап такмак әйтешергә, биешергә, кодачалар эчми исерергә, ирләр кызмача бераз шаярырга атлыгып торалар иде. Ләкин ике якның картлары өстән албасты кебек бастылар, уен-көлкегә ирек тә, вакыт та бирмәделәр; шатлыкның күбе, дулкынланып тышка чыгарга җай таба алмыйча, йөрәктә калды, нурланган күзләрдә, үзеннән-үзе көлеп, елмаеп барган иреннәрдә генә уйнады.

Яшь кодаларның болай кызыбрак чыгуын күргәч, Шәйхел борчылган иде, алай куркырлык, кеше алдында сүзгә калырлык бер эш тә күренмәде. Ул арада инде йорттагы хатыннардан усал килен Мәрфуга белән үги кунак килен Мәрхәбә дә кунакларның паласларын, юрган, мендәрләрен күтәреп чыктылар. Аларга, китәр алдыннан, үзләренчә киенгән кодачалардан Әремтел Сабираның кызы — Хәерниса да килеп кушылды. Болар чыр... чыр... чыр... килеп, атларны куркыттылар, йорттагы шау-шуны тагын арттырдылар. Чаналар тирәсе акшар кебек агартылган, уртасы алма кебек кызартылган битләр, мамык шәлләр, аллы-кызыллы, каралы-зәңгәрле чүпрәкләр белән тулды.

Болар монда шулай — ирләр ат җигеп, малайлар шаярып, хатыннар чаналарга юрган, мендәрләрне, төенчекләрне тутырып азапланганда, назлы килен Гыйззелбәнат кияү өеннән чыкмады, каен сеңеле Гөлбанудан, шул дүрт көн эчендә үзләшеп беткән Закир янынннан аерылмады. Гөлбану белән бергә егетнең әйберләрен кечкенә сандыкка төяште, шаярта-шаярта, кыз белән бергә кияүне киендерește, юри каты кысып, билен бәйләште.

Бикьяр кодачаларыннан Хәернисаның Гөлбануга күңеле бик ятып киткән иде. Юк йомышны бар итеп һаман керә-чыга торды. Иң ахыр сәгатьтә үзенең алып килгән кара алтынлы куш беләзеген яшь бикәчкә бүләк итте. Гөлбануның күңеле мондый дуслыктан йомшарып китте; ни эшләргә, ни белән каршы бүләкләргә аптырап калды. Ахырдан, ике кулына тулган йөзекләрнең матурын сайлады да сөекле кунак җиңгәсе Хәернисаның, сагынмаклык итеп, урта бармагына кидерде, — коеп куйган кебек, үзенә эшләткән кебек. Шулай чак булды. Кырык яшьлек Хәерниса белән унҗиде яшьлек Гөлбану шулай ничектер бөтен күңелләре белән бер-беренә багланып, дуслаштылар да куйдылар. Каенана Сабираның авыр холкы үги килен Мәрхәбәне бик кайгырткан иде. Хәернисаның болай якын итүен күргәч, аның күңеле тынычлана төште, Түзмәде, Фәтхия әбигә йөгереп барып, Хәерниса кодача белән Гөлбану арасындагы дуслыкны сөйләде. Беләзек белән йөзек алмашуларны аерым бер тәм, аерым бер өмет белән күзләрен нурландырып, кайта-кайта әйтте. Фәтхиягә болар бик аз гына, бик аз гына күңел җылысы бирделәр. Бу туй, бу никах аңа шатлыктан бигрәк хәсрәт чишмәсе булган иде. Сабира кодагыйның болай, котырган эт кебек туктаусыз талашып, әрләшеп барулары ананың йөрәген бик

яралаганнар иде. Ул, үзенең сөекле төпчеге Гөлбану бәхетсез булды, бәхетсез булды, бу аждаһалар арасында ничек гомер итәр дип, төннәрдә уянып, ялгызы елаштыра иде. Мәрхәбәнең сүзләре яралы күңеленә бераз шифа кебек әсәр иттеләр; кызы Гөлбануның өстен каплаган киләчәк кара болытлар эчендә кечкенә генә бер якты кисәге ялтырап калгандай, өмет ачылырдай күренде, карт йөрәк бераз җиңеләйгәндәй тоелды.

Шулай бөтен йорт, һәммә кеше кызуланып, озату эше белән кайнашып йөргәндә, өйдән Нурый карт чыкты.' Чәчләре, сакаллары ныграк агарганнар. Биттәге җыерчыклары тирәнрәк төшеп киткәннәр дә бик ешайганнар. Бөтен йөз авыр тормышның ахырында килеп баскан көенечләр белән тагы да куырылган, тагы да ныграк кипкән. Карт күзләре бөтенләй төссезләнеп, төпкәрәк китеп, катып туктаганнар. Өстендә бәрән тун, башында сарык эчле бүрек. Аягында ак пима. Ул бераз эзләнгән күзе белән йорт эче тулып кайнашкан халык дулкынын сөзде дә кирәген тапты: туры Шәйхелгә килде, әллә кайдан, тамак төбеннән кысылып, карлыгып чыккан шелтәле тавыш белән башлады:

— Син нигә атыңны җикмисең тагын?! — диде.

Шәйхел колакларына ышанмады, кан аның башына йөгерде, ни әйтергә белми калды. Ул бу дүрт көн эчендә, үзенең киләчәк көнкүреше билгеләнде дип, атай белән килешү булды дип уйлаган иде. Читкә какмады, инде әгәр малдан өлеш чыгарса, бер имана бирсә, Алатаудан туган илгә кайтып, гомерлек нык оя корырга юл ачыла дип өметләнгән иде. Дүрт төн буенча хатыны Мәрхәбә белән дә күп сөйләштеләр. Тегендә, Алатауда булган өйне, табан, тугым, бөят, алап, арканнарны сатудан күпме акча чыгар, картлар монда авылның кай урамыннан урын бирер, ничек-ничек тезелеп китәрләр — менә шуның кебек тармакларны да нечкәләп сөйләшеп бетерделәр. Дүрт көн буенча яхшы-яманнан бер сүз әйтмәгән картның болай кинәт кисүе Шәйхелне аяктан ега язды:

— Әткәй, — диде, — алай каты әйтмә, мал дауламыйм, тик фатихаңны гына бир! — диде. Каты кыйналып ташланган эт үзенең ачулы хуҗасына ничек ялынып караса, чит җирләрдә өстерәлүдән җаны, йөрәге туйган, шуңа күрә яланнар, таулар, урманнар аша кышкы челләдә кар ерып, үзенә бер гомерлек оя эзләп кайткан бу крестьян Шәйхел дә атасы Нурыйның күзләренә шулай ялынып карады.

Ләкин карт аз гына да йомшармады; шундый ук рәхимсез, каты шелтә тавыш белән кисте:

— Сиңа нинди фатиха тагын! Ашаган табагыңа төкердең, ил алдында йөземне кызарттың. Инде сиңа фатиха кирәк булдымыни? Туй эчендә тавыш чыкмасын дип түздем, тиз югал, күземә күренмә! — диде. Карт крестьян үзенең бу

сүзләрен дөньяда башка һичкем белән уртаклашырга теләмәгән тулы хуҗалык, тулы аталык белән кисеп әйтте.

Тегендә, өй ишеге төбендә, бөтенләй юлча киенеп, толыпларда, шарф, пималарда ак сакаллы карт кода Шибай күренде. Нурый тиз-тиз атлап шуңа таба китте. Шәйхел кар өстендә көе катып калды. Җигеп маташкан кунак атын башка берәүгә бирде. Шунда, озатучылар дулкыны эчендә, яшь кодачалар арасында, чаналар тирәсендә кайнашкан хатыны Мәрхәбә янына барды, берәүдән дә яшерми кычкырып әйтә салды:

— Әйдә, хатын, әйберләрне җыйна! Атай безне куа, — диде, әрнүле ачу белән өстәде: — Бу комсыз карт дөмекми торып безгә якты көн булмас бугай... Кодалар белән бергә бу каһәр төшкән йорттан чыгып китәрбез, — диде.

Кунак килен бу дүрт көн эчендә каенанасы Фәтхиягә дә, килендәшләргә дә, Гөлбануга да — һәммәсенә бөтенләй үзләшеп беткән иде. Кечкенә сабый бала үз анасыннан көчләп аерып алып киткәндә нинди үткен кайгы эчендә булса, Мәрхәбә киленгә дә шулай тоелды. Тәнен үзенең кан тамырларыннан кисеп аералар кебек булды. Ләкин башка чара юк иде.

— Ходаем, ни булды, әллә син, юньсез, тагы талаштыңмы? — дип, иренең күзенә шашып карады.

Шәйхел, әрнеп, сүзне икенчегә сукты:

— Ярар, бу малларны үзе белән кабергә алып китә алмас! Өчтән бере минеке! Карт дөмеккәннең икенче көнендә үз өлешемне кисеп алырмын, — диде дә хатынын тизрәк әзерләнергә җибәрде, үзе, Уралдан, Алатаудан килгән чанасын чыгарып, кара атын җикте.

Хәзер кодалар белән бергә чыгып китәләр дә, авыл очына, Челем бабай Шәвәли картка баралар; аның өен җылытырлар, тамагын туйдырырлар, берәр атна торгач, яңадан үзләренең торган җирләренә юлга чыгарлар, әгәр барса, картны да калдырмаслар — Шәйхел менә шул исәпләр эчендә әйберләрен төяп, хатыны белән чанага утырды, шул исәпләр белән, мәзиннең азаны, маланларның шаулавы, хуш, сау булыгыз, сәламәт булыгыз, исән булыгыз, дигән бетмәс-төкәнмәс озату сүзләре дулкынында, карны чыжылдатып, бер-бер артлы тезелеп, кыңгырау белән чаптырып чыгып киткән кодаларга Шәйхел дә ялгыз чанасы белән иярде. Аларның атлар дулатып, кар-буран туздырып чабулары уңаена бераз барды да бабасы Шәвәли карт урамына борылды.

Кодалар, туйдан кайтканда ат тирләгән булсын дип, урау юл белән Бикьярга чаптылар.

Озатырга җыелган кешеләр: «Ярар, хәерле булсын, Гөлбануга бәхетле гомер китерсен», — диешеп таралдылар. Алдагы көннәр турында йөрәге борчылудан

килгән күз яшьләрен сөртә-сөртә, Фәтхия әби дә кызы Гөлбануның хәлен белергә, аның киләчәк гомеренә каратып җылы сүз әйтергә, күңелен сорарга уйлый-уйлый өйгә керде.

XVII

Үзән елга якты кояш астында көньяктан төньякка таба ялтырап ага-ага да алдына каршы чыккан ташлы тауларга барып бәрелә, бу киң биек ташларны үтеп чыга алмагач, кинәт кояш баешы ягына таба борыла да китә. Агым буенча сул ягында киң сазлыклар, тугайлар, болыннар, бай печәнлекләр тудыра, алар эчендә таллар үстерә, киң, зур якты күлләр ясый; уң ягыннан баскычланып-баскычланып тауның биек ак ярлары йөгерәләр-йөгерәләр дә, бу ак ташлар, елганың тирән ятуларыннан берсе турында кинәт тукталып, текә стена белән су өстенә асылалар. Моны үткәч, ташлар бетә, зур тау елгадан эчкә таба, сөзәкләнеп кереп, менә-менә дә куе урманга барып терәлә. Менә шул тауның көндезге кояшка караган сөзәк битләвендә Бикьяр сибелеп, чәчелеп утыра. Үзән елганың таулы ягына урынлашкан Бикьяр белән нәкъ теге көньяктан тауга килеп төртелгән җиргә, елга белән тигез почмак ясалган бай үсемле туфракка утырган Караюрга арасы, туры барганда, бер чакрымнан артмый. Уртада тАллары киселми зур үскән ике умарталык белән бер тегермән бар. Ләкин моның бөясе[1] тар, арык өстендәге такталары калтырап торалар, юлы бигрәк тә начар: җәй көне болында баткаклык бетми, арбалар тәгәрмәч күчәреннән баталар, кыш көне чана салулый, каршы очрашканда, юл бирә алмый йөдәп, тирән көрткә батып бетәсең. Шуңа күрә моннан тик җәяүлеләр, ат менгәннәр, тегермәнгә килүчеләр генә йөриләр. Каладан-калага сузылган комлы, ике ягы канаулы, каенлы олы юл Караюрганың югары башыннан үтә дә, тигез яланнар, игеннәр аркылы барып, Бикьярны аша чыгып китә.

Кодалар алты-җиде чакрым ураулыкны исәпләделәр, менә шул олы юлга, ат тирләсен, ичмасам, дип чыктылар. Күз күргән бөтен дөнья, әллә кайдан-кая баскычланып менгән таулар, киң басулар, урманнар, Үзән елга буйлап сузылган тигез болыннар — һәммәсе тирән ак кар белән төренгәннәр, һәммәсе якты кояш астында гаҗәп бер матур саф аклык белән ялтырап уйныйлар иде. Закир бу киң кар диңгезен гомерендә беренче тапкыр күргән кебек булды, йөрәге киңәеп, рәхәтләнеп китте. Бу туй, бу никах, кыз куенында үткәрелгән бу дүрт тәүлек аның тәнен, җанын шатлык белән тутырды, теле белән һичбер вакыт әйтеп бирә алмый торган бер бәхет дулкыны эченә алып кергәндәй итте. Ялтыр кар диңгезе эченнән чабулап барган атлар, әле 'бер якка, әле икенче якка салулап ташланган чаналар, шуларга утырып барган атасы, анасы, агалары, җиңгәләре, апалары —

[1] *Бөя* - буа

һәммәсе шулай шаттыр, шундый ук бер бәхет дулкынында үзләрен-үзләре белми чайкалып баралар кебек тоелды.

Шул тойгы эчендә болынны, Үзән елганы аша чаптырып чыкты; шуның эчендә тау битенә сибелгән салам түбәле өйләр арасыннан зур урам буйлап югарыга таба чаптырды; исәнләшкәнгә дә, исәнләшмәгәнгә дә көлеп карады, бер сүз кычкырып әйтәсе, якын итәсе килде. Кыңгырау шалтыратып, чыбыркы шартлатып, чаналарны карда чажылдатып, ат чаптырып үзләренең такта түбәле өйләренә кайтып кергәндә дә, анда каршы алырга җыелган егет-җиләнгә, күрше-күләнгә дә Закир көлүдән авызын җыя алмады, шатлык, бәхет дулкынында йөзгән кебек күренде. Яшь күңелле тавыш:

— Гаҗәп инде, малай, — дигәләп, сүзләрен бутап бетерде.

Нечкәләп сорашырга азапланган якын иптәш егетләренә шундый ук җәелгән авыз белән җавап кайтарды:

— Сөйләмә инде, малай: караюргалар үзләре әйбәт, үзләреннән кызлары әйбәт! — дип, тәмләп, баллап-майлап сөйләп китте.

Бер җиреннән башлап, аны бетерми икенчегә ташланган бу сүзләрдә Гөлбануның йөзе дә, тәмле сүзе дә, сөрмә тарткан күзе дә калмады. Уймак кебек кечкенә авызы да, нечкә биле дә, аккош кебек йөреше дә кырык кат кабатланды, өстендәге киемнәре, алсу күлмәкләре, зәңгәр шәлләре, тәңкә-чулпы, йөзек-беләзекләре — һәммәсе-һәммәсе макталып, яратылып телгә алдынды; кызның куштанлыгына, ничек иркәләнүләренә тагы тәмләп тукталды. Өйләнмәгән яшь егет иптәшләр Закирны сырып алдылар, бер сөйләгәнне кырык кат яңарттыра башладылар. Ул, тагын ипләп сөйләрмен әле, ди-ди, чак котылды. Чанасыннан киемнәрен, букчасын, бүләк сандыгын алды да, тулы бәхет белән атлап туры ак өйгә, әткәсе ягына керде... Керде дә гаҗәпләнеп катты: әле бергә туйдан кайткан өлкән апасы Хәерниса, еларга җитешеп, анасы Сабирага нидер сөйли, нәрсәдер аңлатырга, нәрсәдәндер тыярга азаплана. Үзләре әле юлдан кайтып юньләп җылынмаганнар, башларыннан карлы шәлләрен салып та өлгермәгәннәр. Егет, аптырап, бер анасына, бер апасына карады, ни әйтергә белмәде, Сабира әллә кайчаннан җыелып килгән зәһәр белән чәчрәнә бирде:

— Әйттем, мең кат әйттем мин аңа: катышма, катышма шул затсыз Саесканнарга, дидем... Юк, тыңламады. Имеш, мәһәр дүрт йөз, диләр, ике йөз сумы кулдан акчалата, диләр, минем аңа көчем җитми, дигән булды. Менә инде борыны белән... барып егылды, адәм мәсхәрәсе булдык бит... — ди.

Анасының бу сүзләрен Хәерниса, еларга җитешеп, бүләргә тырыша:

— Әнкәй, нигә юкны сөйлисең? Бик әйбәт, бары да бик әйбәт! Кара халык —

кара сарык, диләр. Безнең кара мужикның сүзе бетмәс, мин үзем кереп күрдем. Бик әйбәт. Буе-төсе дә әйбәт. Сүзе дә әйбәт. Мин аңа кара алтынлы куш беләзек бирдем. Ул миңа менә нинди матур йөзек бүләк итте, юкка начар телләнмә, бары да бик әйбәт, бер дә мәсхәрә юк...

Карчык, кызының өстенә таба килеп, каты җикеренде:

— Әйбәт тә әйбәт! Нәрсә әйбәт? Атыңның койрыгын кисеп кайтардылар, шулмы әйбәт?! Анаңны Саескан килене дүрт көн буе талады, шулмы әйбәт?!.

Сабира белән Хәерниса шулай әрләшеп торганда, як-ягына какырынып, кулына комган тотып, Шибай карт бәдрәфтән килеп керде. Хатынының соңгы сүзеннән талашның нәрсә турында икәнен аңлап алды да ишек төбендә торган таягына ташланды. Закир белән Хәерниса чыгып качтылар. Балалары белән сызарга исәпләгән Сабирага Шибай карт гәүдәсе белән ишек каплады, җибәрмәде, гадәтенчә, яман, усал, пычрак, ямьсез сүзләр белән санап-санап, урысча сүгеп, хатынын кыйнарга тотынды:

— Көндәшеңә атланып йөрдең! Ахры ул бичараны мыйшаяк ашатып үтердең! Мин моңа да күз йомдым. Гомер буе минем җанымны әрнетеп килдең. Инде төпчек улым Закир белән яңа ярәшкән киленең Гөлбануның бәхетен ашарга керешкән икәнсең...

Шулай әрләп, хурлап, ахры гадәттәгедән катырак кыйнап ташлагандыр: Сабираның яулыгы ертылып, чәчләре тузды, телгәләнгән күлмәк эченнән яраланган, кара янган тәннәре чыкты: «Уф, уф... үләм... уф!..» — дип, тирләп, күбекле авызыннан телен салындырып, идәнгә егылды.

Карт аз гына да кызганмады.

— Күз алдымда ятма, ичмаса, — дип, аягыннан өстерәп, мич алдына, чаршау эченә таба кертеп ташлады да үзе шунда ишек төбендә, калай ләгәндә, намазга тәһарәт ала башлады.

Закирның башы бераз әйләнеп куйган кебек булды. Тулы бәхет савыты, әйтерсең, читтән бер кул белән әзрәк селкенде, андагы тәмле балга кемдер кара дегет тамызды. Берәүгә бер сүз әйтмичә, азбарга, әле һәммәсе ябуланып, бәйләп куелган тирле атлар янына барды. Берәм-берәм һәммәсенең койрыкларын карады. Авылда, мужик арасында, капкага дегет ягу белән кодаларның, кияүнең ат койрыкларын, ат ялларын тунап кайтарганны ул күп күргән иде. Озаклап карады: берсендә дә бернәрсә юк, һәммәсенең койрыклары, яллары урынында. Тик атасы төпкә җиккән зур күкнең койрыгыннан биш-ун кылны кисеп алганнар булса кирәк. Моны да, беленмәсен дип, тигезләгәннәр, кисүдән калган кыл төпләрен бөтенләй йолкып алганнар. Чит кеше бернәрсә дә аера алмас. Тик Закирның ун ел буена бу атны көн дә күреп өйрәнгән күзе генә, бик нечкәләгәч,

моны аерып таба алды.

Бу ни эш икән? Әнкәй нигә бик дулый? Гөлбануның электән йөргән егете булдымы икән? Миңа дигән кызны алды дип, үч итеп кисәргә маташтымы икән? Ул кем икән? Караюргада чакта нигә бернәрсә дә беленмәде икән? Крестьян егетенең бәхетле йөрәге болар белән бер борчылды, бер ачуланып кайнашты, ләкин аңа янарга җитәрлек ут булмады. Ул анасыннан яисә апасы Хәернисадан сорашырга булды. Тагы бит анда Карамалының кибетче Шәрәкәй кызы дип тә сөйләнәләр. Дүрт йөз мәһәр сораган, имеш, ике йөз сумын кулдан акчалата бирегез дигән, имеш!.. Әллә әнкәй миңа шул кызны алып бирергә чамалап йөрдеме икән? Юк инде, Шәрәкәй кызы минем Гөлбануга җитә алмас...

Шулай, үз башындагы уйларның нигезләрен, очларын таба алмыйча, егет апасы Хәернисаны эзләп китте. Ул бит Гөлбануны яратып сөйли. Аңа кара алтынлы куш беләзек бирде, аңардан алган матур йөзеген урта бармагыннан салмый киеп йөри. Ул барын да әйтеп бирер.

Егет ялгышмады, апасы Хәерниса аңа яшь бикәчне Закирның үзеннән дә бигрәк яратып сөйләде:

— Әнкәйнең, — диде, — башта ук күңеле Карамалыда иде, диде; ул, диде бай җир, зур җир дип санап, шул кибетче Шәрәкәйнең кара шадра кызын алабыз дип тилереп бетте, үз сүзе булмаганга, хәзер инде караюргаларны тирги дә тирги, — диде.

Хәерниса авылда кияүдә иде, ире бик ашыкса да, бу талашларның дулкыны әзрәк басылганчы китәргә көче җитмәде, анасының котыруларына каршы Закир алдында караюргаларны, Гөлбануны якларга бөтен җаны-йөрәге белән үзен бурычлы тапты. Бу аның акылыннан килмәде, үзенең җизнәсе белән бер чуаш хатынынннан башка һичкемгә беленмәгән бер авыр язмыштан килде. Шул авыр язмыш аны Гөлбану белән якынлаштырды; шул аны яшь бикә, яшь килен ягыннан Әремтел Сабирага каршы калкан булып барырга эчтән — күңелдән омтылдырды. Йөрәк төбендә еллар буенча яшерен яткан көч, Гөлбану аркасында, яңадан уянып чыкты. Гөлбану белән Хәерниса язмышын әллә нинди җепләр, тамырлар белән бәйләнгән кебек ясады.

## XVIII

Шибайның икенче хатыны Бәхрия бала тапмады. Шул сылтау белән ир Кәҗә Солтанның ун ел утырган кызы Сабираны зур бирнә, байтак мал белән бер тиен мәһәрсез хатынлыкка алды. Ул вакыт әле Шибай, авылда староста булгалап, аз-маз үсәргә, урыс түрәгә ярап, кантунлыкка таба юл салырга азапланган чаклары иде. Хатын артыннан килгән мал белән берьюлы аякка басты. Шуның белән бергә элекке хатыны Бәхрия бөтенләй ялчы, асрау дәрәҗәсенә төшеп калды. Ул

эшчән, тырыш һәм Алласыннан, иреннән, кеше теленнән бик куркучан иде. Бу йортка төшеп, ике ай үтмәде, Сабира аның җилкәсенә менеп атланды, көндәшен бөтенләй олтанга әйләндерде. Йортта бөтен хуҗалык Сабира кулына җыелды, барлык кара эш Бәхриягә йөкләнде. Дүрт-биш сыерны иртә-кич ул сауды, көтүгә ул куды, кич ул каршы алды. Кыш көне кырык-илле бәрәнне, өйгә ябып, ул карады, иртә-кич сарыкларны кертеп, имезеп чыгаручы ул булды. Икмәк пешерүче, ике өйнең мичләрен ягучы, идәннәрен юучы, аш пешереп, самавыр әзерләп кертүче, барлык керләрне юучы — карт көндәш Бәхрия булды. Ир боларны күрде, ләкин сүз әйтмәде; тик яшь хатын үзенең көчен иренә каршы да куярга, Шибайның үзенең җилкәсенә таба да үрмәләргә итә башлагач кына, яшеренгән каты крестьян тырнакларын чыгарды. Ир хуҗага карышуның ярамавын каты кул белән, ул үтмәсә, каеш чыбыркы белән аңлатырга тырышты. Сабира бу кыйнаулардан бик күп газап татыды. Йөзе-күзе канланып, бите-башы ертылып, адәм күзенә күренергә оялырлык чаклары күп булды. Һәр таяктан соң бераз вакыт ул йомшарып йөри, иренә сүз кайтармый, ләкин берәр әйбер килеп чыга да, ачудан, әрнүдән йөрәге кузгала, үзен-үзе белми, кем очраса шуның белән әрләшеп, талашып китә. Иренә дә барып бәйләнә. Тагы каты кул, тагы таяк, тагы чыбыркы. Ләкин ул тыела алмады, иреннән ашаган кыеннарын, әрнүләрен башкалар өстенә түгә торган булды. Шуның аркасында аның начар холкыннан һәммә кеше бизде. Телдә хатыннар, карчыклар арасында аның турында:

— Сабирага йомышың төшмәсен.

— Сабира белән каберең янәшә була күрмәсен.

— Сабирага барганчы, эткә бар, — дип сөйләшәләр. Артында:

— Аждаһа! — дип,

— Гыйфрит! — дип,

— Котырган эт! — дип тиргиләр иде.

Ләкин ул көннән-көн баеп барган, урыс түрә тирәсендә дә әйләнгәли торган хәлле солдат-ефрейтор мужикның хатыны иде. Теләсәләр, теләмәсәләр дә, аны ашка-чәйгә чакыралар; ул чакырса баралар, бурычка әйбер алалар; сораса бирәләр, алдында әйбәтләнеп:

— Сабира апа,

— Сабира җиңги,

— Сабира килендәш, — дип дәшәләр, якты чырай күрсәтәләр иде.

Карт көндәш Бәхрия чыдамады. Кышкы бер төндә ике сыер берьюлы бозаулаганын ялчы кереп әйтте. Хатын, туңып үлә күрмәсеннәр дип, күлмәкчән, оекчан кар өстеннән чыгып, азбарга йөгерде. Икесен аналары белән

җылы өйгә кертеп япканчы әллә ничаклы вакыт үтте, бик каты суык тидерде, укшып-укшып ютәлли башлады. Ике ел шулай өстерәлде дә көзге пычракларның берсендә дөньядан үтте. Аны үлде дип кызганучы булмады, киресенчә: «Ярар, ичмаса, җаны тынычланды», — диештеләр. Озын телләр арасына гайбәт тә таралып өлгерде: «Хәстәлеге өстенә Сабира мышьяк биргән икән, азлап, тоз арасында икмәккә сибеп биргән икән», — диделәр. Тикшерүнитү булмады, тик Шибай карт кына, бик әрнеп, кыйнаган чакларда: «Син көндәшеңне агулап үтердең», — дип шелтәли торган иде.

Көндәшеннән соң Сабира бер үзе калды. Шибай бу хатынын бераз авызлыклар өчен аннан-моннан искәнгәләсә дә, бирүче дә, килергә теләүче дә булмады. Сабира өстенә көндәшлеккә берәү дә үзе дә бармады, иң каты күңелле аталар да кызларын көчли алмадылар.

Шулай Сабира бер-бер артлы туып торган балалар анасы булып, ялгызы йортка хуҗалык кылды. Шибайның иң беренче хатыны Бәхрия түгел, аңардан элек ул Мәргыя атлы бер кызга өйләнгән иде, бусы, ел ярым торгач үлде, Алтынбай исемле ике айлык баласы калды. Бу сабый, Бәхрия исән чакта, аның канаты астыннан китмәде, Сабираны күрү белән, бүредән качкан бәрән кебек, акырып кача иде. Карт көндәш үлгәч, үги ана бу малайга кыйналмаган һичбер көн бирмәде, баланың тамагы тәмле аш татымады, өстенә-башына хәерче кебек сәләмә киенде, күлмәге ямалмады, юылмады, — шулай үгилекнең каты кулында чыбыркыланып, җәй көне ялангач тәнгә кычыртканланып үсә бирде.

Сабира үзе күп орлыклы булып чыкты. Барлыгы унбер бала тапты, боларның алтысы яшьләй үлде, берсе сугышта хәбәрсез югалды, ике кызы, ике улы өлкән булып, дөньяга чыктылар. Ләкин һәммәсе холыклары белән аталары Шибайга тарттылар. Арада Сабираның яратып, кадерләп үстергәне — кызлары булды.

Бу ике кыз бер-берен таптап үстеләр. Аралары бары яшь ярым гына иде. Буйга тигез килделәр. Ләкин холыклары бер-беренә охшамады. Зуррагы, Миңниса, бик яштән үк эш сөючән булды. Кечкенәсе, Хәерниса, уен-көлкене, җырны, биюне күбрәк карады... Икесен бөтенләй бер төсле киендерергә, бер дәрәҗә бирнә әзерләргә тырыштылар. Ләкин кызлар үзләре бу эшкә ике төрлерәк карадылар.

Зурысы, Миңниса, ялан эшләрен батырып эшләде. Утауда, урак, печәндә, ашлык сукканда ирләр белән бер уңайдан җимереп барды. Йортның кара эшләрен, бозау, бәрән карауларын, сыер савуларын тәмләп башкарды. Болардан бушады исә, бирнәсенә тотынды: көз, кыш чигүенә, каюына, тегүенә утырды, исәпсез күп сөлгеләр, киҗеле ашъяулыклар, чаршаулар, чыбылдык, чолгау, намазлыклар, киндер күлмәкләр, шарфлар, бияләйләр белән кайнашып чыкты.

Атасы белән, анасы белән шулар өчен елап-елап әрләште. Ләкин кечкенәсе, эш-хезмәт дигәндә, һаман үзенең яшьрәк булуыннан файдаланды, мин белмим диебрәк, качты. Апасы канаты астында бара торгач, чыннан да, бу эшләрнең һичберенә кулы остармады; кеше алдында сеңелесен оялтмас өчен, Миңниса үзе килеп, шаярган булып булышып ташлый торган булды. Хәерниса, дөньяның каты хезмәтләрендә апасына таянып, үзе күбрәк уен-көлкегә таба дулкынланды. Җәй булса, кызларның киндер киптергән, тукмаган чакларында, беренче шайтан ул иде. Кызлар җыелып тауга чыксалар, сабан туена барсалар, кыз озатырга, килен төшерергә җыелсалар, мең төрле вак хәйләләр белән анасын ризалап, анасыннан елап рөхсәт алучы, апасын үзе ашыктырып, үзе шаяртып киендерүче ул була иде. Аулак өйләрдә, көзге каз өмәләрендә иң күп котырган, иң күп җырлаган, иң күп биегән кыз Хәерниса була иде. Берничә тапкыр, ишекне юри биксез калдырып, аулак өйгә гармунлы егет кертте. Бер керткәндә, бик әрсезләнә балалагач, егетне югары киштәгә аягыннан асып куеп, мәсхәрә кылу көлкесен ул башлады. Аның бу шаянлыгы авылга таралды, гайбәткә керде, барып атасы Шибай картка иреште. Ул: «Кызларыңны карый белмисең, начар җиргә аулакка җибәрәсең», — дип, Сабираны каты кыйнады. Миңниса белән Хәернисага андый урыннарга бармаска дип кисеп куйды. Ләкин үткен кыз тыелмады, атасыннан, анасыннан эләккән кыйнауларга бер дә исе китмәде: «Җә, ярар, үтермәс әле: бер кыйнар да бер туктар!..» — дип карады. Җае чыкса, юнен таба алса, аулак өйләргә, качып-посып булса да бара бирде.

Апасы аны бик ярата иде. Үзенең авыр, басынкы холкын шатлык белән, уен-көлке белән тутырганга, үзендә җитмәгәнне сеңелесендә тапканга аны ярата иде. Тавышы-җыры өчен — «минем сандугач сеңелем» дип, уены-биюе өчен — «минем чикерткәм» дип шаяртып иркәли иде. Тик бер тапкыр шиккә төште.

Авылда Алабавыз дигән кушаматлы бер егет бар. Бай нәрсә. Ялгыз атасыннан башка беркеме дә юк. Менә шул чыннанмы, шаярыпмы сөйләнеп йөргән була ди:

— Шибай картның Хәернисасына яучы җибәрер идем, апасы Миңниса комачаулый, — дип әйтә ди.

Кыз моны ишеткәч әрнеп куйды: әгәр аның башы ашасыннан сеңелесенә яучы килә башласа, бу хурлыкка ничек чыдар? Ләкин бу борчу озакка бармады, җилбәгәй егетләр болай сөйләнсә дә, халык авызында үзен яратып, мактап телгә алуларын ул бик еш ишетә иде. Һәм ялгышмады. Теге Алабавызның лыбырдавыннан атна үтмәде, яхшы җирдән башкода килде. Ризалык сорамадылар, ләкин Миңниса, чит кешеләрдән ишетү буенча, йөрәгеннән күнеп, рәхәтләнеп торды. Артыннан сеңелесе куып узганчы үзенә кияү чыгуга

бик шатланды. Бу эшләрне апасыннан бигрәк Хәерниса дулкынланып каршылады. Үз туен көткән кебек: «Кем икән? Нинди егет икән? Матурмы икән?» — дип, сабырсызланып көтте. Апаның бәхете икән: кияве таза, чибәр, кара кашлы, кара күзле, борылып, югары күтәрелгән кара мыеклы, уңган, үткен, шаян, уенчак бер егет булып чыкты.

Туй чорында иркенләп күреп сөйләшә алмады, аннан атна саен пәнҗешәмбе килеп, җомга торып, ике төн кәләш янында кунып китә торган булды. Балдызлар җизнәләреннән качмыйлар. Һәркем дә шулай.

Кияүнең өченче килүе иде. Өчәүләп чәй эчеп утырганда тегеннән әнкәсе Миңнисаны чакырды. Кыз йөгереп чыгып китте. Байтак вакыт анда чуалды. Менә шул чакта кияү үзенең эчке кесәләрен актарды, матур буяулы кәгазьдә исле сабын, яшькелт төсле ислемай, кечкенә кызыл тартмада иннек, кершән, тагын кызыл кәгазьле, озын чуклы, озын, йомшак, тәмле конфетлар чыгарды. Һәммәсен берьюлы Хәернисага төртте дә әллә нинди калтыраулы, борчулы тавыш белән:

— Балдыз, мә, сиңа зур сер! Миннән бүләк! Берәүгә дә әйтәсе булма берүк! — диде.

Кыз ни кылырга белмәде, ялт-йолт тирә-ягына каранды, һәммәсен күлмәк җиңенә тыгып җибәрде, яшь йөзенә кызыл кан йөгерде, тиз торып, шәлен ябынды да:

— Апай, син кая? Озак йөри дип сиңа җизни ачулана монда... — диде. Апасын эзләп, Миңниса артыннан аны чакырырга чыгып югалды.

Шул көннән җизнә белән балдыз арасында нечкә җеп сузылды; ике күңел, һәр икесе бик курыккан, каушаган хәлдә, бер-беренә тартыла торган булдылар.

Апа һичбер әйбер белмәде, һичнәрсәдән шикләнмәде, тик бервакыт җизнәсе киткәч, Хәернисаның күз эчендә тәгәрәргә әзерләнгән бер бөртек яшь күреп, гаҗәпкә калды, ләкин миенә бертөрле дә начар уй килмәде.

— Ни булды? — дип сорады. Хәерниса, гадәтенчә, шаркылдап көлде:

— Ни булсын, чүп керде, — диде.

Тагы бервакыт кияү өй буендагы кечкенә бакчаның текмәләренә сөялгән дә ялгызы гына, акрын гына моңланып тора. Миңниса аяк очы белән килде, колак салды, тагы бераз гаҗәпсенде:

Елама, балдыз, калдырмам ялгыз...
Елама, балдыз, калдырмам ялгыз...
Елама, балдыз, калдырмам ялгыз...

Кияү менә шул сүзләрне авыз эченнән һаман көйли дә көйли.

Хатын начар әйбер уйламады.

— Шулай шул, балдыз апасыннан матур булырга ярамый шул... — дип, билгесез бер күңелсезләнү эчендә югалды.

Җәй көне Миңниса ата йортыннан кияү-каената йортына озатылды. Кияү белән кыз башта унбиш көн саен, аннан ары ай саен диярлек бу өйгә кунакка килә торган булдылар. Кышкы чилләдә, бер кунакка килгән чакта, балдыз үзенең җизнәсенә авыр куркыныч серен ачты: «Карынымда өч айлык балам бар», — диде дә, йөзен каплап, кызарып, азбарга, сыерлар, атлар арасына качты. Бу аның өчен, чыннан да, һичбер төрле чарасы күренмәгән искиткеч зур кайгы иде. Кыз башта аңламады, аңлагач — ышанмады, ышангач — зур дилбегә алып, азбар өрлегенә асылырга уйлады. Бикьяр ташыннан тирән суга ташланмак булды, ләкин аның яшь, сәламәт тәнендә тереклек куәте бик артык көчле иде. Үлемгә бара алмады, үлемнән качты, бу хурлык белән яшәргә дә мөмкин түгел иде. «Ходаем, ни эшлим, ни эшлим, ни эшлим? Башымны ташка орыйммы? Бер якка чыгып качыйммы? Кая барыйм?» Менә шундый газап вакытында ул серен ачты.

Җизнәнең тамагына аш бармас булды. Төнлә күзенә йокы кермәде. Шулай газап эчендә әйләнде-әйләнде дә, икенче көн, бер аулак туры китереп, әйтте:

— Акыл таптым. Әткәңнән сора. Безгә бер айга утырмага бар. Шунда өйрәтермен, елама, — диде.

Ата-анасы Хәернисаның апасына утырмага баруына каршы тормадылар. Кыз, үзенең зур кайгысын каплар өчен, тегү-чигүләрен, каюларын алды да җизнәләренә утырмага китте.

Кияүнең чарасы болай иде:

Кыз үзенең кайгылы серен, бөтенләй икенче төстә итеп, апасы Миңнисага сөйләячәк. Авыл егете аулак өйдә көчләде, шуннан балага уздым, хәзер дүрт айлык, дип әйтәчәк, бер чара табуын үтенәчәк. Хатын түзмәс, иренә сөйләр. Ир-җизнә акыл бирер:

Мәсәйлебашта им-томчы, күрәзә-сихерче чуаш карчыгы бар. Бала төшерергә дә бик оста икән. Чакырган җиргә ун сумга үзе бара икән.

Ирне, бер хөкем эшендә шаһит итеп, калага алдыралар. Менә шунда киткәндә, ул үзе сикерче карчык белән сөйләшер, аңа кайчан килергә икәнен әйтер.

Балдыз, мондый куркыныч чараны ишеткәч, сабый бала кебек үкереп-үкереп елады. Ләкин башка юл юк иде. Шуңа риза булды. Җизнәсе калага киткәч, караңгы бер төндә, юлаучы чуаш карчыгы белән чуаш карты бу йортка кунарга төштеләр. Карт тышта ат, чана янында озак торды, аннан соң, мал өенә кереп, мич башында йокларга ятты.

Карчык үзенең саргаеп, каралып кипкән, тамырлары чыгып каткан ябык, каты

куллары белән Хәернисаның тәннәрен, билләрен, эчләрен сыйпады, әзерләп алып килгән әрем кайнатмасын көчләп эчерде. Бу — гаҗәп бер тәмсез, әче нәрсә иде. Шуннан ике сәгать үткәч, кызу ягылган кара мунчага алып барды. Кызны ләүкәгә сузып яткырды, апасы Миңнисадан ут кебек кызган ташка чүмечләп-чүмечләп су салдырды. Мунча җәһәннәм кебек кайнады, кызуга чыдарлык хәл калмады, сулыш алырга һава бетте, чуаш карчыгы үзе, кызның түзә алмый акыруына карамастан, ләүкәдә аны туктаусыз әйләндерә башлады. «Тагы сал, тагы сал, кызу җитми», — дип акырды. Миңниса белән Хәерниса: «Үләбез бугай, үтерә бугай», — дип, башларын югалттылар, ләкин каршы торырга хәлләре булмады. Чуаш карчыгы шул җәһәннәм кызуы кебек мунча ләүкәсендә өстеннән шапырдап тир аккан, хәле бетеп, һушыннан язар чиккә җиткән кызны һаман туктаусыз әйләндерде; әйләндерде-әйләндерде дә, карт сөяк тезләре белән кызның эчен, үтерердәй авырттырып, чәнечтереп басты, изде. «Тагы сал, кызу юк», — дип пышылдады, тагы әйләндерде, тагы тезе белән кызның эчен-карынын изде дә — үзе үк артка ташланып, мунчаның ишеген, төнлеген ачып җибәрде.

Шул төнне үк баладан котылганлык билгеле булды. Бер атна үтүгә инде Хәернисаның хәле, сәламәтлеге үз җиренә кайтты. Ләкин элекке җиңел, уенчак, шат кыз кайтмады. Бу бәхетсез гыйшык, бу куркыныч, авыр хәлләр аның ниндидер шатлык тамырларын кискән кебек, ниндидер яшь дәрт чишмәләрен корыткан кебек булдылар. Ул элекке матур, уенчак, җиңел музыкалы тавышын да югалтты, элекке шаян сөю җырлары аның теленә, ничектер, килми башладылар; ул озын, авыр көйләргә салып, хәсрәт җырлары белән моңлана торган булып китте. Шуның белән бергә җизнәнең дә, апа белән кызның — өчесенең дә башына бер-беренә әйтелмәгән кайгы кереп утырды. Хәерниса унҗиде тулып, унсигезгә чыкты. Яучылар, башкодалар йөриләр. Әле хәзергә, төрле сылтаулар чыгарып, Шибай картны тотып киләләр. Ләкин ул бит үзсүзле хуҗа! Бер киреләр, ике киреләр дә өченчесендә, һичкемгә киңәшмичә үк, килешеп тә куяр. Ничек тә бит матур, үткен Хәерниса гомергә ата йортында тора алмас, беркөн кияүгә чыгарга туры килер! Менә шул вакыт ни булыр? Шул вакыт тагы нинди, тагы нинди авырлыклар басарлар?!. Күптән түгел Бикьярның Рәгыя дигән бер кызны кияүгә биргәннәр иде. Башта ук гайбәт күп иде. Егет туй вакытында дүрт көн кунды да яңадан килмәде. Кыз да, аталары да, ил алдында мәсхәрә булып, дөнья йөзенә күренә алмаслык хурлык эчендә калдылар.

Шундый авыр куркыныч борчулар астында ел ярым үткәч, Хәернисага көмешче Әфтәх дигән егеттән яучы килде. Артык мактарлык түгел, борган кара

мыеклы баһадир җизнәдән соң тәбәнәк буйлы, кысык соры күзле, саргылт йөзле Әфтәх, әлбәттә, әллә кая югалып кала иде. Ләкин җизнә дә, апа да: «Әйбәт, сабыр кеше», — дип димләштеләр. Тагы нинди хурлыклар күрәсем бар икән, Илаһым хуҗам, дип, кыз төнге күз яшьләре эчендә туен көтте. Ул һәммә нәрсәгә, һәммә нәрсәгә, һәммә нәрсәгә риза иде. Кыйнасын, суксын, ач тотсын! Тик, ил алдында мәсхәрә кылып, ташлап китмәсен! «Мин алдандым, хур булдым!» — дип тавыш чыгара күрмәсен! Кыз менә шуны теләде, аягын үбәрмен, йөргән җиренә туфрак булырмын, дип эченнән нәзерләр, сәдакалар әйтте.

Җизнә үз ягыннан чаралар күрде. Туй якынлашкан саен, юк йомышны бар итеп, Бикъярга, бабаларына килә торды, ничек үткәрү якларын кайгыртышты. Өндәүчеләрнең зуры, башы итеп Бәдгытдин атлы бер якынын җибәртә алды. Моның мәгънәсе шунда чыкты: гадәттә, кияү үзенең аталары, кодалар белән бергә аерым чанада туйга килә дә, никах укылганчы, өндәүченең йортында берничә сәгать вакыт үткәрә. Аннан соң гына, кыз хатына алып барып, зөфафка биклиләр. Менә шул өндәүче йортында үткән берничә сәгать вакытны җизнә үзенчә файдаланырга уйлады. Бәдгытдингә шаярып әйтте: «Үпкәләр бит, кияүне нигә әзрәк сыйламыйсың, ул төшерергә ярата бугай», — диде. Үзенең мужик исәбендә егетне кыз янына бераз кызмача кертүне уйлады. Кияү, чыннан да, кире какмады. Чәй, аш арасында аңа бер чынаяк бирделәр. Ул йотты да җибәрде, эчкән кебек тә булмады. Тагы бирделәр, тагы да аударып кына салды, тагы эчте, ләкин аз гына да исермәде, тик күзләренә бик нечкә генә томан пәрдәсе күтәрелгән кебек булды. Җизнә борчылды: «Инде Алланың үзенә тапшырдым», — диде.

Туй искиткеч шома үтте. Егет үзенең яшь кәләшеннән бик канәгать булды. Апа белән сеңелнең бәхете башларыннан ашты. Хәерниса өчен иң зур бәхет — кияүнең аңа ышануы булды. Менә шул ышаныч өчен кыз аңа үзенең тулы, тирән мәхәббәтен бөтенләй бирде; шул ышаныч өчен ярым крестьян, ярым вак һөнәрче, көмешче Әфтәх — кызга дөньядагы һәммә ирләрдән яхшырак, кыйммәтлерәк булып китте.

Аның йөрәгендәге теге авыр куркыныч серләр әллә кая, төпкә төшеп, кара кан булып утырып калдылар. Өс якны тыныч бәхет каплады. Йөрәкнең менә шул ике төрле кайнашы Хәернисаның бөтен гомеренә һәрвакыт, һәркайда үзен күрсәтә торган тирән эз калдырды. Кыз язмышы, кызларның алданышы, кызлар турындагы ялган гайбәтләр күтәрелеше — аның йөрәгендәге төпке кара канны кузгата, аның тынычлыгын ала торган булдылар. Кырык яшькәчә күп хәл кичерде, ләкин бу тынычсызлыктан һичбер вакыт котыла алмады.

Энесе Закирны өйләндерү турында сүз кузгалгач, Хәернисаның күңеле аз-аз дулкынлана башлаган иде. Килешеп кайткан Гөлбану турында озын колакның начар гайбәтен ишеткәч, ул түзмәде, һичкемгә белдермәстән, Сәрби карчыкны чакырды, сәдакага бер күлмәк бирде дә тегермән бөясе аша, Үзән елга болыннары буйлап, аны Караюргага җибәрде:

— Урам гайбәте белән кайтма, Мәфтуханы күрергә тырыш. Читләп тә сораш, — диде.

Ләкин карчык төпле бер әйбер китерә алмады, Мәфтуха, гәрчә Хәернисаның килен булып төшкән авылыннан булса да, гәрчә алар бер-берен яратышкан кебек йөрсәләр дә, ул Хәернисадан бигрәк Гөлбануның матур җиңгәсе, аның якыны иде. Ике уртада йөргән яучы карчыкка әйтте:

— Ахирәтем Хәернисага әйт. Юк белән баш авырттырып йөрмәсен, бик әйбәт. Менә дигән кыз, яңа унҗидегә чыкты. Ул Лотфый кибетче егет белән бар гайбәт шул гына: үткән җәй урман буенда, печән җыйганда бергә туры килгәннәр. Шунда егет агач арасында сагалап торган да, кызны кычкыртып кочаклап үпкән. Кыз елап абзаларына, җиңгәләренә сөйләде. Менә бар гайбәт шул гына. Башка бернәрсә дә юк, юкка борчыла күрмәсен, — диде.

Хәерниса бу җаваптан тагы тирәнрәк борчылды. «Әйтергә яраганы бу булса, тел төбендә яшереп калдырганы күпме икән?» — дип уйлады. Әткәсе Шибайга елап әйтте:

— Һәр җиргә улларыңны гына йөртәсең, үткән туйга апа барды, бусына безне җибәр, — дип ялынды.

Сабира бу кызын яратмый иде, исәбе Миңнисаларны алып бару иде. Талашып караса да, картын җиңә алмады. Хәерниса ире белән бергәләп Караюргага, Гөлбануның туена бара алды. Кызны ул чын күңеленнән яратты. Закирга әйбәт хатын булырын да сизенде, аның курыкканы — теге юк-бар гайбәтнең таралуы, шуларның егет колагына ирешүе иде. Бу куркынычлар Гөлбану белән үз язмышын бәйләгән кебек булды. Анасы Сабираның анда, туйда чагында ук чыгарган талашларына, өйгә кайтып кермәс борын тагын шул ызгышларны кузгатуга аның борчылулары менә шуннан килде. Ул анасы Сабираның бик авыр холыклы икәнен кырык еллык гомерендә үз җилкәсендә күп татыды. Закир болай әйбәт егет үзе, ләкин кайбер вакыт бик беркатлылана, анасы сүзенә ятып, муенсызланып та куйгалый. Әгәр әткәсе Шибай карт исән торса тагы бер хәл инде. Аның өлкәнлеге, каты куллылыгы бар. Ул улларын да, Сабираны да, таяклабрак булса да, кеше алдында хурлыкка төшермичә, житәкләп илтер, ләкин аның да яше җитмешкә таба карый, үзе һаман авырый. Үткән ел яшь айгырдан егылып билен, аркасын имгәтте. Шуннан бирле һаман сызлана. Әгәр

ул үлеп китсә, монда инде җәһәннәм булыр. Башкалар ызгышырлар, тиргәшерләр дә эләктерә алганнарын күтәреп аерылып чыгарлар. Закир төпчек. Ул бит төп йортта калырга тиешле. Әле хәзердән үк болай җенләнгән анасы, Шибай карт үлеп, йөгәнсез, авызлыксыз калса, зур уллары ташлап чыкса, бәйләүдән ычкынган эткә әйләнер. Үзе дә хур булыр, бөтен нәселне дә ил алдында мәсхәрәгә калдырып бетәр...

Хәернисаның уйлары үзеннән Гөлбануга, аннан атасының авыруына, анасының холыксызлануларына күчеп, һичкайда җавап тапмыйча күп буталганнан соң, җәмәгать эчендә үзенең каты гадәт-йолалары буенча яшәгән һәрбер крестьян хатын өчен иң зур көч булып танылган нәрсәгә — ил алдында мәсхәрәгә калу, халык алдында хур булу, бөтен нәселне оятка салу кебек куркынычларга барып терәлде. Гөлбану белән үзен шул куркынычка иң якын торган корбан кебек тойды.

Туйдан кайту белән Шибай карт, Сабираны кыйнап ташлагач, тәһарәт алды да, таягын таянып, мәчеткә икенде намазына китте. Хәерниса, энесе Закир белән сөйләшеп, аның күңелендәге туй, никах, яшь чибәр кәләш шатлыкларын тагы дулкынландырды да кыйналып идәнгә ыргытылган анасына керде. Ләкин бу хатын нык икән: Хәерниса барып кергәндә яңадан аякка басты, елау һәм ачу тавышы белән хурланып акырынды:

— Аертам. Аертам дигәч аертам. Шул Саесканнарның әллә нинди этләр белән өстерәлгән кәнтәйләрен килен итеп үз йортыма китерер хәлем юк! Адәм мәсхәрәсе! Шуны аертмасам, исемем Сабира булмас... — диде. Тузган чәчләрен, ертылган күлмәкләрен юнәйтә башлады. Ишек ачты да йортка, улы Закирга: «Монда кер!» — дип кычкырды. Зәһәрләнеп, аны әрләргә, аңа ат койрыгын да, башкасын да, Саесканын да сөйләп бирергә әзерләнде.

XIX

Ләкин төп хуҗалык аның кулында түгел иде. Шибайның картлыгы да басты, бил чәнчүләре көчәеп, айлар, атналар тора алмый да яткалады. Шулай да, авызыннан җаны чыгып киткәнче, тезгеннәрнең һичберен һичкемгә бирергә якын килмәде; хатыны ничаклы дуласа да, егет-кияү Сабирадан бигрәк Шибай карт өргән җил уңаена бара бирде. Аның күңелен, йөрәген тутырган шатлык, бәхет дулкыннары кайбер вакыт анасы сүзе белән кара-лып-каралып киткәләделәр, ләкин боларның чишмәсе Закир белән Гөлбануның яшьлегендә, ике яшь йөрәкнең бергә тоташып ялкынлануында иде. Башта атна саен, аннан унбиш көнгә бер тапкыр егет үзенең яшь кәләшенә кияүләп барды. Моның өчен яшь кара айгырны солыдан чыгармады, төсе югала дип яхшы чанасын башка берәүгә дә җиктермәде. Бикәченә бүләк өчен акча кирәк булганда, Шибай

саранланып, җитәрлек бирми башласа, өсәктән урлап иген сатты, Караюргага, яшь кәләшкә барачак пәнҗешәмбеләрне, алдан бармак белән исәпләп, келәт бүрәнәсенә балта белән чабып билгели торды. Ул бөтен кышын, язын җимереп эш эшләсә дә, йортның барлык мәшәкатьләрен җилкәсендә алып барса да, күңеле белән һаман Нурый карт йортында, матур җыелган кияү бүлмәсендә, үзенең тулы шатлыгы Гөлбану янында яшәде. Печән өсләре якынлашу белән инде кыз озату, килен төшерү чорлары керер. Егет, моны һаман уйлап, үзенчә алдан әзерләнмәк булды, бердәнбер сердәше Хәерниса апасы килгән чакларда, аның белән киңәшә торды. Менә шулай барганда аның шатлык белән тулы күңелен көтелмәгәнрәк яктан сындырып җибәрделәр.

Базарда юк кына нәрсә өчен теге Сыераяк Хәмди белән әрләшеп китте бит. Бу-юньсез нәрсә икән. Аз сүзне кабартты да уеннан уймак чыгартып куйды. Нәрсә ди:

— Әй, — ди, — беләбез инде, борыныңны бик күтәрмә, — ди. — Синең үзеңне дә кеше ачкан чирәмнәрне генә сөрергә өйрәнгән диләр бит...

Бу сүзләрдән талашны тыңларга җыелган барлык, кешеләр, эчләрен уып:

— Ну, Сыераяк икәнсең, каптырдың бит Закирны, — дип, шаркылдашып, хахылдап көлештеләр.

Егетнең күз алды караңгыланды, ата-бабасы белән сүгеп, Сыераякның өстенә ташланды. Кыйнарга бирмәделәр. Бу, хурлыгыннан ни эшләргә белми әрнеп, башы катып, өенә кайтты.

Бүген кәләшкә барасы көне иде. Төш ауды, тарантас чыгарылмады, айгыр азбарда, улакта, ялгызы кешнәп, хуҗа егетне көтте. Шибай үзенең урамга таба салынган өенең тәрәзәсеннән берничә тапкыр карады: ат җигелмәүгә гаҗәпсенде, ләкин дәшми кичерде. Атна үтеп, икенче пәнҗешәмбе, өченче пәнҗешәмбеләр дә шулай калдылар. Айгыр чыгарылмады, тарантас җигелмәде, егет кәләшкә бармады.

Тегендә, Караюргада, Нурый карт өе өстендә кара кайгы капланды: кияүнең үз вакытыннан өч атна үткәч тә килмәве, җитмәсә тагы бертөрле дә хәбәр әйтеп җибәрмәве — бу инде һичкемнең башы күтәрә алырлык эш түгел иде. Гөлбану, борчылып, ашау-эчүен оныта торган булды, хурлыгыннан кеше күзенә күренергә, кеше белән очрашырга кыенсына башлады. Төннәрен мендәргә капланып елап үткәрде. Бәхетсезлек баскан кебек булды. Башта, яучы килеп йөргән чакларда, кибетче Лотфый аның йөрәген алган бердәнбер егет кебек иде. Гәрчә араларында, шул урман буенда, печән җыйганда, агач астыннан йөгереп чыгып, кочаклап үбүдән башка һичбер нәрсә булмаеа да, гәрчә аларның бөтен якынлыклары уракка, печәнгә, суга йөргәндә очрашкалап, күз кысу, каш

сикертүдән күп үтмәсә дә, гәрчә аулак өйдә, ишек төбендә кешедән качып-посып бирешкән ашыгыч вәгъдәдән, ике тапкыр алышкан бүләктән башка һичбер нәрсә белән алар багланмасалар да, — туйгача Гөлбану үзен Лотфыйныкы дип, Лотфый — үзенеке дип уйлый иде. Башка һичберәүгә бармаска, көчләсәләр, качып, Лотфыйга ябышып чыгарга эченнән ант итүләре тик менә шуңа нигезләнгән иде. Кыз бирелеп, туй башланганда, егетнең бернәрсә дә эшли алмавы, шул ат койрыгыннан башка бер һөнәр дә күрсәтмәве — Гөлбануның яшь күңеленә яра булып төште; Лотфидан йөрәген суындыруга, ул мине яратмаган икән, болай шаярган гына икән, дип уйлауга сәбәп булды. Шул яраланган йөрәк өстенә Алланың тәкъдиргә язып куйганлыгы капланды, кыз үзен язмышта Закирга билгеләнгән икән, шул тәкъдирдән узып, беркая да бара алмыйсың икән, дип уйланды. Шулар белән ул, ничектер, акрын-акрын Лотфыйдан китте, тәне белән генә түгел, күңеле, җаны белән дә Закир куенында җылы тапты, бар насыйбы шунда гына бугай дип, йөрәген беркеткәнгә ошады. Лотфый, каядыр түбәнгә, артка таба чигенеп, акрын-акрын бөтенләй югала башлады. Кияүнең биргән шатлыгы ничаклы тулы булса, Лотфый шул чаклы ерагайды. Ләкин Закир белән ике ара күңелсезләнгән чакларда, каенана Сабираның зәһәрләре килеп бәрелгәндә, кибетче егет тагы күтәрелә, кызның йөрәгендә тагы Закир белән янәшә урын өчен талаша башлаган кебек була иде. Мондый вакытларда Гөлбану үзенең печән җыйганда үбешкән көнен дә, аулак өйнең ишек төбендә очрашкан, вәгъдә алышкан, бүләкләшкән минутларын да сагынып куя, кайбер вакыт: «Илаһым хуҗам, нигә болай икән? Нигә миңа Лотфыйны язмадың икән», — дип кайгырып та ала иде.

Закир өч атна кичеккәч, кызның йөрәгендәге бу икеләнү тагы көчәйде. Ул тагы язмышны, тәкъдирне уйлап, Закир урынында нигә Лотфый булмады икән дип, ялгызы күз яшьләрен түкте. Ләкин үзеннән һичбер адым атламады, сердәш җиңгәсе Мәфтухага күңелен ачмады. Бу тик, йөрәкнең тамырларын акрынлап кимерә торган бер авыр хәсрәт зәһәре кебек, кан белән тамырлар буенча гына әрнетеп йөрде.

Кыз шул хәсрәтләр өчендә көйгәндә, ата белән ана, бер-беренә әйтми, ике яктан эшкә тотындылар. Фәтхия үзенең балаларының кендек әбисе Камәрия карчыкны чакырып чәй эчертте, Үзән елганың болыннары буйлап, тегермән бөясе аркылы чыккач, кай урамнарга борылырга икәнен өйрәтте дә Хәерниса кодачага җибәртте:

— Бу нихәл? Үзе дә юк! Хәбәре дә юк! Ил алдында хур булдык лабаса! — дип әйтергә кушты.

Нурый карт, күп ел гомер итеп, мондый мәсхәрәне күрмәгән иде. Шибайга

кеше аша әйттерде:

— Безнең алай кирәксез балабыз юк. Әгәр киреләсәләр, туры әйтсеннәр, бердәнбер кызыма минем өемдә урын җитәрлек! — дидертте.

Бу хәбәрләр бару белән Шибайның йортында сүз, гайбәт, ызгыш башланды. Ләкин Закир, атасының: «Кара халык — кара сарык ул! Безнең мужикның юкбар сүзенә колак салсаң, башың югалыр. Өч йөз тәңкә мәһәрне уен дип беләсеңме? Атаңның чәче юкка агармаган!..» — дигән сүзләреннән соң яңадан тарантасны чыгарып майлады, солыдагы яшь айгырны кыргычлады, үзе крестьян кияүләрчә бары белән киенде, ике кесәгә бүләкләр салды да тагы Караюргага, кәләшкә китте.

Бу аның соңгы кияүләве иде. Атна-ун көннән киленнәр төшерү башланачак. Аңарчы кияүнең анасы, янына бер кеше утыртып, кодалар йортына килен сорарга барып кайтачак. Аннан соң Закир, көймәгә өч ат җигеп, кучер утыртып, яшь бикәч Гөлбануны Караюргадан Бикьярга алып килергә барачак. Шулай итеп, кыз атасыннан каената йортына бөтенләй күчәчәк.

Ләкин монда инде Сабира, үзенең актык көчен җыеп, сугышка әзерләнде. Килен сорарга бару дигән сүз чыгу белән ире, балалары алдында котырып китте:

— Юкны сөйләп торма. Булмас! Булмас дигәч, булмас, атакайгынам. Шул Саесканнарга килен сорарга дип аягымны атлар хәлем юк!

Ул менә шулай кискен башлады. Шибай карт авырып ята иде, шулай да кызмады, бераз көлде:

— Ярый. Алайса, менә кызым Хәерниса барыр. Аны Караюргада яраталар. Кодагыйларга да тыныч булыр, — диде. — Шулай бит, кызым. Барасың бит? — дип, Хәернисадан сорады.

Ләкин бу аптырады:

— Белмим, әткәй. Ничек инде ул, илдә юкны, әнкәйдән узып мин барыйм? Кеше көләр ич! — диде.

Карт туктамады:

— Ни эшлисең бит, көлсә көләр инде. Анаң бармагач, бүтән кемне җибәрәсең? Алайса, менә Бикьяр белән Караюрга арасында болын буйлап һаман йөри торган карчык бар, шуны җибәрик, сыйланып кайтыр. Ярыймы?

Шулай иттереп, бүген ул Сабираны кыйнамыйча ук җиңде.

Закир, эшнең кая таба барганын чамалагач, ат җигәргә тотынды. Алтынбай, Шибайның кушуы буенча, унике яшьлек улы Миңлегалимне тиз-тиз юындыртты, киендертте. Хәерниса килен сорарга китәчәк анасының тарантасына барлык кирәк-яракларын куйды, палас салындырды, киез түшәде,

ике мендәрне, кабартып, артка терәде, кучер астына күчтәнәчләрне тыкты. Ул арада инде кунакка бару шатлыгыннан авызы колагынача ерылган Миңлегалим, чыбыркысың тотып, зур күк ат җигелгән тарантасның кучерына менеп үк утырды. Мондый бәхет аңа сирәк эләгә иде. Инде карт әнкәй тагы яңадан кирели генә күрмәсә ярар иде дип, йөрәге леп-леп итеп торды. Шатлык белән ялтыраган күзләрен ишектән ала алмады.

Сабираны җиңгән нәрсә — ире Шибайның тискәрелеге булды. Караюрга Саесканнарына килен сорарга баруны күңеле бер дә теләмәде, үзе бармагач, берәү дә бармас, шулай итеп, бу хәерсез кодалыклар үзеннән-үзе юкка чыгар дип уйлады. Ләкин Шибай моңа бирелерлек күренмәде, Сабира бармаса, кызы Хәернисаны озатачак. Әгәр ул йомшакланып: «Илдә юкны, әнкәйдән узып мин ничек барыйм», — дип торса, зур улы Алтынбайның хатыны Фәүзияне җибәрәчәк. Бу оятсыз: илдә юк дип тормас, каенатам кушкач нигә бармаска, дияр дә килен сорарга чыгып китәр. Бусы инде Сабираны бөтенләй кимсетү, кеше алдында мыскыл итеп көлү булачак.

Менә шул төрле катлаулы әрнүләр эчендә Сабира, тешен кысып, зәһәрләнде, өйдәгеләрнең һәммәсен — ирен дә, улларын, киленнәрен дә, кызы Хәернисаны да үзенә дошман итеп тойды. Ничек, кайчан, кайда боларның һәммәсен бер әрнетергә исәпләп, юынды, киенде дә җигүле атка чыгып утырды.

Шулай Сабира Караюргага килен сорарга китте.

Җәй, үзенең бөтен байлыгы белән тулышып, матурланып өлгерде. Арышлар баш кысып, серкәгә утырды. Хәзер инде карасу яшел яланнар өстендә бик аз гына, бик сыек кына төс белән сары алтын дулкыны башланды, солылар, бодайлар буйга үсеп, куе яшел дәрьядай җәелеп яталар. Карабодай, үзенең тәмле исле гаҗәп матур ак чәчәген коеп, акрын-акрын карасу кызыл төскә керде. Тауларның, болыннарның, сөрелмәгән чирәмнәрнең үләннәре, чәчкән ашлык кебек куерып, озын булып, тиздән югары күтәрелделәр. Җир җиләге кызарып пеште, бөрлегән, каен җиләге менә бүген-иртәгә өзәргә тулышып киләләр. Кояш астында кызарып, янып утырган тәмле чияләр хәзер өрелеп, каралып баралар. Үзенең киң яфраклары эчендә нечкә, нәзек, тәмле кура җиләге, аксыл сарыдан кызарырга чамалап, кояш нуры астында кызынып утыра.

Менә шул килен төшерү, кыз озату мәшәкатьләрен генә кичергәч тә, болыннарда саф-саф тезелгән чалгылар яңгырый башлар; берничә көн үтүгә, ак җиңсәләр кигән җитү кызлар, яшь киленнәр җырлап-җырлап, ак тырмалар белән печән җыярлар. Аннан соң арыш урагы, ул бетәр-бетмәс каты ашлык ураклары ялганыр. Менә алда шулай эш тора.

Шибай моны күз алдында кебек күрде. Сабираны Караюргага килен сорарга озаткач, хәленең бик шәп булмавына карамастан, ат иярләтте дә ашлык карарга, печәнгә кайчан төшү турында күз салырга дип яланнарга чыгып китте.

XX

Бикьярлар һәммәсе киенеп-ясанып урамнарга агылдылар. Салам түбәле өйләр, кәкре-бөкре тыкрыклар, коймалар, текмәләр, читәннәр — һәммәсе бертуктаусыз, әле анда, әле монда йөгереп кайнашкан аллы-гөлле күлмәкләр, зәңгәрле-яшелле, кызыллы-сарылы шәлләр дулкыны эчендә калдылар. Кара бишмәтләр, җиңсез камзуллар, кайсы оеклы-чабаталы, кайсы итекле, кырма бүрекле көяз егетләр шул купшы шәлләр, яулыклар арасына сибелделәр.

Бүген җиде кыз китә, тугыз килен килә.

Менә шул уналты йортның һәрберсендә кеше кайный, һәрберенә малайлар җыелалар, егетләр, кызлар өер-өер килеп, берсен озатып, икенчесен каршы алып, өченчегә, дүртенчегә бер-бер артлы барып өлгерергә, тормышның бу бәйрәмле, сирәк шатлыклы көнен бөтен тулылыгы белән алырга омтылалар. Бу шатлыклы бәйрәм көненең уйнак дулкыннарыннан читтә калырга берәүнең дә күңеле риза булмый. Берәү дә начар күренәсе, ямьсез чыгасы килми. Кызлар алдагы атнада ук моның кайгысына керештеләр. Кулыннан килгәне яңа күлмәк тектерде, яңа шәл алдырды, моңа хәле җитмәгәннәр шундый көннәр өчен генә күз агы кебек итеп саклап килгән кадерле күлмәкләрен чыгардылар; кирәк җирен төзәттеләр, аякка ак бәйләм оек, өстеннән күн ката табарга тырыштылар, ул булмаса, чабатаның кечкенәсен, яңасын, матурын сайладылар; белгән белгәненчә, һәркем тапканынча, биткә ап-ак итеп кершән якты, бит алмасына, нәкъ уртага кып-кызыл ясап, иннек сөртте, бик саклап токкан сөрмәсен тартты; чулпылар, алкалар, беләзек һәм йөзекләр белән бизәнде. Шулай киенү-ясану дәрте, күлмәк, шәл кайгылары дулкынланып ташты. Гайбәтләр чигеннән артты, башкаларның яулыгыннан, акшар кебек агарган, кызыл алма кебек уртасы кызарган битләреннән көлүләр, көяз, кыланчык, чытлык, куштан дип мәсхәрәләп көлүләр үзара сүздә чаткыланып очтылар; шулай көлә-торып та, әгәр үзләре булдыра алса, тагы да ныграк. көязләнергә, тагы да катырак куштан, кыланчык булырга, тагы остарак чытлыкланырга омтылулар кара-каршы бәрелештеләр. Шул кара-каршы бәрелешләр, ярышлар эчендә, һәрбер кыз үзенең сөйгәне алдында, барлык егетләр каршында да һичкемнән ким булып күренмәскә, күңелләрне ауларга, йөрәкләргә мәхәббәт орлыклары чәчеп үтәргә теләде, очраса — бер карашуны, уңай чыкса — бер күз кысып, каш сикертеп үтүне өмет итте.

Кызган йөрәкле кызлар дулкыны үзенең сихерле көче белән яшь җилкенчәк

егетләрне, яшерен җепләр белән багланган кебек, үз артларыннан үз күләгәләре кебек ияртеп йөртте.

Булганы итеген, булмаганы яңа чабатасын киде. Кырма бүрек әзерли алмаса, матур kәләпүш тырыштырды, саклап кигән бишмәтен, булмаса, камзулын кагып, төзәтеп чибәрләтте, сөйгән кызы биргән кызыл яки яшел яулыкны чиккән ягы белән кесәдән тышка салындырды, шул үзенчә, барынча, хәлле хәленчә ясанып, һәр егет урамның кайнаган дулкынына ташланды. Теләгән кызын күрермен дип, бәлки бер сүз әйтермен дип, бәлки, уңай чыкса, яшерен очрата алса, кызарган бит алмасыннан, янган иреннәреннән үбәрмен, бәлки вәгъдәләшермен дип дәртләнде. Шул дәрт ялкыны аның гәүдәсен җиңеләйтте, аягына тизлек, күзенә-йөзенә яшьлекнең нурын балкытты.

Бүген Бикьяр урамы менә шулар белән кайнашты.

Төш авып барган вакытта Шибай картның йортын, урамын, азбар буйларын каплап алган менә шул егетләр, кызлар, ирләр, хатыннар, дулкыны өстеннән:

— Килен килә, килен...

— Килен килә, килен... — дип сузып, айһайлап акырган күмәк тавыш күтәрелде.

Өйдә аш-су эчендә кайнаган кунак Хәерниса моңардан аптырап калды. «Әле ит тә пешеп өлгермәгән, бәлешләр яңа мичкә кергән, бу ничек бик иртә киләләр?» — диде.

Өй буйларын, бакча, читән, келәт тирәләрен сырып алган хатын-кыз дөньясы бер яктан икенче якка ташланды, йорт кызыллы, яшелле, аллы, зәңгәрле күлмәкләр дулкыны белән уйнап алды, ирләр, егетләр капкага, урамга таба атларны каршы алырга атылдылар. Шибайның йорты турында бөтен киң урам халык туфаны белән капланды, һәммә кеше түбәнгә, Үзән елга күперенә, болынга таба күз ташлады. Ләкин малайлар алдаганнар икән, аннан колынлы бия җиккән бер кырлайчы[1], арган атын кыйнап, чак атлатып килеп ята. Башка берәү дә юк.

Зурларны болай ялган белән кузгата алганлыклары өчен малай-шалай тагы бер кат шатланышып, кычкырышып шаулаштылар. Килен каршы алучылар тагы йортка, койма буена төркем-төркем булып сибелделәр.

Бикьярдагы кебек Караюргада да шулай ук бетен яшьләр кыз озату, килен төшерү көненең шатлыгы эчендә урамнарда дулкынланып кайнашалар иде. Монда малайлар, ялганлап кычкырып, халыкны урамга чыгарган вакытта, анда, Нурый карт өендә, Гөлбануны озатырга җыелган исәпсез-хисапсыз егетләр, кызлар, бала-чагалар кузгалышы эчендә ашыгыч-ашыгыч ат җигүләр

[1] *Кырлайчы* – вак-төяк белән сәүдә итүче

башланды.
Закир, егет-җилән шаярмасын дип, зур көймәне (повозка) үзе карап майлатты, өч атны үзе карап, катнашып, үз күзе алдында җиктерде. Аның белән бергә һәрбер арчи үз арбасы, үз аты тирәсендә кайнады. Сөйләшү буенча, бер сандык арбасы, өч арчи барачак иде.
Нурый карт белән Фәтхия өчен бу арчилар эше бик зур борчулар тудырды, әллә ничаклы үпкәләргә сәбәп булды.
Арада бер дә сүзсез барырга тиеш дип табылган кеше — Чокыр Хәбип булды. Ул кыш көне, туй алдыннан, Бикъярга өндәүче булып барганда ук әйтте:
— Нурмөхәммәт абзый, — диде, — мин бала-чага түгел, ике сөйләтмәссең, арчига[1] мине җибәрерсең, — диде. — Шулай булмаса, өндәүгә бармыйм, — диде.
Чокыр Хәбип — Нурыйның бердәнбер энесе. Ата бер, ана бер. Өс-баш начар түгел, кеше алдында йөз кызартмас. Ат-арбасы да ярарлык. Байлыгы, кеше арасында хөрмәте дә бар. Фәтхия әби дә Чокырны арчиларның башы, беренчесе дип исәпләп куйды. Ул, тарантаска ике ат җигеп, хатыны белән бара.
Икенче арчи инде, теләсәң-теләмәсәң дә, усал килен Мәрфуга белән ире Төхфәт булырга әзерләнеп куелган. Аның тик бер сүзе булды:
— Мәрфуга килен, — диде, — кыш көне туйга килгәндә дә Сабира кодагый белән талашып дөнья боздың, телеңне тыеп тот! Әгәр тагы кышкы кебек талашып кайтсаң, миңа үпкәләмә, моннан соң мин сине кунакларым эченә кертәсе булмам! — диде.
Мәрфуга, теле Сабирага каршы бик кычытса да, каенанасына вәгъдә бирде.
— Ярар, әнкәй, ярар. Тешемне кысарга тырышырмын, — дип көлде.
Фәтхия тагы:
— Сиңа әйтергә җиңел: өч көн кунак буласың да кайтып китәсең, Гөлбану каен сеңелеңне онытма! Ул бит шунда гомер итәсе; әле болай да явыз аждаһа кулында кызым ничек көн күрер дип җаным әрни, — дип өстәде, күз яшен җиңе белән сөртте.
Өченче арчи көтелмәгәнрәк кеше булып чыкты.
Бикъярлар — бик көяз халык. Алар турында тирә-якта: «Эчтән калтырар, тыштан ялтырар», — дип көлеп сөйлиләр. Өйләрендә үзләре алабута ашап, чабата киенсә дә, кунакта, мәҗлестә бик кыланчык булалар. Араларында күбе кырлайчылык, кырык тартмачылык, йомыркачылык, көмешчелек, йон тетүчелек, пимачылык, тегүчелек кебек төрле вак һөнәрләр белән дөнья гизгәнгә, телгә бик шомалар, мәсхәрәчеләр. Юк-бардан көләргә, шаяртырга,

[1] *Арчи – кияүгә чыккан кызны кияү ягына озатып баручы*

мыскыл итәргә бик яраталар. Арчилардан Чокыр Хәбип тә, Төхфәт тә болар белән бу яклардан бер дә ярыша алырлык түгелләр. Ара-тирә уен, сүз көрәштерү чыкса, болар кызарып, авыз йомып утырырлар. Менә монда инде ерак Казаннан килеп шомарган бикьярларга каршы арчилар арасында, һич булмаса, бер үзләрендәй үткен телле адәм кирәк. Авылда Хәйрулла кибетче бар. Кыштан ук уенга салып әйтә килде:

— Нурый абзый, мине җибәр, арт сабакларын бер укытып кайтыйм шул тел бистәләренең, — диде.

Картның исәбе башкача иде. Ләкин карчыгы белән сөйләшкәч, бу уен сүз чынга әйләнде, шул гайбәтчел, көяз, мактанчык Казан бикьярлары алдында йөз аклыгы өчен, Гөлбану өстенә бу яктан күләгә төшмәсен өчен, башкаларның үпкәсенә карамастан, шул кибетче Хәйруллага тукталдылар.

Закир кияүнең зур кимәсенә өч ат җигеп, Гөлбануны иптәш кызлары белән бергәләшеп шул кимәгә утыртып, кызлык гомере үткән яланнардан, таулардан, урманнардан йөртеп, исәнләштереп кайтарганда, бу өч арчи бөтенләй әзерләнеп беткәннәр иде инде.

Кыз үзен тыя алмады, басу карап йөргәндә дә, аннан кайткач, җиңгәләренең, иптәш кызларының бизәп-ясап киендергән чакларында да һаман елады. Ире, култыклап, йорт тулы шаулаган халык эченнән ярып көймәгә (повозкага) утыртканда да күзеннән яшь туктамады. Ире Гөлбануны кочаклап утырды, көймәнең күнен төшерде.

Биленә киң бүләк сөлге бәйләгән кучер:

— Һай!.. Һай!.. — итеп, төпке атны тартты, ике мичәүнең дилбегәләрен какты, зур көймә (повозка), аның артыннан арчилар, иң соңыннан сандык арбасы шау-шу, кычкырыш эчендә кызның туган йортыннан чаптырып киттеләр. Гөлбану каушап, калтыранып барды.

Үзән елга аша туры юл белән тегермән бөясе аркылы чыкканда Караюрга — Бикьяр арасы бер генә чакрым саналса да, калага үтә торган олы юл белән урап барганда җиде чакрымга җитә. Башта арыш басуын ярып үттеләр. Бер коры елганы аша кичтеләр. Аннан каты ашлык яланының бер читен эләктереп алып, Бикьяр каршына болынга килеп төштеләр. Башкалар арттарак аерым калдылар. Закир, гадәт буенча, көймәне, күпергә җитмәс борынрак, Үзән елганың уңайлы бер ярына туктатты. Киткәндә, юл буенда елап, күзе, йөзе бозылган яшь хатынын елгага, су читенә юынырга, яңадан төзәтенергә алып килде. Хатын ничектер йомшарган, изелгән иде, шулай да тиз-тиз юына белде, кечкенә көзгегә карап кершән ягына алды, иннекне дә оста сөртте, сөрмә тартырга да онытмады. Бөтенләй яңа, шат Гөлбану булып китте. Закир яратып елмайды:

— Инде еламаска тырыш, битең бозыла, — диде. Яңадан көймәгә утырдылар, арттан арчилар басып килеп җиттеләр; биленә киң бүләк сөлге бәйләгән кучер егет тагы:

— Һай!. Һай, малкайлар! — дип, атларны кузгатты.

Болар чаптырып килеп Үзән елганың күперенә менгән чакта, тегендә, Шибайның йортында, килен каршыларга җыелган халык өч ат җиккән көймәне (повозканы) күрделәр, малайлар тагы:

— Килен килә, килен...

— Килен килә, килен... — дип тапташып, шаярышып, тавыш күтәрделәр.

Бу шаулауга йортның эче тагы кузгалды, кызлар, киленнәр гөжжж... килеп, чыр... чыр... чыр... кычкырышып, әле анда, әле монда йөгерештеләр, уңайрак, киленне күрерлегрәк урынга барырга тырыштылар; ирләрнең, егетләрнең саграк булганнары, сөзмәгә эләкмәскә дип, бер читкәрәк таю ягын карады. Усалраклары сөзмә каян чыгар, иң элек эләктереп аласы иде дип, өй ишегенә табарак якынлаштылар. Иң зур төркем чыдамады, ерактан ук күреп, каршылау өчен урамга атылды. Шибайның йорты турында урамны каралы, кызыллы, гөлле, аллы куе болыт каплады. Күрше егетләрнең берсе чабып килгән өч атлы көймәнең кучерына, анда сөлге бәйләгән егеткә булышмак өчен, сикереп менде, төпке атның дилбегәсе белән чыбыркыны тартып алды да, урам яңгыратып, шаулы халык өстеннән кычкырып җибәрде. Кайнаган дулкын кинәт икегә ярылды; менә шул ачыктан, иң алдан яшь киленле көймә, аның артыннан ирле-хатынлы кунак арчилар, аннан соң сандык арбасы, чаптырып, Шибайның салам түбәле каралтылар белән әйләндерелгән киң, зур йортына керделәр, азбар буеннан әйләнеп, яңадан өйләрнең баскычы, ишеге янына килеп туктадылар.

Атлар тукталыр-тукталмас, Закир кимәдән сикереп төште, җитезлек белән яшь хатынын култыклады да икегә ярылып юл ачкан халык уртасыннан өйгә алып китте.

Шулай Гөлбану ата йортыннан каената туфрагына аяк басты.

Яшь килен уң аягын көймәдән алып җиргә баскан минутта, эчке ишектән бер хатын чыкты да алъяпкыч астына ишерелгән сөзмәне шундагы ике егеткә бирде. Болар иң әүвәл, шаркылдап көлешеп, бер-беренең битләрен, чәчләрен куе катык кебек ак сөзмә белән буяшырга азапландылар; шул арада башка егетләр, сөзмә чыкканны сизеп, һәркем булдыра алганынча эләктереп качарга тырышты; бу ала алганнар, башкаларны куып тотып, йөзләрен, бүрекләрен, кара бишмәтләрен ак сөзмәгә буяп бетерделәр. Шунда кайнаган кызлар, киленнәр өстенә таба кулындагы сөзмәсе белән бер егет ташланган иде, чыррр... чырр... килеп, күлмәк, шәл пычранудан куркып, көлешеп, айхылдап

качып беттеләр. Сөзмәнең үзәге, малайлар белән егетләр арасына кереп китеп, анда гадәттән тыш зур бер кузгалыш, тартыш башланды. Һәрбер үткенрәк егет ничек тә сөзмәне эләктерергә омтылды, эләктерү белән, һич булмаса, берәүне тотып, бөтен җирен агартып, пычратып качты; башкалар моның үзен куып киттеләр, тота алсалар, берничәсе кушылып, үз сөзмәсенә үзен эштән чыгарып буядылар. Шулай бер-берен куышып, бәрешеп, Шибай тирәсеннән икенче йортка — башка киленнәрне каршыларга чаптылар.

Монда Закир, көймәдән култыклап алу белән, туры, электән хәзерләнгән хатыннар ягына — йортка таба салынган дүрт почмаклы өйгә алып керде. Анда киленнәр, кызлар, кардәш хатыннар тулы иде. Кайсы исәнләште, кайсы күреште. Сабира каенана, килеп, яшь киленнең аркасыннан сөеп китте. Хәерниса һәммәдән бигрәк шул тирәдә кайнады, яңа төшкән киленне берәр сүз белән, берәр эш белән уңайсыз хәлгә куя күрмәсеннәр дип, аның тирәсеннән китмәде. Минуты белән арбадан сандыкны кертттеләр. Шунда ук яңа көзгене ике тәрәзә арасына китереп астылар. Калайлы зур сандык сәке буена урынлашты. Аннан сөлгеләрне, чыбылдык, чаршауларны, намазлыкларны берәм-берәм чыгарып элделәр, пәрдәләрне тәрәзәләргә корып җибәрделәр. Шулай итеп, үзе белән бергә киленнең бирнәсе дә каената өенә урынлашты.

Шул әйберләр белән бергә Гөлбану үзенең чигүле алсу алъяпкычын чыгарды да җиңел, уңган кул белән тиз-тиз бәйләде, каршыларга килгән каен сеңелләр ярдәме белән чиләк, көянтә алды, кушъяулык (бөркәнчек) ябынды да, алты кыз белән бергә, якындагы чишмәгә суга китте.

Бу кызлар яңа төшкән киленгә су юлы күрсәтеп алып кайттылар.

Каената йортында яшь киленнең беренче эше — менә шул булды.

Судан кайткач, өлкән җиңгәсе Фәүзия белән бергә чыгып, сыер савышты. Аннан кергәч, аш өендә, беләк сызганып, камыр басты. Бик нечкәләп токмач кисте, чиләк сыярлык зур самавырга су салып, ут кабызды; шулай бер-бер артлы өй хезмәтләре ялганып киттеләр.

Гөлбануда үз язмышын күргән Хәерниса яшь киленне беренче адымнарында күздән җибәрмәскә, аягы тайса, тиз ярдәм итәргә тырышты. Көянтә-чиләкне ничек күтәреп кайтуын, ничек җилкәсеннән алып куюын карады; җиңел, уңган дип тапты. Сыерга чыккач, ничек бозау имтекләвен тәрәзә аркылы җентекләде, камыр басканда, токмач кискәндә яшь киленнең бераз каушап калтыраган куллары ничек йөрүен күзәтте. Арада бер сынар өчен:

— Киленкәем, ашның тозын карый күр, бик кырку була күрмәсен, — диде.

Гөлбану, дерелдәп, кашык алды, кая басканын югалта язды, авызымның тәме бетмәгән булса гына ярар иде дип, куркына-куркына шулпаны капты, бер сүз

белән өзеп:

— Таман, — диде.

Хәерниса шулар белән тынычланды, үз эченнән:

— Берәүдә гаеп итә алмас, өй эшләрен, аш-су тирәсен бик әйбәт белә икән, — дип кистереп куйды.

Шуның белән бергә, каршы алучылар аркылы Шибай килене Гөлбануның төсе-бите, буе-сыны, йөреше-кыланышы, киенеше-ясанышы турында Бикьярның һәммә урамнары буйлап яхшы, яман сүз таралып киткән иде инде. Хәерниса үзенең энесе яшь ир Закирның муенсызрак икәнен белә иде. Иң элек аны эзләп очратты:

— Бәхетең, туганкаем, — диде, — хатының харап уңган, кулы кулга йокмый, — диде. Көянтә-чиләкне ничек тотуын, бозау имтекләвен, камыр басып, токмач кисүләрен берәм-берәм нечкәләп сөйләде; аның артыннан ук арчига килгән усал килен Мәрфуганы күрде, аның да телен йомшартырга теләп, яхшы сүз әйтте:

— Әйбәт, килен бик әйбәт икән, нинди генә эшкә тотынса да, кулы кулга йокмый, шулай уңган, — диде.

Мәрфуга бик шатланды, Чокыр Хәбип белән теге кибетче Хәйрулланың гайбәтче хатынына бу сүзне ирештерергә, иренең дә колагына салырга теләде, ләкин өлгерә алмады: бу вакыт Шибайда ирләр, хатыннар мәҗлесенә килгән ир кунаклар, хатын кунаклар ике өйгә шаулашып кереп утыра башлаганнар иде. Мәрфуга да шулар белән бергә атлады, арчи кунак сыйфаты белән хатыннар мәҗлесенең түренә, Чокыр Хәбиб белән кибетче Хәйрулла хатыны арасына кереп сыенды. Аларга пыши-пыши итеп Хәернисаның яшь килен Гөлбану турындагы мактаулы сүзен сөйләп алды.

Бу вакыт Гөлбану кунаклар өчен казан, мич тирәсендә аш-су хәзерләшеп йөри иде. Бу мәҗлестә дә, аннан соңгы өч көн буена бер-бер артлы барган аш-суг кунак җыелышларында да Гөлбану һәммә эшкә катнашты, аның турында сүзләр өзелмәде.

## XXI

Болар артыннан ялан эше һәр яктан китереп кысты.

Ул көн Шибай карт ат менеп карап кайткан иде, утауның вакыты чыгып бара, шулай да тарыны утамый булмас, Үзән елгага караган башын чүп басып бара, диде. Печәннәрне бик өлгергән тапты, урыны-урыны белән болында үләннәр ат корсагы астына җитәләр, безнең Исәнбикә җиренә сыя алмый гөрләп утыра, хәзердән чалгы сорый, диде.

Башка авылда булган кебек, Бикьярда да җирне җәмәгать белән билиләр, иген

чәчә торган туфрак унике елга бер бүленә. Җан исәбенә яки ир исәбенә карап түгел, һәр хуҗалыкның кулында унынчы рәвездән килгән[9*] ничә имана (монда «душ» диләр) булса, менә ул шуңа карап җир тия. Моны бөтенләйгә сата алмый, бүләк итә алмый, тик берничә елга чәчәргә генә бирсә бирә ала. Авылның фәкыйрьләре шулай эшлиләр дә: үзләренең чәчәргә хәлләре җитмәгәнлектән, бик мохтаҗ чакларында, рәвез буенча тигән җирләрен бай крестьяннарга бик юк хакына берничә ел иген игәргә генә сатып бирәләр. Урман, печәнлек болыннар да шулай. Ләкин боларның бүленүләре ешрак була. Урманны ике-өч елга бер, болыннарны һәр ел бүлешәләр. Һәркем шобагасына чыккан өлеше белән файдалана. Фәкыйрьләргә монда да кыштан, күп вакыт берничә елларга, урман, печән өлешләрен алдан, бик аптыраган көннәрендә, арзан бәягә сатарга туры килгәли. Шуның аркасында бай крестьяннар, гәрчә үзләренең теге унынчы рәвездән килгән иманалары бик аз булса да, ярлылардан җыйганнарын бергә кушып, азында бөтен бер шобага (сигез имананы бер шобага диләр) белән, кайбер вакыт унар, унбишәр өлеш белән урманнан, җирдән файдаланалар.

Шибай бик искедән моңа гадәтләнде. Ачлык ел булса, бәла-каза килсә, янгыннан ялангач калса, башкача мохтаҗлыкка төшсә, ярлы мужик бик аптырап, бала-чагасын ачтан үтермәс өчен яки өендәге актык казанын ясак түләргә яздыртмас өчен картка килә. Өч чәчәргә, биш-ун чәчәргә җирен бирә, урман, печән өлешләрен юк хакы белән бирә, старостадан, волостьтан тамгасы салынган кәгазен китерә дә аз-маз акча, күп вакыт он, ярма алып китә.

Картның быел шулай җыйган печән өлеше, үзенекеләрне дә кушкач, бары унике иде. Биле чәнчүгә җиңелмәде, атын тирләтеп, урмандагы, таудагы, болындагы иң ерак печәнлекләрне дә карады, әгәр бүлгәндә бик начар җире чыкмаса, быел шобага ярымнан кырык-илле арба печән булыр. Исәнбикә дә шул чаманы бирсә, кыш асрап, язга таба, хак күтәрелгәч, калага илтеп, бер егерме чана сатарга да чама килер дип исәп йөртте. Үлән һәркайда яшелләнеп, тулышып утыра, һәркайда болыннар чалгы көтәләр. Ләкин алда берничә көнлек кыз озату, килен төшерү мәшәкатьләре бар. Яшьләр шунда кайнашыр, карт-коры кунаклашу, арчи алу, үзара сыйлашу белән чуалыр. Менә шул үтүгә печәннәрне бүлешерләр. Аңарчы инде, вакыт җиткән булса да, ил болыннарына чыгарга туры килми. Картның, бу җәмәгать уртагыннан башка, тик үзенә караган бер печәнлеге бар. «Исәнбикә» дип йөртәләр. Авылдан җиде чакрымда, Үзән елганың түбән агымында, тау буенда, бик яхшы аерым кечкенә болынлык. Үзе кантун булып торган чагында, күрше авыл башкортлары, банк аркылы немец утарларына җир сатышу эшендә урыс түрә белән ике арада тылмач

булып, булышлык кылып йөргән өчен, җир кискәндә бер читтә бүленеп калган бу култыкны бүләк иткәннәр иде. Шибайның усаллыгы җитте: берничә куштанны сыйлады да Исәнбикәне үз артына мәңгелеккә итеп беркетте дә җибәрде. Башкортлар хәзер бик нык даулашып карыйлар, гомерлек түгел, аңа тик беразга, чабып, печәннән генә файдаланырга бирелде, диләр. Шаһитләр дә бар. Ләкин һәммә рәсми урыннарда башкортларның үз илчеләре ризалыгы белән Шибайга ныгытылганга, яңадан кире кайтара алмадылар.

Карт ул көнне атын чаптырып Исәнбикәгә дә килде, сокланып, күзен ала алмады — быел шулай үлән шәп үскән!

Карап кайтты да зур улы Алтынбай белән уртанчы улы Фәсхине чабарга җибәрде:

— Безнең Бикьяр көязләре кунак сыйлаудан тиз бушамас, Исәнбикәнең үләне хәйран булып, чалгы сорап тора, килен төшү мәшәкатен үткәрүгә, барып жыярбыз да кибән салырбыз, — диде. Алтынбайның хатыны зур килен Фәүзия белән аның унике яшьлек улы Миңлегалимгә дә тынычлык бирмәде. Малай, үзенең әбисе Сабира белән Караюргага килен сорарга барып кайткач, инде киленнәр төшерү кызыклары башлана дип торганда, Шибай аны да эшкә җикте: аталары чапкан печәнне ике көн кипкәч үк, анасы белән җыеп, чүмәлә сала барырга озатты.

Болар күңел багламадылар, утыз чүмәлә салдылар да, печән бик калын, әле кибеп җитмәгән дип, ташлап кайттылар. Фәсхи белән Алтынбай, таң иртәдән караңгы кичкәчә чабып, ике тәүлектә Исәнбикәне бетерделәр. Закир үзенең яшь кәләшен алырга киткән көннәрдә, болар менә шуның өстендә булдылар. Шулай башланыр-башланмасрак барган эш арасына шаулап килен төшерү, кыз озату көннәре килеп керделәр дә бетен өч тәүлекне алдылар. Бу арада эштән, сабаннан, печәннән бушанган крестьяннар, гөрләтеп, кунак мәҗлесләре эчендә кайнадылар, бөтен яз, җәй, көз буйлары каты авыр хезмәтләр белән сызланган кул-аякларга ял бирделәр. Гөлбану бу өч көн эчендә үзенең яңа тормышына өйрәнү, үзен күрсәтү, үзе турында, үзенең эш белүе турында, үзен ярату-яратмаулары хакында әллә ничаклы борчылды, аруның, кыенлыкның нәрсә икәнен онытты, аягүрә, ничек туры килсә шулай, аннан-моннан капкалап, тәүлеккә ике сәгать йоклап, һәммәсенең күңелен табарга тырышты; шул кайнаш эчендә өч тәүлек үтеп тә китте, дүртенче көнгә чыгып, төш аугач, арчилар, атларын җигеп, ялгыз калган Гөлбануга тигез мәхәббәт белән бәхетле гомер теләп, Караюргага кайтып киттеләр.

Тарантаска яшь айгырны җигеп, Закир белән Гөлбану арчиларны Үзән елганы чыкканчы озата бардылар. Болар кайтып йортка кергәндә инде монда иртәнге

эшкә кызу хәзерлек башланган иде.

Өлкән килен Фәүзия келәт башыннан печән тырмаларын төшерде, зурлы, кечкенәле сәнәкләрне ыргытты, чүмәлә тарттыра торган арканнарны сузып ташлады; кыекның буена, өрлеккә уңайлап куелган зур, озын кибән сәнәген ипләп алып бирде. Закир белән уртанчы ул Фәсхи, озын арба тирәсенә камытларны, йөгән, нукта, дилбегә, арканнарны таратып, юнәйтергә керештеләр Өлкән ул Алтынбай аш өенең сәке астыннан пычкылар, ышкы, өтерге, балта, чүкеч, бораулар чыгарды, утынлыктан төз агачлар сайлап алды да тырмаларны төзәтергә тотынды, өлкән килен Фәүзия үзенең иренә шаярыбрак әйтте:

— Син, — диде, — яшь киленгә тырма ясарга онытма. Яңа кул бит. Тапсаң, буяп та җибәр. Күңеле булсын, — диде.

Алтынбай күтәрелеп карамады.

— Анда, тәрәзә башында, былтырдан калган буяу бардыр, кибеп бетмәгән булса, шуны бер савытка из дә миңа китер, — диде, үзе нечкә, кипкән имәннәрдән очлап, шомартып ясалган каты тешләрне тырманың сырт агачына балта белән сак кына кага бирде.

Гөлбану, юк йомышны бар итеп, ире Закир янына килде, аның ишеп утырган аркан очында күз уйнатып:

— Нәрсә? Иртәгә ялан эшенә барабызмы? — дип сорады.

Закир хатынына яратып күзен терәде:

— Шулай, шулай. Беләкләрең генә түзсен, печән җыеп, кибән салырга барырбыз, син кибән башына менәрсең, — диде.

Хатынның күңеленә шатлык тулды, монда, йорт эчендә, кырык яктан гаеп эзләп торган кырык күз астында ул үзен төрле яктан утлы тимер белән чәнчергә әзерләнгән кешеләр арасында кебек сизенә. Яланда алай булмас, анда бергә-бергә эшләү рәхәт булыр дип уйлады. Тагын нидер әйтмәкче иде, — бигрәк чытлыкланган була инде, иренең яныннан китә алмый, дигән гайбәттән курыкты.

Зур җилпучы белән йөгереп келәткә барды, өсәктән тутырып арыш оны алды да аш өенә керде. Анда сәке өстенә киң куна тактаны иплән куйды, он вагын туздыра-туздыра иләде; өлкән юкә агач савытка икмәк изде, чамалап тозын салды да өстен чүпрәк белән каплап куйды; тагы чыгып, өсәктән тулы бер җилпуч белән он китерде, анысын да иләде дә иртәгә икмәк басарга әзерләп куйды.

Ул шулай рәхәтләнеп эшләп йөргәндә тыштан сарык-кәҗә тавышы килде; маланларның чыбыркы шартлатып сыер куулары ишетелде, азбардан бозаулар

акыра башладылар. Яшь килен өстендәге оннарын какты, чөйдә элүле торган сөт чиләген тиз генә алды да көтүгә каршы атылды. Ләкин өлгерә алмады: азбарның капка арасыннан берсе ак, берсе кызыл ике бозау ничектер тыгызланып сыйдылар да урам капкадан акырып килеп кергән сөт тулы җиленле аналарына таба уйнап-сикереп чаптылар, барып та җиттеләр, имчәкләрне өзәрдәй тартып имә дә башладылар. Гөлбануны каушау алды: «Илаһым хуҗам, каенанам гына күреп калмаса ярар иде», — дип, бозауларга ташланды, ашыктырып, азбарга куды, берсен тарткалап, көчләп, кертеп япты, икенчесенең муенына муенчак салды да иплэп имтекли башлады.

Сабира каенана яшь киленнең мондый зур гафиллеген күреп кала алдымы-юкмы — Гөлбану белмәде, Илаһым хуҗам, күрмәсә генә ярар иде, шуны да карый алмыйсың дип таларга тотына башлар дигән борчу эчендә дүрт сыерны сауды.

Савып бетергәч, бозауларны яңадан имезеп, аерып япканчы кояш баеды. Гөлбану сөт тулы чиләк белән өйгә кереп барганда, Фәүзия акрын гына әйтә куйды:

— Киленкәем, самавырларыңның нихәле бар? Безнең каенана бик әремтел нәрсә, хәзер тиргәнеп бара, - дип, колагына салды.

Яшь килен кызарып ук китте, кичке чәй әзерләү бөтенләй аның хәтереннән үк чыккан иде. Аягын тизләтте, берсе теге ак өйгә — каената белән каенанага, берсе үзләренә — ике самавыр кирәк.

— Илаһым хуҗам, харап булдым, өлгермиләр инде — дип ашыкты, керү белән, сөтен казанга салып, учактагы чыбык, йомычка кисәкләренә ут төртте дә үзе самавырга тотынды.

Бүген көндез арчилар өчен бик сыйлы аш, бәлеш, симез бәрән итләре пешерелде. Өйдәгеләрнең зурраклары кунаклар мәҗлесенә үк утырып ашадылар, яшьрәкләр аннан йолкып, моннан йолкып, мәҗлестән кире чыкканнарны тыгына-тыгына туендылар, шуңа күрә кич яңадан ашка казан асылмады. Карт, таягына таянып, ютәлләбрәк мәчеттән — акшам намазыннан кайтканда Гөлбануның ике самавыры да гөрләп кайнап чыкканнар иде инде.

Яшь килен кушъяулыкны ипләбрәк ябынды да каушабрак ак өйгә керде, каенатага бер сүз дә әйтмичә, йөзен яртылаш каплабрак, сәкегә, киез өстенә ашъяулык җәеп, чәй әзерләде, шаулап кайнаган самавырны кертеп куйды.

Каенана, тешен кысып, ачулы күз ташлады, самавыр өстендәге көлне күрсәтеп:

— Ни карыйсың? Сөртеп кертергә кирәк! — диде. Гөлбану чәч төпләренә, колак очларынача кызарды, башка сүз тапмады, каушаулы тавыш белән:

— Ярар, әнкәй, — диде дә тиз-тиз атлап эчке өйгә йөгерде.

Анда зур коры сәкегә киндер ашъяулык япты, зур бөтен икмәк белән өлкән пычак, сөт, сигез чынаяк китереп куйды, такта чәйне ватып чәйнеккә салды да гөжләп кайнаган самавыр өстенә утыртты. Агалары, җиңгәләре, кулларын юып, ишек төбендә чөйгә эленгән сөлгегә сөртә-сөртә, табын янына җыелдылар. Арада иң өлкән Алтынбай, үзенең аз гына чал кергән сакалын уа-уа, түргә менеп, оек-чабаталы аягын бөкләп утырды да, бисмилласын әйтеп, зур икмәкне телгәли башлады. Гөлбану көндезге мәҗлестән калган сөякләрне, бәлеш капкачларын зур бер тәлинкәгә салып китерде, өлкән җиңги Фәүзия чәй ясарга тотынды. Яшь килен, табынның һәммә кирәге булды бугай дип күз йөртте дә, бераз тартынып, йөзен агаларыннан аз гына читкә борып, ире янына сыенды. Закир, юри шаяртып, аны һәммәгә күренерлек рәвештә табынның уртасына тартты:

— Нәрсә син? Әллә мулла кызымы? Болай качынсаң, ничек бергә урак урырсың? — дип көлде.

Карт килен Фәүзия шул өч көн эчендә үзенең яшь килендәше Гөлбануны яратып өлгергән иде, Закирның шаяртуына:

— Җә, юкка бәйләнеп барма! Барыбыз да шулай булдык. Өйрәнер әле, менә дигән килен булыр әле! — дип җаваплады.

Бу күп каенишле, холыксыз каенаналы өлкән йортта Гөлбану, бик каушап, яңлыш атламасам ярар иде дигәндәй йөри иде; кипкән битле, зәһәррәк күзле карт килендәш Фәүзиянең болай яклавы аның йөрәгенә җылы бирде, күзенә яшь килә язды. Башкалар, үзара туктаусыз сөйләшеп, аз-маз төрткәләшеп алдылар, көлештеләр. Гөлбану берсенә дә катнашмады. Нечкә тамакланып кыланган була димәсеннәр өчен, үзен көчләп, бер телем икмәк ашады, ике чокыр чәй эчте дә чынаягын каплады. Ләкин карт килен Фәүзия моның мәгънәсен аңлады, юл куярга теләмәде:

— Безнең Бикьярда төн бик озын була, сусарсың, — дигәләп, тагы берне ясады.

Ул арада караңгы төште, йомшак, иркәле җәйге төн килеп җитте.

Өлкән ага чал сакал Алтынбай белән аның хатыны — карт килен Фәүзия келәттә яталар икән. Алтышар-җидешәр чынаяк эчеп капладылар, өйрәнгән буенча, дога урынына бит сыйпадылар да шунда йокларга чыгып киттеләр. Уртанчы ул Фәсхи белән аның хатыны Сыйтдика, җәйге гадәт буенча, печәнлеккә менделәр. Алар таралгач, Гөлбану шунда, сәкегә, үзләренә урын җәйде, түшәк, ястыгын кабартты. Җәймәсен япты, мендәрләрен какты да зур яңа сырган юрганны ябып куйды. Ире шуның эченә кереп яту белән гырылдый башлады. Хатын тиз-тиз чынаякларын юды, самавырын түгеп, кагып куйды, инде суынып килә торган сөтенә оеткы салды да, чабатасын чишеп, арган тәне

белән иренең кочагына кереп, эреп югалды.

XXII

Җәйге кыска төн гаҗәп тиз үтеп китте.

Яшь килен әле менә хәзер генә иренең күкрәгенә башын куеп, тәмле, тирән йокыга чумган гына иде. «Соңга калам, бугай», — дигән куркыныч тойгы, йокы алдыннан үзенә-үзе шулай уйлап яту буенча, Гөлбануны уятты. Караса, еракта, тау, урман артыннан, әле чак кына сызылып алсу таң атып килә. Хатын каушап китте. Ирен уятмаска тырышып, аягына оек-чабатасын киде, тиз генә чәчен иплəп, битен юды да, морҗа ачып, мичен якты. Ярый, утыны кичтән кертелгән иде. Аннан соң кичә иләгән җилпучлы оны белән икмәген басты, аны, чикмән белән каплап, җылырак урынга утыртты. «Ходаем, ни генә булды икән, оемаса ни эшләрмен», — дип, куркынып, катыгын ачты. Бәйрәм бүләге алган бала кебек шатланып ук китте: киң агач савыт тулы катык, тигезләнеп, бавыр кебек каты оеган, пычак белән кис тә ал! Шулай уңган! Тиз су кертте. Тагы соңга калмасын дип, үзләре эчә торган өлкән самавырны куйды. Ул арада тыштан уянып чыккан агаларының, җиңгәләренең тавышлары килә башлады, монда, сәкедә киерелеп, иснәнеп, беләкләрен, аркаларын язып, Закир күтәрелде. Дөнья яңа алсуланып барганда, әле кояш чыгарга байтак булган бер заманда, урам капкадан чабышып атлар кайтып керде. Йокысы юньләп ачылмаган унике яшьлек малай Миңлегалим яшь айгырдан сикереп төште дә:

— Кешәнлим[1], иртәгә кешәнлим дуңгызны! Бүген дә чак таптым, — дип сукрана башлады.

Гөлбану чәен әзерләп бетерә алмады, йокылы, ватылган йөзләре әле язылып җитмәгән ябык, каты гәүдәләре белән, кыенлык пәрдәсе каплаган күзләрен тырный-тырный, һәммәсе өйгә кереп, чәйгә утырдылар.

Гөлбану үзенең икмәкләре өчен кайгырды. «Харап булдым, эшкә алып китәргә өлгертә алмадым бит», — дип, үзен дөньяның зур, иң каты бәхетсезлегенә эләккән адәм хәлендә күрде. Каушабрак карт киленгә әйтте:

— Фәүзия җиңги, ни эшләрбез инде? Мич яңа уза, икмәк өлгерми бит? — диде.

Өлкән килен тынычландырды:

— Җә, кайгырма, синнән түгел ул. Менә минем Миңлегалимем каенатамның эше белән кала. Азактан безгә шул алып барыр, — диде.

Гөлбануның өстеннән тау төште, миченнән күмерләрен бер чүлмәккә алып сүндерде, куна такта өстендә камырны зур-зур икмәкләр ясап әвәләде, онлады да кызу мичкә тыкты. Фәүзия, чәй ясый-ясый, күзен бу якка, яшь киленгә таба ата торды, бер ялгыш эшләп ташламасын дип борчылды. Ләкин аның бик

---

[1] *Кешәнләү* - тышаулау

белеп, үзенә ышанып кыланганын күргәч, тынычланды:

— Җә, килен, мичеңне карап яп та чәйгә утыр, — диде.

Ирләр ашыгыч-ашыгыч рәвештә арыш икмәген телем-телем бөкләп салдылар, бер-бер артлы алты-җиде чынаяк чәйне бушаттылар да, бит сыйпап, йортка чыгып, кичтән әзерләнгән озын арбага ат җигәргә, тырмаларны, сәнәкләрне тутырырга керештеләр.

Гөлбану ике генә чынаяк эчеп өлгерде, тигез кызалармы икән дип, мичне ачып, икмәкләрен карады да, яңа оеган катыкны күтәреп тышка чыкты. Анда һәммә нәрсә әзер, атлар җиккән; кечкенә кыз, чәй дә эчә алмыйча, йокылы күзләрен тырный-тырный, арбага таба китеп бара.

Озын арбага тезелешеп утырдылар. Чабаталы аяклар җиргә таба салындылар. Уртанчы ул Фәсхи иң алга урынлашып, кулына чыбыркы белән дилбегәне алды. Алтынбай үзенең улы Миңлегалим малайга:

— Син монда шар сугып йөрмә. Әткәйнең эшен бетер дә бар. Без бит икмәксез китәбез, — диде.

Бу сүз Гөлбануны чәнечкән кебек булды, ни эшләргә белми иренә таба гаепләнеп сыенды.

Озын арбага җигелгән пар ат, чаптырып, печән җыючыларны Исәнбикәгә алып китте.

## XXIII

Җиде чакрым икән.

Башта бераз болын буйлап, әле иртәнге аксыл томан эчендә тыныч кына пәрдәләнеп аккан Үзән елганың уң як яры белән бардылар. Аннан үргә таба суктырдылар. Болар бер тауның өстенә менеп җиткәндә, нуры белән дөньяны яктыртып, кызыл ут эчендә, кояш калкып чыкты. Яланнар, урманнар, болыннар иртәнге чык белән алмазландылар. Үзән елга, киң басулар, таллы болыннар арасыннан боргаланып-боргаланып, кызгылт кояш астында ялтырап уйный башлады. Үрне аша төшеп, яңадан Үзән елгага таба борылгач, бераз бардылар-бардылар да ташлы тау белән арыш кыры арасында суга башы белән терәлгән бер кечкенә култыкка килеп туктадылар.

Менә шул Исәнбикә иде.

Гөлбану арба туктар-туктамас сикереп төште. Кушъяулыгын ипләп ияк астыннан кара тасма белән бәйләде дә әйберләргә кереште. Эчәргә су тутырылган кечкенә, тимер кыршаулы мичкәне арба астына утыртты, үлән, аның өстеннән тула чикмән япты, шуның янына ук катык чиләген дә тыкты; эт-кош ашамасын дип, кичәдән калган бәлеш кисәкләрен ашъяулыгы белән иң аска этәрде.

Ул арада Фәсхи тирләп килгән атларны тугарып, арбаның тәртәсен күтәреп, бәйләп куйды. Закир төпкә, үрәчә төбенә ипләп салынган тырмаларны алды, зур сәнәкне шундагы якын тал төбенә, күләгәгә куйды. Алтынбай, буй-буй тезелеп яткан, чабылган печәнне берничә урыннан алып:

— Кибеп җиткәнме икән, чык шәп түгелме икән? — дип, тотып-тотып карады: ул шытырдап тора иде.

— Әйдәгез, Аллага тапшырдык, — диде дә, тырмасын кулбашына күтәреп, Исәнбикәнең тауга, кояшка караган нәзегрәк печәнле, кибәрәк төшкән ягына барды, юл башлап җыярга да тотынды.

Гөлбану бара-бара ак җиңсәсен киде, яңа эшләнгән матур, җиңел, тигез тешле тырмасын кулга җайлады да, ире белән янәшә торып, печәнне тәгәрәтә башлады; җиде тырма бер уңайдан эшләп китте, болын буйлап күбәләр бер-бер артлы тезелә бардылар.

Исәнбикә — өчпочмаклы бер култык болын. Аның төньягы ташлы, чокырлы тауларга терәлә. Бу таулар бераз гына сөзәкләнеп дулкынланалар да, кинәт баскычланып-баскычланып, ак башлары белән күккә таба күтәрелеп менеп китәләр. Болынның көнбатыш ягы аз гына калкулана да киң арыш басуына тоташа. Көньягы белән көнчыгыш якларын бераз әйләнеп килеп, Үзән елга юып үтә. Монда яшел тАллар үсәләр, бер җирендә начар, селкенчәк сазлык, түндәйлек, бер урында, кечкенә тамак белән кереп, кечкенә түгәрәк, ләкин тирән үк бер күл ясап ала. Гаҗәп бер тонык сулы бу күлнең бер башы таллык, бүтән ярлары төз, бик матур камышлар белән бизәнәләр. Атларны, арбаларны менә шул түгәрәк күлнең таллы башына таба куйдылар.

Кояш күтәрелә башлады; агачлардан, таулардан югары менеп китте. Ул күтәрелгән саен җирдә дә, һавада да иртәнге юешлек кимеде, җәйге челләнең эссе көне кызганнан-кыза барды.

Кечкенә кыз Фагыйлә арды, кояшта тирләп, кызарынып бетте. Башкалар белән бер уңайдан печән җыеп бара алмый, калынрак урыннарда күбәсен китерергә көче җитми башлады, ләкин хәлем бетте дип туп-туры әйтергә гарьләнде, ике тапкыр тырмасына абынып егылды, ахыр чыдамады:

— Әткәй, мин су эчәргә барыр идем, — диде. Алтынбай кызның янган йөзенә, хәлсезләнгән күзләренә карады:

— Бар, кызым, бар, сиңа килмәгәч тә ярар иде, — диде дә күбәсен әйләндереп салды.

Фагыйләне бүген берәү дә көчләмәгән иде. Крестьян баласы, ир малай булса, җиде яшьтән атка, тырмага, сабанга йөри башлый. Сигездә-тугызда утауга, уракка кушалар. Ләкин печән җыю эше ун яшьтәге балаларга да авырга килә.

Фагыйләгә әнисе кат-кат әйтте: «Юкка анда янып-көеп йөрисең, барма», — дип тыйды. Ләкин кыз үзе Исәнбикәне, аннан да бигрәк пар ат белән зурлар арасында ерак җиргә чаптырып барып, чаптырып кайтуларны бик ярата иде. Аның кечкенә йөрәге менә шуларга тартты. Шуңа кызыгып, бүген килми кала алмады.

Арбага килеп, курай белән мичкәдән бик акрынлап, уйнап-уйнап су эчте. Кызу кояш астында янган битен, кулларын, күлгә төшеп, акрынлап чылатты. Түбәнәчә яп-якты булып ялтыраган күл суында уйнаган кызыл канат балыкларны карады, якын ук килгән бер алабугага кинәт тотам дип кул сузганда егылып, өс-башын сулатты; ләкин тегендә, зурлар янына барып, печән җыясы бер дә килмәде, куллары бик арган иде. Беләкләрендә тырма өстерәрлек көч бер дә юк иде, шулай да: «Арып егылды», — дип көлүләреннән хурланды. Үткән елда да шулай арыш урган чакта, су эчәргә барган чакта, хәлсезләнеп йоклап китте. Уянса, алын әллә кая чаклы барып җиткән, моның өлешен тар гына итеп, буйдан-буйга сузып калдырганнар. Ничаклы тырышса да, куып җитә алмады, өстәвенә тагы: «Кәҗә», дип, «Артта калган кәҗә бәрәне», — дип мыскыллап, көлеп эштән чыгардылар. Бу тырышып-тырышып та тегеләрнең алынын куып җитә алмагач, бер явызы моның тар өлешен кисеп алды, бу артта бер үзе торып калды, елап, үксеп, гарьләнеп бетте.

Фагыйлә, бүген дә шундый бер хурлыкка төшүдән куркып, аталарына таба акрын-акрын атлады. Башын күтәреп, тезелгән күбәләргә карады, арада җыелмаган буй печән калмаганмы дип чамалады. Юк, алай итмәгәннәр. Бер уңайдан һәммәсен җыеп киткәннәр. Моның тырмасын да шунда бер җыелган күбә янына башы белән югары кадап куйганнар.

Кечкенә кызның җаны тынычланып ук китте. Бер дә генә барасы килми инде. Аяклар атларга ук теләмиләр. Ул тал яфрагы өзеп шаярды, берсе дә тегеннән: «Кая йөрисең? Нигә җыймыйсың? Ал тырмаңны, менә ялкау!» — дип кычкырмады. Аннан, куак арасында, чабылмый калган җирдә, тАллар төбендә, аллы-кызыллы чәчәкләр бар икән, шуларны акрынлап өзгәләде. Юк, тегеләрдән берсе дә моны орышып чакырырга исәпләми. Алар анда, рәхимсез кыздырган утлы кояш астында, янып-көеп, үзара сүзсез, тавышсыз җыялар да җыялар, болында саф-саф тезелгән күбәләр артканнан-арта бара, арта бара.

Кыз бала шулай икеләнеп маташты-маташты да, берәү дә кычкырмагач, моның өлеше кәҗә булып арттан сузылып ятмагач, таллар арасыннан акрын-акрын төньякка таба борылды. Анда, тау итәгендә, сөрергә дә, чабарга да ярамаган

ташлы, чокырлы, нугыт[1], шелек[2], тубылгы чыбыклы[3] тигезсез урыннар бар. Монда һәр ел адәм әйтеп бетергесез җиләк була. Фагыйлә былтыр ашап та, җыеп та бетерә алмады. Аны тарткан нәрсә — менә шул иде. Барып чыкса, күзләренә ышанмады, әйтерсең кызыл чикмән ябып куйган инде: тау битенең сыек, бераз кипкән үләне менә шулай кызарып пешкән эре җир җиләге белән капланып ята! Иң күбе бармак башы зурлыгында җир җиләкләре. Фагыйлә, таптамаска тырышып, боларның иң эреләрен, иң пешкәннәрен чүпләп, авызына тутыра башлады. Шулай ашый-ашый югарырак менсә, каен җиләгенә барып чыкты, уң яктагы чокыр битенә килсә, бөрлегәннәр тәлгәшләрен күтәрә алмый, якты кояш нурында янып, матурланып, кызарып утыралар. Кыз боларга ташланды. Өзлексез учлап-учлап ашарга кереште. Ирен, авыз, тел бу җимешләрнең гаҗәп үткен, нечкә, һич туя алмаслык тәмнәреннән эриләр, бу тәмне тагы да, тагы да, тагы сорыйлар, ашаган саен, чәйнәгән саен, тагы үзләре кызарып, янып, тел өстендә, авыз эчендә суланып, бөтен тәнгә, бөтен тамырларга ләззәт белән таралалар.

Ашап-ашап күңелне бераз туйдыргач, Фагыйлә үзенең абзасы Миңлегалимне, аннан әнкәсен уйлады. Иң эреләрен, иң кызарып, тулып пешкәннәрен, сабаклары белән өзеп алып, яулыгына җыя башлады. Менә шунысын гына, менә шунысын гына алыйм, менә бу пешкән калмасын дип өзгәли торгач, әллә ничаклы җир җиләге, каен җиләге, бөрлегән өелде. Болар һәммәсе кызыллар, эреләр, тулып, матурланып пешкәннәр иде. Боларга тияргә кызганды, әниләргә әз генә бирәмен дә башкасын өйгә алып кайтамын, анда кызларга күрсәтермен дип, исәпләп куйды. Боларны ашап киметмәс өчен, юлга дип, әнигә, абзыйга дип, тагы җыярга тотынды. Менә шулай рәхәтләнгәндә, тегеннән, болындагы арба яныннан тавыш килде, әле яңарак кына Бикьярдан икмәк китергән абзасы Миңлегалим, кулын авызына куеп, кычкырды.

— Фагыйләү-ү... Фагыйләү-ү... ашарга ки-и-илл!.. — ди. Кызның күңеле булган иде инде. Яулыктагыларын, берәүгә дә бирмәскә дип, яфраклап бәйләде, башкаларга өләшергә, үзенә ашарга дигәннәрен, сабаклары белән тезеп, кулына кысып тотты, иң зур бүләк алгандагы шатлык белән әниләре янына йөгерде.

Бу барып җиткәндә, арбаның тәртәләрен күтәреп, чикмәннәр каплап күләнкә ясаганнар да, шуның астына кереп, ашарга утырганнар иде. Янып, кызарып пешкән бу эре җиләкләрне күргәч, хәйран калдылар, иң элек агасы

---

[1] *Нугыт* – карга миләше (бузина).

[2] *Шелек* – гөлҗимеш куагы.

[3] *Тубылгы чыбыклы* • – тәртәгә яраклы юан чыбыкпар үсә торган.

Миңлегалим, елардай булып:

— Миңа бир, миңа бир, — дип, сеңеленә ташланды.

Кызның күңеле киңәйде. «Нигә печән җыюдан качтың», — дип берсе дә бәйләнмәгәч, яңадан барып җыярга өметләнде; абзасына да, әнисенә дә, яшь җиңгәсенә дә, башкаларның һәммәсенә дә эре-эре җиләкләр тамарга торгандай салынган тәлгәшләрне өләште. Ахры түзмәде:

— Бусына тимим, алып кайтам, — дип, алдан әйтеп, яулыгына җыелганнарын да күрсәтүдән үзен тыя алмады.

Арада бу җиләкләргә карап күзләре янган кеше — кечкенә малай Миңлегалим булды. Ул сеңеленең биргәненә бер дә туймады, шунда үзе тау битендә, кояшта кызынып ятып, үз кулы белән өзеп-өзеп, иң кызарганнарын сайлап, рәхәтләнеп ашыйсы килде. Ләкин шулай да атасыннан анда барырга сорарга батырлыгы җитмәде.

Аңа хәзер унике яшь. Менә бишенче ел инде ул җәй буена йортның атларын карый. Зурлар белән бергә утауга, уракка йөри. Өлкәннәрдән калышмый печән җыя башлавына да икенче елга китте. Җәйнең озын көне буенча шулай аталары уңаена эшли. Кич кайтып, аннан-моннан капкалый да атка куна китә. Барып җитеп, атларны тышаулаганчы ярты төн якынлаша. Анда тиз генә йокламыйлар, җырлыйлар, бииләр, кайбер көн бик кызышалар да, кыска төн үтеп таң атканын сизми дә калалар. Күз йоммыйча, яңадан атларны тотарга, тиз авылга кайтып, көн буе башкалар белән бер уңайдан эшләргә туры килә. Башка крестьян малайлары кебек, Миңлегалим дә эшнең бу рәвешле агуына өйрәнеп беткән, аны башкача була ала торгандыр дип миенә дә китерми. Уеннар, көлкеләр тик менә шул эш арасына гына кысылалар. Ул бүген сеңеленең бәхетенә бик кызыкты, әллә сорыйммы дип, ике тапкыр авызын ачты да, барыбер җибәрмәс дип, кире туктады; ашап бетереп кузгалгач, тырмасын кулбашына күтәреп, өлкәннәр белән бергә печән җыярга юнәлде, шулай да тауга таба тагы җиләккә киткән сеңеленә:

— Миңа да җыеп китер, Фагыйлә... — дип кычкырмый калырга көче җитмәде.

## XXIV

Гадәттә, башка елларда бу Исәнбикәдә кибән салган көндә Шибай карт үзе килеп бер карап китүчән иде. Алтынбай, шуны чамалабрак, башламыйча торды, һаман күбәләргә җыйдыруны карады. «Берәр комачау булгандыр, төшкәчә көтик әле», — дип уйлады.

Кояш күтәрелгәннән күтәрелә бирде. Аның саен күләгә кыскарды, эсселек көчәя барды. Атлар чебенгә, кигәвенгә тАллар арасына кереп, арканнарына уралып беттеләр, бер-беренә борыннарын төртеп, туктаусыз баш чайкап,

койрык селкеп тора башладылар. Печән җыючыларның тәннәре тирләп су булды, күлмәкләре ябышып бетте. Кызу кояш астында барган эш белән арып яндылар, иреннәре көйде, авыз кипте; ирләр изүләрен чишеп җибәрделәр, хатыннар минут саен йөзләреннән аккан тирләрен яулыклары белән сөртеп, күлмәкләрен җилләндерделәр. Ләкин бу гына күп булышлык бирмәде, кызу эш өстенә, күктән яндырган кояш белән тәннең актык көчләре чыктылар.

Гөлбану янып, тыгызланып, бөркәнчек эченә сыймас кебек булып китте. Хәле бетте, иреннәре, телләре корып кипте. Кояш нуры аның күз алдында һаваны ак утка әйләндерде кебек булды. Бу ак ут диңгезгә әверелде, моның утлы дулкыннары чайкалып ялкынланалар шикелле тоелды, менә-менә, актык тамчы көче бетеп, тырмасы кулыннан төшеп китәр хәлгә җитте. Шулай да сер бирмәскә, бу Бикьярга килеп, ялан эшенә чыккан беренче көнендә үзен сынатмаска тырышты. Кояш түбә өстендә һаман тамуг уты кебек яндырып, дөньяны каплаган ак ут диңгезе тагы ныграк дулкынлана, Исәнбикәне дә, Гөлбануның үзен дә, җиңгәләрен, агаларын да селкетә башлаган кебек тоелды, тагы бераз гына барсын — яшь киленнең хәле китәчәк, бәлки егылачак иде.

Алтынбай сакаллы крестьян башы белән түзә алмады:

— Уфф... ф... чыдар хәлем калмады... диде дә күбә өстенә тырмасын атып бәрде. — Җитәр, әйдәгез төшкә туктыйк, — дип өстәп, үзе Үзән елгага таба китте.

Һәммәсе бик арганнар, янганнар иде, күбәләрен сафка китереп җиткерү белән берәм-берәм тырмаларын ташладылар. Ирләр Алтынбай артыннан киттеләр, хатыннар, үзләренә аерылып, тал ышыгынарак яшеренеп, чишенеп су коенырга, йөзәргә, юынырга, янган тәннәрен рәхәтләндерергә керештеләр. Тегендә ирләрнең киң колачлап түгәрәк тирән ятуда[1] йөзгәннәре, малай Миңлегалимнең балык кебек уйнап әле бер якка, әле бер якка йөзеп чыгуы, шаяруы күренде.

Җиңгәләре бик кыстаса да, Гөлбану су коенмады. Әле килен булып төшкәненә өч көн барлы-юклы гына, шул арада ялангачланып, өлкән җиңгәләр алдында тән күрсәтеп торырга кыюлыгы җитмәде, тик оек-чабатасын салды да ак аякларын суга тыкты, җиңнәрен сызганып, кулбашынача суда рәхәтләндерде, бөркәнчеген ташлап, битен, муеннарын юды. Шулар белән баягы ак ут диңгезе югалды, яшь тәне үзенең көчләрен яңадан кайтарды.

Үзән елганың киң ятуларында су белән рәхәтләнгәннән соң, һәммәсе яңарып, көчләнеп, шуның белән бергә ачыгып, арбалар янына килделәр. Фәсхи атларны елгага илтеп йөздереп китерде. Мондагылар арба тәртәсен күтәреп ясалган күләнкәне тагы бераз киңәйттеләр дә, шуның астына кайсы кырын ятты, кайсы

[1] *Яту* - чоңгыл

утырды, катык белән икмәк ашарга тотындылар.

Аталары белән шаярып, су коенган малай ни арада киенгән дә каядыр китеп югалган. Алтынбай берничә тапкыр: «Миңлегалим, ашарга кил!» — дип кычкырды, малайның кайдандыр, тау буеннан:

— Хәзер, әткәй, хәзер... — дигән җавабы килде, үзе күренмәде. Яртылай ашагач, Алтынбай тагы кычкырды, тагы теgeннән яңгырап:

— Хәзер, әткәй, хәзер... — дигән тавыш ишетелде. Ашап бетерер алдыннан тагы кычкыру, тагы шул җавап:

— Хәзер, әткәй, хәзер.

Алтынбайның ачуы кабарды: «Нәрсә анда бер бетмәгән хәзер», — дип, тиз кайтартырга кычкырмак булды, шул минутта бик зур кигәвен карт килен Фәүзиянең муенын батырып тешләде; килен хатыннар телендә генә була торган ямьсез пычрак сүзне, үзе дә сизмәстән, әйтеп кычкырды да уң кулы белән кигәвенгә ашыгып сугарга омтылды; беләге тәртәгә тиде, ул бер якка кайшалды, сәнәкләр таеп төштеләр, бөтен куләнкә берьюлы аш, табын һәм кешеләр өстенә гөберт итеп җимерелде. Көлеп, кычкырып, бары да чыгып качтылар.

Шул арада кояш баешыннан рәхәт салкын җил искән кебек булды. «Ничек болай бу?..» — диебрәк әйләнеп карасалар, анда берсе өстенә берсе капланып, куерып, тау-тау болытлар күтәрелгәннәр, кояш яртылай шуларга күмелеп бара, теге болытлар, ишерелеп-ишерелеп боларга таба актарылып киләләр. Шуннан кызган һаваны каулап, рәхәт салкын җил исә... Менә бераз гына, бераз гына вакыт үтсен, болытлар килеп тә басар, күбәдәге коры печәннәр яңгыр туфаны астында калып та куярлар...

Бу куркыныч бик бар һәм бик якын иде.

Болытларны күрүгә, Алтынбай кулындагы кечкенә кисәк икмәген, катыклы кашыгын ташлады, ут чыккандагы кебек кычкырып җибәрде:

— Харап булдык, печән яңгырда кала... Тизрәк алын арбага ат җигәргә... Тизрәк җыелган күбәләрдән кибән салырга... — диде.

Бер ул гына түгел, бу күбәдәге печәннең яңгырга эләгеп каралу, кадерсезләнү, черү куркынычын һәммәсе бик ачык күрделәр. Башкалар тиз-тиз эшкә тотынганда, теgeннән йөгерешеп кечкенә кыз Фагыйлә белән Миңлегалим дә минуты белән килеп җиттеләр.

Закир алын арбаны[1] тартып чыгарды да ат җикте. Фәсхи, балта алып, тал кисте, киселгән тАлларны дилбегә белән алын арбаның күчәренә ныгытты, арканның бер башын шул ук күчәргә ныгытып, артка салындырды, кулына сәнәк алды да

---

[1] *Алын арба* – арба алды, арбаның тәгәрмәчләре һәм тәртәләре белән бергә алгы күчәре

Алтынбайга кычкырды:

— Билгеләдеңме? Кая салабыз?

Алтынбай бер карау белән Исәнбикәне ике яртыга бүлде. Тауга караган якның урта үзәк урынын билгеләде дә дүрт япьле уңай тимер сәнәк белән күбәләрне шул урынга эшереп-эшереп китерә башлады.

— Менә шунда тарттырыгыз! — диде.

Малай сикереп атка менде, тезелгән күбәләрнең иң читеннән башлап, кибәнгә таба акрынлап, чыбыклы алын арбаны тарттырды, Закир сәнәк белән төйи барды; аның артыннан кечкенә кыз калган печәннәрне тырма белән тазартып ала барды. Тегендә, кибән төбендә, Алтынбай белән Фәсхи китерелеп аударылган берен өя тордылар; карт килен Фәүзия кибән башына менде; Фәсхинең хатыны юаш Сыйтдика белән Гөлбану шунда кайнаштылар.

Бу кызу, ашыгыч эш арасында иң зур җанлылык малай Миңлегалимдә булды. Ат өстендә эшләүне ул эшкә санамый, моңа уен-көлке дип карый иде. Бөтен Исәнбикәдә аның тавышы яңгырады. Закир аның чыбыкларына ат дугасыннан печән өйгәч, арканны кайтарып салалар; малай кычкырып, шаулап кибәнгә килә, арбасын аудара да тагы кире күбәләргә, Закир янына шаулап чаба. Күкне каплап болай таба актарылып килгән кара болытларны ул да аңлады; болар куерган саен, якынлаша барган саен аның да җаны әрни, ул тагы кибән белән Закир арасында кызурак йөри, тизрәк ташып бетерер өчен атны аяклары белән бер кымтый, чыбыркы белән кабыргага, очага бер бирә дә дулатып, чаптырып китә.

Ләкин ничек кенә булса да, бер белән ташып өлгертә алмыйлар. Алтынбай моны тиз күрде, шунда ук кычкырды:

— Закир, — диде, — бер белән эш чыкмый, бар, әнә Әпек балаларыннан алын арба алып кил, бусын килennәргә бир, Сыйтдика төяр, Гөлбану тырнар, — диде.

Болардан түбәнрәк, Үзән елга буенча, Әпек дигән башкортның уллары печән чабалар иде. Закир икенче атны камытлап менде дә шуларга чапты. Алын арбаларын сүзсез бирделәр, тик: «Эшең беткәч, кире китер, безне йөртмә», — диделәр. Аннан алын арба кайтуга, Фәсхи яңадан балтага тотынды, тиз-тиз тал кисеп, чыбыкларны алын арбага беркетте, күчәргә арканны тагып артка өстерәде дә:

— Әйдә төя, — дип кычкырды. Үзе, кибәнгә килеп, унар күбәлек чүмәлә кебек өелгән печәннәрне озын сәнәк белән батырып чәнчеп, һай-һулап югары ыргыта башлады.

Хәзер инде ике ат ташый. Берсен кечкенә кыз Фагыйлә җитәкли. Анысында

төяп тә, тырнап та Закир бер үзе эшли. Икенче атка малай атланган. Монда уртанчы килен Сыйтдика сәнәк тотып төяп маташа, яшь килен Гөлбану тырма белән анын артын тазартып бара.

Җил көчәеп китте. Иркенләп өеп чәнчергә бирми, печәнне ала да китә, ала да китә. Уртанчы килен Сыйтдика күптән түгел бала тапты, ләкин бала бер атнадан үлде. Үзе дә чак үлми калды, шуның авыруыннан соң ныгып, терелеп бетмәгән иде әле. Аннан соң ул болай да юаш, йомшак, зәгыйфьрәк хатын иде. Бар көче белән тырышып бакты, кеше алдында хур булмаска, ага-җиңгәнең яман теленә калмаска теләде. Нык көчәнә торгач, күтәргән печән белән ике тапкыр егылды, җил аның печәннәрен очыртып алып китте дә, бөтен Исәнбикә буенча таратып, тАлларга сылап бетерде. Тегеннән, кибән башыннан, карт килен Фәүзия моны күрде, иренә нәрсәдер әйтте, җилгә очкан печәннәргә Алтынбайның җаны әрнеде:

— Әй, әрәм тамак нәрсә! Ике күбәне чәнчеп бирә алмый бит, — дип сүгенде.

Гөлбану эченнән бу юаш җиңгәсен бик кызганды:

— Әллә сәнәкне миңа бирәсеңме, җиңги? — дип, кыюсызланып сорады.

Ләкин Сыйтдика хурланды. «Бусы нәрсә тагы? Кичә килде, бүген минем өстемә менәргә әйтәме?» — дип рәнҗеп уйлады. Актык көчен җыеп, өч күбәне бергә алды, тимер сәнәкне кадап күтәрде, ләкин шомарган чабата таеп китте, печәннәр тагы туздылар. Тегендә Закир ерткычланып акырды:

— Нәрсә анда печән әрәм итәсез! Гөлбану, синә ни булган? Ал сәнәкне! Ул тырнар! — диде.

Бичара юаш килен Сыйтдика, бик хурланса да, сәнәкне килендәшенә бирде, үзе тырма алды.

Гөлбануның кул тамырларында куәт кайнады, нәкъ ире Закир чәнечкәнчә, дүрт-биш күбәне җирдән эшереп китереп бергә өйде дә тимер сәнәкне батырып җибәрде, чүмәлә зурлыгы күтәреп алып, алын арбага бәйләнгән арканлы чыбыклар өстенә китереп салды. Җитмәсә тагы, сәнәк күбә төпләрендә ялап алган кебек таза, шулай бернәрсә калдырмый ала. Ат өстендәге малай хатыннар кулына туры килүенә хурлана башлаган иде, яшь җиңгәсенең, зур чүмәләдәй чәнчеп алып, ирләрчә осталык белән тотынганын күргәч, тагы күңелләнеп китте, тагы аякны кымтып, камчылап чаба башлады. Хәзер ул Закирныкыннан калышмый йөри. Кайбер вакыт алардан тизрәк тә урый. Яшь җиңгәсенең бу уңганлыгына сокланып, аның ничек күтәрүләрен карый-карый, малай бер тапкыр онытылып китте, дуга биеклеге өелгән печән өстеннән кайтарып аркан тартылгач та китми торды. Гөлбану үзенең әле өч кенә көнлек яшь килен икәнлеген бөтенләй исеннән чыгарды, малайга кинәт:

— Җә, нәрсә торасың! Кузгал! — дип кычкырып җибәрде.

Бу тавыш Закирга да, кибән тирәсендәгеләргә дә ишетелде. Фәүзия килен борылып ук карады, шатланып куйды. Ул каенанасы белән дә, уртанчы юаш килен Сыйтдика белән дә һаман төрткәләшеп тора иде. Гөлбануның болай өстенлеген, көндәш киленнән бер көн эчендә югары күтәрелүен күргәч, аңа күңелле үк булып куйды, үзе җиңгән төсле тоелды; түбәннән, иренең озын сәнәк белән чүмәлә зурлыгында чәнчеп бирелгән печәнне тырма белән тартып ала-ала, сөйләүдән тыелырга хәле җитмәде:

— Кара, безнең яшь киленне күрәсеңме? Ничек кычкыра бит! Теге бозауны тырмага калдырган, үзе сәнәктән! — диде.

Закир белән Гөлбану ярыша-ярыша ике яклап күбәләрне кибән төбенә таба кысрыклап китерә тордылар, Алтынбай белән Фәсхи югары күтәреп биреп торудан тукталмадылар. Кибән яртыдан үтте, югарыдагы хатын, текәрәк тартып, тарайтып сала башлады.

Менә шул вакыт гөр-р... итеп күк күкрәде, күк йөзе болытлар белән капланды, караңгылык алды, елтырап яшен яшьнәде дә, көчле яңгыр исе туры боларга таба бәреп килде. Крестьяннарның, ичмаса шул бер кибәнне дә очлап өлгерә алмадык дип, җаннары көйде, йөрәкләрен әрнү каплады, актык көчләре белән тагы тиз-тиз ташырга керештеләр. Эре-эре яңгыр тамчылары төшкәли башлады. Өч ир өч яктан кибән өстенә зур-зур чәнчеп ыргытырга тотындылар, хатыннар арба яныннан, яңгыр үткәнче кибәннең үзәгенә ябып торырга дип, чикмәннәрне, бишмәтләрне китерделәр, сәнәккә элеп югарыдагы киленгә, кибән башына ташладылар.

Җил көчәйде, яшен ешайды, болытлар, бер-берен таптап, каралы-сорылы, күкле төсләрдә уйнап, бу якка актарылдылар. Эре-эре яңгыр тамчылары, көннең кызу кояшында кипкән печәннәр өстенә тамып, шыбыр-шыбыр ява башладылар.

Ләкин крестьяннарның бәхете җиңде. Яңгырның үзәге уңнан Караюргага карап үтте, монда Исәнбикә өстенә тик бер чите генә эләкте, аз-маз тамчылады, шулай да печәнгә һичбер зыян итәрлек яумады. Шаулап, җилләнеп үткән кара болытлар артыннан яңадан күк йөзе ачылды. Кояш көлеп карады. Яланнар, урманнар, таулар, агачлардагы яфраклар, яшел зөбәрҗәт кебек сафланып, матурланып яшәрделәр, һәммә яшеллекләр өстендә кояшның нуры ялтырап уйнады.

Кибән башыннан чикмәннәрне кире ташладылар. Бераз гына сүрексен, бераз гына куллар хәл алсын дип, берничә минутка туктадылар да, яңадан тотынып, инде бик ашыкмыйча, беренче кибәнне зур, матур, коеп куйган кебек төз, тигез итеп очладылар, кибәннең түбәсенә нәзек очланган имән чөй кактылар.

Һәммәсе бик арган иде. Атларны тугармый гына арбага бәйләделәр; үзләре, тал төбенә килеп, икмәк белән катык ашап алдылар.

XXV

— Инде калганы чүп кенә... Аны уйнап кына бетерербез... — Алтынбай шулай дип кулына сәнәген тотты, калган яртының урта, үзәк урынын бер күз ташлауда билгеләде дә: — Икенче кибән менә шунда булыр, — дип, күбәләрне уйнатып, шаяртып, шул урынга эшерә башлады.

Закир Әпек балаларыннан алган алын арбасын кире илтеп бирде, үзе, атының камыт бавына озын аркан тагып, чүмәлә тарттырырга көйләде.

Ун көн килен төшәрдән элек, Шибайның тынгысызлыгы аркасында, карт килен Фәүзия белән аның улы яшь малай Миңлегалим килеп, бераз печәнне җыеп, утыз чүмәлә салып киткәннәр иде. Икенче кибәнгә менә шулар да керә, әле бүген җыелып, чүмәләгә салынмаган күбәләр дә керә. Алтынбай: «Бу нәрсә? Безгә уен гына ул», — дисә дә, чынга әйләнеп китте. Байтак көч, байтак вакыт алды.

Баягы кебек, кибән башына Фәүзия менде. Фәсхи белән Алтынбай түбәннән биреп тордылар. Кыз алын арба җигелгән атны җитәкләп йөртте. Малай, арканлы атка менеп, уйнап, шаярып, тавышы белән бөтен Үзән елга буен яңгыратып, чүмәлә тарттырырга тотынды.

Сәнәк белән печән күтәрүләр Гөлбануның беләкләрен бик арытканнар иде, ул берәүгә дә ишеттермичә генә иренә әйтте:

— Син чыбыкка төя, чүмәләне миң җибәрим, кулларымның хәле бетте, — диде. Закир көлде.

— Ярар, ярар, тик син чүмәлә җибәрә беләсеңме? Арканнан төшеп калса, үзеңнән көләрләр, хур булырсың бит! — дип, Гөлбануга карады.

Хатын үзенә ышанды; ир, сәнәкләп алын арбага, чыбыкка төяде, Гөлбану, Миңлегалимнең атына чүмәлә җибәреп, Сыйтдика чүмәлә төбе тырнап йөрде. Менә шулай тигез генә, тыныч кына эшләп барганда, малайның менгән аты түндәккә[1] абынды, сөртенеп егыла язды, түндәксез җиргә басыйм дип сикергән иде, тездән батты, чыгарга омтылган саен, көчәнгән саен, дүрт аягы да тирәнрәк китә бирде. Малай белән Гөлбану бик нык каулап, чыбыркылап, тезгеннән тартып карасалар да, корсагыннан баткан атны чыгара алмадылар.

Тегеннән:

— Хатын-кыз кулына эш бирсәң, шул булыр инде, — дип сүгенеп, Закир килде, үзенчә, бер кузгатуда чыгармак булып атка сукты. Ул тартылып сикерде, тагы тирәнрәк чумды. Иплэп карасалар, монда бөтен тирәсе яман сазлык — баткак

---

[1] *Түндәк* - түмгәк

булып чыкты. Тик өстендәге түндәкләр генә бераз катырып торткан икән!

Тегеннән Фәсхи белән Алтынбайны чакырдылар. Алар да булдыра алмады. Ахырдан атның корсак астыннан аркан үткәрделәр, икенче атны бу арканга җиктеләр дә, һай-һулап, шаулап, кычкырып тарттырып чыгардылар. Баткан атның корсак астыннан аркан үткәреп маташканда, Закирның күлмәге, беләкләре, битләре — һәммәсе, сазның ябышучан мәте балчыгына буялып, эштән чыкты, егет шайтан төсенә керде. Гөлбану аны Үзән елгага көчләп өстерәде, кырып-кырып битен-башын, беләкләрен, күлмәкләрен юды, кушъяулыгы белән йөзен сөртте дә, кичкә каршы суык тимәсен дип, арба яныннан аның камзулын китереп киертте.

Кояш түбәнәеп, көн кичегеп бара. Ат мәшәкатен бетергәч, яңадан элекке кебек кызулык белән чүмәлә тарттырырга, чыбык белән күбәләр ташырга, килгән печәнне озын сәнәкләр белән кибән башына ыргытырга керештеләр.

Көн кичеккән саен, болар ашыктылар. Кояш кызыл ут эчендә баеп күздән югалды, болар да икенче кечерәк кибәнне шулай ук матур, түгәрәк куеп, очлап бетерделәр. Җәйнең озын көне буенча эшләп, Исәнбикәнең печәнен, яңгырга эләктермичә, коры көйгә кибәнгә салып, тәмам итә алдылар.

Эшләгәндә беленмәде, ләкин арба янына килгәч, һәммәсе эштән чыгып арган, ватылган икәнлекләрен сизделәр. Аякларның атларга хәле юк. Кулбашлар басып, салынып бара. Закир, һәр көн шаяртып җиккән каты дугасын җиткерә алмагач, үзеннән-үзе кычкырып көлеп җибәрде.

Болар ат җигеп, әйберләр төяп, кайтыр юлга чыкканчы байтак вакыт үтеп китте. Болай кичегүгә башка һәркемнән бигрәк малайның эче пошты. Башкаларга ни булса ул, кайталар да ашап йоклыйлар; Миңлегалимгә алай түгел: кайтып ашарга кирәк, аннан атлары белән тауга кунарга барырга кирәк. Барып җитеп, атларны тышаулаганчы ярты төн була. Аннан башыңны куеп өлгермисең, таң ата, тагы кайт, тагы эшкә кит!

Малай үз башында кайнаган бу әйберләр белән юл буе әрнеде, атасына кат-кат әйтте:

— Әткәй, мин кола бияне кешәнлим... Бик йөремтәл нәрсә... Кичә дә Юныс картның солысына җитеп барганда тотып алдым, — диде. Аннан тагы сукранып-сукранып өстәде: — Ашлыктан тотып кайтсалар, атларны карамыйсың дип мине кыйныйсың.

Алтынбай улының сүзләренә риза булды:

— Ярар. Кешәнләсәң кешәнләрсең. Тик бик кыска итмә. Ач калдырырсың, — диде.

Болар йортка чаптырып кайтып кергәндә, урам як өйнең баскычында чалма-

чапан күренде. Алтынбай гомер буенча мулла-мәзинне тик фидия өчен генә яшәүчеләр дип исәпли, аларны вакытсыз күрсә, вакытсыз очратса, күңеленә шомлы үлем куркынычы килә иде. Чалма-чапан күзенә чалынгач, моның мәзин икәнен таныгач, йөрәге шу-у итеп китте. Үзенә үлем китергәндер кебек булды, арбадагыларның һәммәсенә ишетелерлек итеп:

— Ни эшләп йөри монда бу козгын? — диде дә, үзе сикереп төшеп, шул чалмага таба йөгерде.

Карт бу арада хәлсезләнеп тора. Билем, аркам дип, күп ыңгыраша. Иртәдән ятып калды. Печән җыючыларның һәммәсе дә ишек төбендәге чалманы шуның белән, авыру белән, үлем куркынычы белән багладылар. Бу Гөлбануның йөрәгенә агу булып кадалды. Аның әнкәсе Фәтхия карчык һәркайчан, Сабира кодагыйның холыксызлыгыннан зарланган саен, күз яшен сөртеп сөйли иде:

— Илаһым хуҗам, ичмасам Шиһабетдин коданың гомерен озын кыл. Ул исән булса, бик артык котырынырга Сабирага юл куймас, тыяр, ир кеше бит, — ди торган иде.

Күзенә яшь килде, йөрәген курку алды, бу йортка бәхетсез аяк белән килдем, күрәсең, дип шомланды. Ләкин ни булды икән дип сорарга батырлыгы җитмәде, тик өйгә кереп, токмачлы, бәрәңгеле, катык каткан ашка утыргач кына, Алтынбай агасы, үз алдына мыгырданган кебек, әйтеп куйды:

— Мәзин күргәч, котым очкан иде... Аллага шөкер, алай куркырлык әйбер юк икән, — диде. Атасы Шибайның хәзер яңадан азрак торып утырганын сөйләде.

Гөлбануның йөрәгеннән авыр таш алынды. Иркенләп сулады да ашарга кереште. Һәммәсе шулай авыр эштән соң йотлыгып ризыкланганда, күршедән бер ачы сызгырган тавыш килде. Сәкенең түбән як читендә утырып ашаган Миңлегалим кашыгын ташлады да, сикереп, йорт як тәрәзәгә атылды; үзе башта, авызына ике бармагын куеп, тагы яманрак, әчерәк сызгырды, аннан башы белән тыгылып, күрше йортка, яшь, кечкенә, ләкин яңгырак тавыш белән кычкырды:

— Апуш! Апуш! Синме? Хәзер киттем! — диде дә, табакка килеп, яңадан бер-ике генә кашык токмач капты, анасының:

— Кая ашыга икән бу чаклы? Качмас, өлгерер идең әле, ашыңны ашап бетергәч тә... — диюенә карамастан, ак киез эшләпәсен, бишмәтен, яланда кунганда ябынып ятарга атасының чикмәнен алды да йортка ташланды.

Кое баганасына өч ат бәйләүле иде, берсен атланды, икесен, нукталап, ике яктан җитәкләде дә күршедәге малайга:

— Апуш, әйдә киттек! — дип, тагы яңгыратып кычкырды, үзе атлары белән яланга кунарга чаптырып чыгып китте.

## XXVI

Бу тәнне куркыныч астында үткәрделәр.

Таң алдыннан берничә тапкыр картның сулышы тарайган кебек булды. Ләкин озак бармады, ясин чыгарга мулланы чакыртырга уйласалар да, өлгерә алмадылар. Шибай яңадан күзләрен ачты, иркенләп тын алды. Үзенең үлем алдындагыга ошашлы хәленә карамастан, карт крестьян хуҗалыгының һичбер җебен үз кулыннан ычкындырырга теләмәде. Кояш чыгар алдыннан зур улы Алтынбайны чакыртты, бүген кемгә кая барырга, нәрсә эшләргә икәнен санап кушты:

— Кичә, — диде, — картлар печән бүлеп йөрделәр... Мин бара алмадым. Үз урыныма Хисамины җибәрдем. Бик өзгәләгәннәр. Безгә Каенлы күл тамагыннан, Акъятуның югары ягында бер шобага чыккан. Андагысы әйбәт булыр. Тагы теге, былтыр печән чапкан Әчеле күл бар бит, шуның асты икән, бусы бик түндәкле, начар сазлык җир... Юне булмас. Син үзең сажинны ал да, үлчәп, чикләрен таптап кайт. Закир белән Фәсхи хәзер үк Каенлы күл тамагындагы өлешкә китсеннәр, — диде. Бераз хәлсезләнеп ятты.

Алтынбай бер сүз дә әйтми чыгып китә башлаган иде, карт яңадан туктатты, улына шелтә белән карады:

— Син нәрсә? Сүз беткәнне көтми качасың?.. Мин ул көнне ашлыклар карап кайттым. Тарының Үзән елгага караган түбән башы бик чүпле... Соңгарак калдык калуын... барыбер утамый булмас, бүген синең балаларың белән килендәр өчесе дә шунда барырлар, колакларына тукып җибәр, бетерми кайтмасыннар, анда ике барып йөрерлек эш юк... Йокламасыннар...

Карт туктады, улы башын кашыбрак ишеккә таба кузгалды.

Алтынбай үзе дә иллегә карап бара. Аның унике яшьлек улы, ун яшьлек кызы бар инде. Чәченә чал керә башлаган. Моның кебек мужиклар әллә кайчан инде үзенә йортлы-җирле булып, үзләренә аерым хуҗалык булып яшиләр. Бу һаман атай кул астыннан котыла алмый. Картның үзенә әллә кайчан үләргә вакыт инде. Юк, ул әле һаман яткан җиреннән: «Син алай ит, хатының болай итсен, улың монда барсын, кызың тегендә барсын», — дип кушып ята. Чал сакаллы крестьян болардан әллә кайчан ук туеп беткән иде. Хатыны Фәүзия дә:

— Аерылыйк!

— Аерылыйк!

— Аерылыйк! — дип, туктаусыз колак төбендә мыгырданып тора.

Вакыт, әллә кайчан аерылырга, үзбашланырга вакыт иде. Тик менә кайбер исәпләр генә бу йортка бәйлиләр. Карт бит, ул турыда сүз ачсаң, кул кына селкә, булмас, юкны йөрмә, ди. Аңа карамаска да булыр иде, башкалар бит

талашалар, сугышалар да аерылып чыгалар. Аннан акрынлап үз туфракларында үз ояларын коралар. Алтынбай кемнән ким? Ул да ач үлмәс иде. Шулай да менә бер әйбер җеп кебек бәйләп тота: талашып, сугышып аерылсаң, карт сине өстеңдәге киемең, хатыныңның кызыл яулыгы белән куа да чыгара. Бер уч ашлык, бер казык, бер чебеш тә бирми. Әгәр инде теш кысып түзсә, атай үлгәч, үзара мал бүлгәндә, Алтынбай алай алдатмас. Бу турыда аның гомер буенча корып килгән исәпләре бар.

Бу уйлар мужикның башына бик күптән керделәр, әллә кая, тирән төшеп утырдылар. Шулар аңа түзем, чыдам бирделәр. Ләкин һаман да бер аягы белән кабергә баскан картның яткан җиреннән һаман кушып, баш булган булып маташуы аның теңкәсенә бик тиделәр.

Атасы яныннан теге өйгә чәйгә чыкты. Шулай кушканча, кемгә кая, нинди эшкә барырга икәнен сукранып, ырылдабрак әйтте. Улларның, киленнәрнең дә һичбер нәрсәгә исләре китмәде; бары да шулай гомер буена Шибайның таягы буенча йөрергә өйрәнеп беткәннәр инде, моңа бераү дә гаҗәпләнмәде. Аталарының авыруына да күнеккәннәр иде: нәрсә, аңа бит инде җитмеш яшь. Җитмәсә тагы, үткән ел билен имгәтте. Арада тик Гөлбану гына каенатасының каты чирләп китүенә бик борчылды. Әнкәсе Фәтхиянең: «Илаһым хуҗам, Шибай коданың гомерен озын кыл! Ул үлеп, ялгыз Сабира кулына калса, харап бит, харап бит, Илаһым хуҗам!» — дип елап сөйләвен тагы хәтерләде. Җиңгәләре белән, балалар белән утауга барганда да, анда тукталып икмәк ашаган чакларда да, ул үзенең миенә кереп утырган караңгылы кайгыдан чыга алмады.

Фәүзиянең ике баласы аңа бик өйрәнеп, якынаеп киттеләр. Кечкенә кыз бала Фагыйлә яшь җиңгәсенең чибәрлеген дә, өстендәге яңа күлмәген дә, чәченә үргән ал тасмасын да бик яратты, күңеле белән тартылып, һаман аның тирәсендә сырынды, ашаганда: «Мин матур җиңги янына утырам», — дип, балаларча туп-туры әйтеп куйды. Гөлбану, үзенең чәч үргечендәге ал тасмасын алып, кызның чәчен тарады да шул үзенең ал тасмасын бүләк итте, шуның белән аның кечкенә сыек чәчен матурлап үреп җибәрде. Фагыйләнең башы күккә тиде, бөтен яшь, саф йөрәге белән үзенең матур җиңгәсе Гөлбануга багланды да куйды. Малай Миңлегалим башта читсенер кебек иде, кичә, кибән салганда, Гөлбануның ирләр кебек батырып чәнчүен күргәч, үзләште, аның белән бергә чүмәлә тарттырганда, уйнап-көлеп, болын яңгыратулар вакытында, бигрәк тә Закирга караганда болар тизрәк китереп аударган шатлыклы чакларда, малай яшь җиңгәсен бөтенләй үзенә дус кебек тоеп китте. Бүген утауда ул инде бөтен күңеле белән ярата башлады. Көн буе сабан сөрергә,

тырма тырматырга, печән җыярга, урман, көлтә ташырга — һәммәсенә Миңлегалим риза, һәммәсен, эт булып арса да, яратып эшли. Әмма менә утау — аның дошманы! Бил дә авырта. Билчәннәр кулны да чәнчә. Эшләгән эшең дә күренми. Ул ел да шулай сукрана, җае чыкса, башка эшкә качу ягын карый иде. Бүген дә дәртсез килде, һаман билен тотып, борынын казып, утамый азапланды. Шулай да алыны артта калмады. Менә бәхет! Яшь җиңгәсе башын да күтәрми, һаман утый да утый, утый да утый! Үзенеке белән бергә ялкау малайның алынын да сыдырып алып бара. Менә бит уңган җиңгәң белән янәшә туры килсәң, ничек рәхәт икән!

Балалар икесе кичәле-бүгенле, эш эчендә, яшь җиңгәләренә күңелләре белән бәйләнделәр. Бу Гөлбануга көтелмәгән юаныч булды, Фагыйлә белән Миңлегалимгә кулыннан килгән һәммә әйберне эшләп, аларның күңелләрен табарга тырышты. Ләкин бу гына хатынның йөрәк төбенә авыр таш белән яткан кайгысын юып китә алмады. Утау артыннан тагы печән җыюлар, кибән салулар килде, аннан арыш урагына төштеләр. Бу — Гөлбану өчен икенче сынаш иде, ләкин сер бирмәде. Нурый карт үз балаларын бик яшьли эшкә куша, каты эшләтә, рәхимсез күп, усал эшләтә, арытып, эштән чыгарганчы эшләтә иде. Җиде яшьтән шундый каты эш эчендә кайнап чыныккан Гөлбануның куллары — Бикьярларга гайбәткә урын калдырмадылар. Яшь килен беренче көнендә үк ике килендәшен дә уздырды. Аның артында таза бәйләнгән эре көлтәләр ирләрнеке кебек үк күп булып тезелеп бардылар. Уракка төшкәч, Фагыйлә белән Миңлегалим бу җиңгәләренә тагы да ныграк дусландылар, үзләре теләп, алында аның ике ягыннан төштеләр. Миңлегалим — малай кеше ялынмады, үз алынын үзе алып барды, ләкин кечкенә кыз үзенең матур җиңгәсенең канаты астына бик сыенды. Әзрәк артка кала башласа да аңа карап елмайды, көлтә бавы өзелсә, көлтәсен зуррак ясап, бәйли алмый азапланса да: «Җиңги, менә шуны гына кысып бир», — дип әйтә торган булды.

Уракның беренче көнендә юри көлтә санаштылар. Арада иң күбе — Алтынбайда иде. Закир, Фәсхи, Гөлбануларның өчесенеке бер чамада — йөз сиксәнешәрне урганнар. Кич кайтыр алдыннан чүмәләгә җыя башлагач, уртанчы ул хахылдап көлеп, кычкырып җибәрде, ямьсез сүз катнаштырып:

— Мактаулы килен... —дип, бавы чишелгән бер көлтәне Гөлбану өстенә шаяртып ыргытты.

Һәммәсе кычкырып көлә башладылар. Гөлбану, хур булдым, адәм мәсхәрәсенә калдым бугай дип, комач кебек кызарды, шулай да тиз бирешәсе килмәде, тузган көлтәнең бавын барып тотты, оялыбрак күтәрде дә әйтте:

— Бу минем бау түгел! Менә минекеләр ничек. Мин борып аска тыгам, — диде.

Башта ышанмадылар, бүтән көлтәләрен китереп, бауларын чагыштырдылар. Алтынбай Гөлбану яклы булды, бу тузган көлтә яшь киленнеке түгел икән, кулы белән ясап күрсәтте. Алайса кемнеке була дип, тавыш күтәргәннәр иде, крестьян соры күзен кысты, кечкенә Фагыйләгә таба карады, төртте, ләкин баланы елатмас өчен:

— Анысын белмим, иллә-мәгәр яшь киленнеке түгел бу! — дип, сүзне икенче якка алып китте.

Шулай кызу эш кайнаган көннәрдә, Караюрганы телгә алып, Гөлбану ире Закирга ике тапкыр елап әйтте:

— Башкалар барып та кайтты инде, нигә мине генә мәхрүм итәсең?! — диде.

Бу сүз, гадәт буенча, яңа киленнең үз туган иленә, ата-аналарына кияве белән бер генә көнгә булса да кунакка барып, күрешеп кайтуы турында иде.

Ир үзенең анасы алдында атасы Шибайдан сорады, карт сүзсез күнде:

— Нәрсә, — диде, — бер синнән калмас, ата-баба йоласы, атыңны җик тә барып кайт, тик озаклама, эшнең тыгыз чагы! — диде.

Ләкин Сабира риза булмады, аерым алып, улын тиргәде:

— Оятың бармы, юкмы синең? Атаң хәл эчендә! Бүген-иртәгә үлем көтә. Анда, яланда, җыелмаган ашлыгың череп ята!.. Син яшь кәләш белән кунакка чабарга әйтәсең! Битең кая?! — диде.

Закир, аптырап, анасына карады:

— Соң бит, әнкәй, ил йоласы шулай бит инде. Ни эшлим? Башка киленнәр барып кайттылар, нигә мине генә мәхрүм итәсең дип елый бит...

Бу бәрелеш өстенә Алтынбай хатыны карт килен Фәүзия дә килеп чыкты, үзен тыя алмады, каенанасына чәнечте:

— Җә, харап инде! Бер кичкә барып кайтканда дөнья җимерелмәс! Синең комсызлыгың ул! — диде.

Йорт эчендә, уллар, киленнәр, балалар арасында яшь килен Гөлбануны аталарына кунакка җибәреп кайтару — үзенә бер эш булып күтәрелде, һәммәсе Сабирага каршы аякландылар.

Алтынбай көлеп әйтте:

— Тукта, мин бу убырлы карчыкны бер өйрәтим әле, — диде.

Ындырда чәчүгә дигән арышны сугалар иде, Сабираның тау астында, ерак урамда чирләп яткан сеңелесе Бәдриягә хәл белергә киткәнен карап торды да, Алтынбай әйтте:

— Закир, бар, тиз тарантаска күк атны җик, килен, син әзерлән, тиз бул. Убырлы карчык кайтканчы капкадан чыгып китәрлек булырга кирәк, — дип котыртты.

Гөлбануның һәммә нәрсәсе әллә кайчан әзер иде. Ашыгып, битендәге тузаннарын юды, тиз-тиз кершән ягынды, оек белән күн кәвеш, яңа күлмәк киде, шәл ябынды да төенчеген күтәреп йортка чыкты. Яшь җиңгиләрен болай яшереп кунакка җибәрү шатлыгыннан кечкенә кыз Фагыйлә дә, Миңлегалим дә бөтенләй канатланганнар иде.

Малай, капка башына менеп, карт анасы Сабира кайтмыймы дип карый торды. Ул арада үзенең йөрәгенә пычак чәнчелгән кебек:

— Закир абзыкай, тизрәк! Карт әнкәй ындырга җитте, — дип акырып җибәрде. Үзе бар көченә йөгереп барды да урам капканы тутырып ачты, тарантаска җигелгән атны шуңа таба китереп куйды.

Аннан-моннан киенгәләп Закир күренде, аны төрткәләп, этәреп арбага мендерделәр. Гөлбану, юрган белән мендәрен төзәтә-төзәтә, кечкенә каенесенә сокланып карады.

Чыбыркы шартлады, ат кузгалды, малай әче сызгырды, нәкъ менә шул вакытта тегеннән, ындырлар, азбарлар арасыннан арып, ахылдап, ачуыннан кара тиргә батып, зур буйлы Сабира карчык кайтып җитте. Күзе белән арбага ташланды, улы белән киленен таныгач, бөтенләй шашты, ни әйтергә белмәде:

— Алланың каһәре суксын! Муеныгыз астыгызга килсен, мәңге бәхиллегем юк!.. — дип тиргәнеп, җенләнеп, балаларын, улларын, киленнәрен каргап, һәммәсенә явыз догалар кылып, үзенең өенә, почмагына кереп капланды.

XXVII

Үзенең туып үскән иле Караюргага, әнкәсе Фәтхия карчыкка кайткач, Гөлбану бөтенләй яңадан туган кебек рәхәтләнеп, иркенләп китте. Җиң сызганып эшләгән яланнарын, җиләк җыйган тауларын, урманнарын, суга йөргән чишмә буйларын — һәммәсен сагынган, һәммәсен күрәсе килеп, йөрәге өзелгән иде. Күреп күзе туймады, сөйләшеп сүзе бетмәде. Анасы Фәтхия карчык белән, матур җиңги Мәфтуха белән елашып күз яше кипмәде, санаулы ике тәүлек гомер щулай яшен кебек үтте дә китте.

Матур җиңгә Мәфтуханың язмышы бик авырайган булып чыкты. Ир ирлеген иткән: «Балам юк, баласыз гомер — тозсыз аш», — дигән сылтау белән Мәфтуха өстеннән икенче хатын алган. Матур җиңгә әйтә: бик үткен, бик усал нәрсә, ди. Әле килгәненә ничә ай гына булды, менә шул арада да, ди, назлы яшь кәләш булып, матурланып, чытлыкланып, куштанланып, ирне кулга алып бетерде, ди. Менә, ди, мин хәзер ул йортта асрау хатын кебек булып калдым, бөтен кара эш, кара хезмәт минем җилкәдә, ди. Ул, ди, ак кулланып, назланып, минем өстән хуҗалык итә, ди, карынында дүрт айлык баласы бар, менә шул да булгач, хәзер, ди, ир алдында да бик кадере үсеп, артыграк борынын күтәрә

башлады, ди. Сүзенең очы-кырые булмады, матур җиңги күз яшьләренә бутап, Гөлбануның элекке сөйгән егете Лотфи турында да бик озак сөйләде. Ирләр, ди, бар да бер икән, берсенә дә ышанырга ярамый икән, ди. Менә синеке дә, ди, яратам, үләм, аннан башкага күңелем дә, күзем дә төшми, дип ант эчеп йөргән булган иде, ат койрыклары кистереп маташкан да иде. Аягы төзәлгәнне генә көтте дә, Шәрип ахунны яучыга җибәреп, Карамалыдан кибетче Гыйльман дигәннең кызын алды, шаулатып туй итте, хәзер менә бергәләп дөнья көтәләр, ди.

Гөлбану күңелен тыя алмады, Лотфи өйләнгән Карамалы кызы турында күп сөйләште: «Матурмы икән, эшкә уңганмы икән, әйбәт торалармы икән, яратышалармы икән?» — дип, кайта-кайта нечкәләп җентекләде.

Мәфтуха бу турыдагы гайбәтләрне күп белә иде, йөрәгем бушап калсын дип, һәммәсен чиште. Лотфи өйләнгән Карамалы кызының матурлыгын да, тегү-чигүгә, каюга уңганлыгын, бирнәсе искиткеч зур булганлыгын да әйтте, шуларга ялгап, буяуны үзеннән дә кушып, тагы:

— Бик яратышмыйлар бугай. Кыз санга сукмый, имеш, ди. Һаман, һаман үзенең аталарына кунакка китү ягын карый, имеш, анда барса, атналар буе ята, имеш, — дип өстәде.

Бу соңгы сүзләр Гөлбануның күңелендә әллә кайларда яшерелгән, әллә нинди билгесез кылларын тибрәттеләр. Нәрсәдер уянырга иткән, нәрсәдер баш күтәрергә теләгән кебек, шулай яратышмый китсәләр, талашып аерылышсалар, кем белә, әллә Ходай язган булса... дип, хәлсез генә өметкә таба юнәлде, ләкин шунда ук үзен-үзе кисте: «Әй, ходаем, кая инде! Кискән икмәк кире ябышамы?» — дип, үзенең өметен күңелсезлек белән каплады. Шулай да йөрәгенең әллә кайбер катлавында, әллә нинди ерак төпке бер почмакта, нindидер бер кечкенә, хәлсез җылы тойгы әз генә кузгалды, җанланып алды. Лотфи белән Карамалы кызы арасындагы хәлләр турында булган гайбәтне ул бар эш дип, яратышмыйлар икән дип ясап бетереп куйды, менә шул аның теге ерак яшеренгән хәлсез, ләкин җылы, якты тойгысына ризык бирде, нигез булды.

Анасы Фәтхия карчыкка үз тормышы турында начар яктан һичбер сүз әйтмәсә дә, болай серләшеп киткәч, Мәфтуха җиңгәсеннән яшерә алмады: «Мин ут эчендә көн итәм, каенанам котырган эттән болай яман, бәхетсезгә кояш карамый диләр. Инде менә каенатам да хәл эчендә ята, бүген-иртәгә үләр диләр. Ул үлсә, убырлы карчык минем башымны ашар инде», — дип, өзелеп-өзелеп елады.

Анасының бетмәс-төгәнмәс тәмле ашлары, майлы коймаклары, куе

каймаклары, симез бәрән итләре, тутырган тавыклары белән өзлексез сыйланды, сердәш җиңгәсе белән елашты да, Гөлбану тагы ире белән Бикьярга, каената йортына кайтты. Анда Сабира кара чырай белән әрләп каршы алды: «Оятсызлар, битсезләр, үләргә яткан аталарын, ялан тулы ашлыкларын ташлап, кунакта өчәр көн торалар», — дип, әче зәһәр телләнде. Ләкин үзе уйлаган, үзе әзерләнгән дәрәҗәдә йөрәген бушата алмады.

Закир белән Гөлбану тарантас белән өйгә кайтып төшкәндә, йортта ике арбага ат җигелгән, менә хәзер чыгып китәргә дип, ашыгыч төянәләр иде.

Бүген — беренче август икән!

Келәт алдында җигүле ат тора. Алтынбай егерме биш чиләк арышны арбага төягән; йөген ул агач шырпылар белән тегеп, аркан белән бәйләп бетереп бара. Аның улы Миңлегалим өч җир тырмасын, берсе өстенә берсен каплап, тешләрең югары таба каратып салган, ике атка мичәү җепләре белән эләктергән дә, үзе кола биясенең сыртына киез чикмән салып, менәргә әзерләнеп маташа. Болар аталы-уллы бүген арыш чәчеп, тырматырга баралар. Фәсхи, икенче бер арбага ат җигеп, чалгылар, тырмалар салган, ашарга катык белән икмәк, эчәргә су куйган. Карт килен Фәүзия дә, уртанчы юаш, йомшак килен Сыйтдика да шунда кайнашалар. Болар әле яңа җитеп өлгергән солыны чабып бәйләргә китәргә әзерләнәләр.

Закирлар кайтып төшкәч, иң элек кечкенә кыз шатланып, кычкырып җибәрде, яшь җиңгәсе Гөлбануга арбадан төшү белән килеп тотынды:

— Без солыга китәбез, әйдә син дә калма, — дип, аның тирәсендә яңгырады. Зурлар Караюрга кодаларның исәнлеген сорашканда, бу кечкенә кызга җиңгәсе тегеннән алып кайткан кечкенә тәмле бәлешне биреп тә өлгергән иде инде.

Алтынбай тулы зур йөк өстенә чәчү тубалын куйды, үзе менеп утырды:

— Җә, хәерле сәгатьтә булсын, чәчүгә китәм, — дип, атын кузгатты.

Миңлегалим, кола биясенә атланып, айгырны җитәкләп, тырмаларны җирдән өстерәп, атасына иярде.

Монда тавыш кузгалды. Сабира дөнья селкетеп тиргәргә тотынды. Кунак арбадан төшкәндә дә, өйгә кереп әйберләрен урнаштырганда да, чишенеп, яңадан эш киеменә киенгәндә дә туктаусыз әрләде, зәһәрләнде. Ләкин вакыт тар иде, киңәя алмады. Закир белән Гөлбану чабаталарын, ак җиңсәләрен, иске күлмәкләрен эләктерделәр дә йортка чыктылар. Җигелгән атка утырып, Фәсхиләр белән бергә яланга, солы чабып бәйларгә чаптырып, кычкырып көлешеп киттеләр.

Ана нарчык: «Миннән котыла алмассыз, кайткач, мин сезгә танытырмын», — дип, авыру карты янына керде.

Солы, борай, бодай урылып, чабып-бәйләнеп беткәнче арышны да чәчеп тәмамладылар. Шаулашып көлтә ташырга тотындылар. Бу арада хатыннар тары урды, борчак йолыкты, кибән куюдан бушаган бер яңгырлы көндә Алтынбай, үзе барып, кара бодайны чабып ташлады.

Ындырлар саф-саф тезелгән, очланып түгәрәкләнгән зур кибәннәр белән тулдылар. Ул арада чапкан карабодай кипте. Көн аяз чакта сугып калыйк дип, тагы һәммә атларны, арбаларны, карт белән карчыктан башка һәммә кешене алып, чиләкләр, капчыклар, көрәкләр, сәнәкләр, салам агачлары, чабагачлар төяп, яланга, карабодай сугарга куна киттеләр. Бу үзенә бер зур эш булды, һичкемгә кирәге күренмәсә дә, бер кеше кушмаса да, кечкенә кыз Фагыйлә дә бөтен йортны берьюлы аякка бастырган бу кызыклы куна ятудан читтә калмады, зурлар белән бергә барды, бергә шаулап, кычкырып кайнашты. Башка эш табылмаганда, карабодай сугучыларга бәрәңге пешерде, чәй кайнатты, табак-савыт юды. Карабодай быел тирә-якта бик харап уңды. Дисәтинәдән йөз илле потлап алган урысларны сөйләделәр.

Ләкин Шибай, саранланып, яз көне базарга чыкмады, күрәләтә йорттагы начар, чүпле орлыкны чәчтерде. Алтынбай ул вакытта да сукранган иде; ике көн азапланып, җитмеш поттан артык карабодай күренмәгәч, әле дә атасын кызганмый каты сүкте.

Бу — яланның азаккы эше иде.

Ике йөкне элекке көндә үк җилгәреп, тазартып, йортка илтеп бушаттылар. Калганын үзләре белән ике арба төяп алып кайттылар. Закир, кайтышлый күпер төбендә үк, тимерлектә эшем бар дип, төшеп калды, Фәсхи алгы аягының йөрәк итенә шырпы кереп, каты аксый башлаган кола бияне Намаҗан остага күрсәтергә алып китте; Сыйтдика килен, кайткач та, агач киледә тукмак белән иртәгә беленгә тары онлатырга тотынды, — шулай һәммәсе таралып беттеләр, йөкләрдәге карабодайны келәткә, өсәккә кертеп бушату бөтенләй Гөлбану өстенә калды.

Арыш потлык зур агач чиләкне алды, соскы белән чумырып, бер-бер артлы икене бушатырга да өлгермәде, урамга караган ак өйдән елауга ошаш бер тавыш килде, аның артыннан тәрәзә аркылы мулланың шомлы чалмасы күзгә чалынды, борын тавышы белән «Иннә лиллаһи вә иннә иләйһи раҗигун» дигәне ишетелгән кебек булып китте.

Балалар мал кагылмасын дип йөк янында карый калдылар. Гөлбану чиләген, соскысын арба өстенә куйды да кое төбендә бәрәңге юып торган карт җиңгәсе Фәүзиягә барды; курыккан, агарынган йөз, каушаган сүз белән:

— Җиңгәкәем, әткәйнең хәле начар бугай, анда елыйлар, — диде. Икесе дә,

эшләрен ташлап, урам як өйгә йөгерделәр.
Шул арада капкадан мәзин килеп керде. Алтынбай ашыгып кайтты, тиз-тиз атасы янына керде. Киленнәр, эчтә ни барын белә алмыйча, катып тордылар. Аннан акрын-акрын баскычка менеп, колакларың ишек ярыгына куеп тыңлый башладылар.
Кемдер эчтән төртеп ишекне ачты. Анда каенаналары Сабираның муллa-мәзиннән йөзен каплабрак елаганы күренде. Закир белән Фәсхи дә кайтты. Өйнең түренә, сәке өстенә, кыйблага йөзен каратып, Шибай картның гәүдәсен ипләп салдылар, күзләрен йомдырдылар.
Гөлбану түзмәде, аның йөрәгеннән нәрсәнедер кисеп, өзеп алдылар. Каенатаның үлеме белән бергә үз көне каралып киткәндәй тоелды; шунда, ишек төбендә, кешеләр алдында ук, күзләрен яулык чите белән сөртә-сөртә, үксеп елап җибәрде.

## XXVIII

Хәернисаларга шул төн ат менеп Миңлегалим барып кайтты, карт атасы үлгәнен хәбәр итте. Хатын шул таңда ук, ире Әфтәхне утыртып, Бикъярга килеп җитте. Шибайның өлкән кызы юаш, сабыр, эшчән Миңниса да сеңелесеннән калышмады. Болар икесе дә үги агалары Алтынбайның комсызлыгын беләләр иде. Әгәр барып өлгермәсәң, атайдан калган мирасның анысын яшерер, монысын качырыр, шулай коры кул күтәреп калырбыз дип курыктылар.
Беренче көннәр картны күмү мәшәкатьләре эчендә үтеп киттеләр.
Исән чагында сүзләр бик куе иде. Заманында зур дан тотты, кантун булган чакларында бик гөрләде. Башкортостанда кантунлыклар бетерелгәч тә, һаман урыс түрә алдында сүзе үтүчән булып калды. Дөрес, аның турында вакытында телләрдә күп ачы сүзләр бар иде. Башкорт картлары Шибайны:
— Бу килмешәк татар безнең майга симерә.
— Бу килмешәк татар безнең башкорт каны белән күбенә, — дип, шелтәләп әйтүдән курыкмадылар. Иделбай атлы башкорт карты:
— Син урысның үзеннән ямансың, син урыс губернаторының пычрак көрәгесең. Башкортны талыйсың! — дип, халык алдында ямьсезләп сүкте.
Моның өчен Шибай үч алмый калмады, Иделбай картны Себер җибәртте. Бу шагыйрь-җырчы адәм иде. Ерак Себер дә үз хәленнән моңланып, Шибайны чәнчеп бәетләр чыгарды. Бу бәетләр башкорт арасына таралды; киленнәр, карчыклар елап-елап моны укыйлар, Шибайны каргыйлар иде. Ләкин бара торгач яңа эшләр туды, икенче кешеләр турында бәетләр чыкты, элекке кантун Шибай үз ишләре эчендә исемле, көчле бер карт булып калды.
Ул яшь чагында калада алты-җиде ел зур бер мәдрәсәдә булган иде. Ләкин

гыйлемгә күңел куймады, күбрәк вакытын кала балалары белән күгәрчен очыртып уйнауга бирде, шунда аз-маз урысчага да шомарды. Үсә төшкәч, мәдрәсәгә килгән казакъ шәкертләре белән дуслашып, җәйләрендә Казакъстан даласында, Уел кебек ярминкәләрдә вак-төяк сату-алу белән дә азапланды. Егермегә җиткәч, бер бозыклыгы өчен мәдрәсәдән кудылар. Уку дәрте сүнгән иде. Бикьярга, атасына кайтты. Алдагы көзгә каралып, гаскәр хезмәтенә алынды. Анда усал, үткен солдат, соңра каты куллы ефрейтор була алды. Патша хезмәтен тутырып кайткач та, ул «кара халык — кара сарык» дип йөртә торган крестьяннар арасында бөтенләй югалырга риза булмады. Үзенчә киңрәк дөньяга чыгарга омтылды, шул исәп белән башкорт картларына, башкорт ил башлыгы олы атанларга дусланды. Бер ягы белән аз-маз мәдрәсәдән алган гадәтенчә, сүзгә осталыгы, шомалыгы белән муллалар арасында да дус-иш тапты. Урыс түрәгә туктаусыз хезмәт күрсәтә барды. Шулай терәкләнеп, баскычланып, күп мәшәкатьләр соңында килмешәк татар Шибай бервакыт Башкортостанда кантуннарның берсе булу дәрәҗәсен дә кичерде.

Үлем, җеназа өстендә бу озын, катлаулы гомернең тик ак яклары телгә алынды, иткән изгелекләре генә күтәрелде; әмма берәү дә ерак Себердә Шибайны сүгеп үлгән карт башкорт Иделбайның каргышларын, аның халык эчендә елап укылган ачы бәетләрен хәтерләмәде, боларны үлем каплады. Үлем артыннан, калганнар өчен дә мал кайгысы баш күтәрде.

Теге, Алтынбай безне мирастан коры калдырмасын дип, куркып килгән Миңниса белән Хәерниса кайдан сүз ачарга белми, җеназа үткәч, кире кайтып киттеләр. Шибайның өче, җидесе дә бик яхшы, бик тыныч үтте, тик менә җидесен үткәрергә дип җыелган мәҗлес таралгач каладан бер кәгазь килеп төшүе генә бераз кытыршылык тудырды.

Закирны өйләндергәндә бирелгән өч йөз сумның яртысы каладан бурычка алынган булган икән, карт, кул куеп, кәгазь дә биргән икән. Ничек тә хәзергәчә шуны түләми кичектереп килгән. Үзе үлү белән бу калкып чыкты. Ун көн эчендә түләргә сорыйлар, булмаса, Шибайдан калган малны килеп язачаклар.

Алтынбайның каны бик кайнады. Закир өчен алган, анда безнең эшебез юк дияргә дә чамалады. Ләкин егет абзасының авызын җиңел каплады:

— Син өйләнмәдеңмени? Синең хатының өчен бу йорттан мәһәр түләнмәдемени?..

Зур ызгышка китмәде, сүз шунда киселде. Бу йөз илле сум бурычны үз вакытында түләү өчен бер ат, йөз пот бодай, еллаган чуар үгез кереп китте.

Инде котылдык дип, иркен суларга өлгерә алмадылар, Исәнбикә болынының кулдан ычкыну куркынычы алга килеп басты. Бу кечкенә тугай өчен

башкортлар Шибайны болай да шелтәлиләр: «Без сиңа җир сатканда илчелек, тылмачлык кылганың өчен берничә елга файдаланырга гына бирдек, син аны үз исемеңә мәңгегә беркеттең, үзеңнеке ясадың», — диләр иде. Шулай да башкорт җәмәгатьләренең үз юлбашчылары аркылы кул куеп, һәммә җирдә ныгытылып өлгергәнгә, кире ала алмаганнар иде. Хәзер менә шуның бер уңайсызрак ягы бәреп чыкты.

Бикьярның күбе кебек, Шибай да көязләнергә, киңрәк торырга ярата иде. Түшәгенә күрә аягын сузуны оныта торган иде. Акча бик кирәк чагында бу Исәнбикәне салып, крестьян банкысыннан бурычка алган булган икән. Бу да түләнмәгән икән. Хуҗа вафат булгач, мирас бүленә башлаганчы дип ахры, бу турыда да кәгазь килеп төште. Моның хәбәре бик зурайды, мужиклар:

— Бу йорт черек нигезгә салынган икән, карт үзе кабергә керүгә җимерелә башлады, Исәнбикә дә китә икән, барлык малын да язалар икән, — дип чәнчеп сөйләделәр.

Сүз барып ирешү белән, Шибайның кияүдәге кызлары — Миңниса белән Хәерниса тагы, ат җиктереп, кечкенә улларын утыртып, Бикьярга килеп җиттеләр. Тарала торган малдан үз өлешләрен эләктереп калырга тешләрен кайрап, Алтынбай белән талашырга әзерләнделәр. Ләкин эш бер Алтынбайда гына түгел иде. Закир да, уртанчы ул аңгыра Фәсхи дә бу бай үләнле, кадерле болынны кулларыннан ычкындырырга теләмәделәр, моңарчы килгән кебек, һаман файдалану ягына тешләре, тырнаклары белән тотындылар. Тагы бераз ашлык сатарга, зур чуар сыер белән бер ун сарыкны базарга чыгарырга чамаладылар. Ләкин ике кыз моңа якын килмәде. Җир, урман, болын кебек нәрсәләр барыбер ирләргә генә китә инде, читтә, кияүдә булган Миңниса да, Хәерниса да моңардан бертөрле дә табыш күрә алмыйлар. Әмма, шул Исәнбикәне коткарам дип, ничаклы мал сатмакчылар. Боларга бит кызларның өлеше дә кереп югала. Кызларның тияре кими. Бу турыда сүз, талаш, ызгыш, үпкәләш озакка барды. Хәерниса үзенең анасы Сабирага да каты әйтте:

— Син үзең монда торганга улларыңны яклыйсың. Безне көпә-көндез, кеше алдында таларга әйтәсең, — диде.

Староста килгән иде, Хәерниса йөзен аз-маз каплап башлады, кызгач, яулыгын бөтенләй ачып җибәрде:

— Сез барыгыз да бер, барыгыз да ирләрне яклыйсыз, — дип әрләште.

Алтынбайның бу турыда бер аерымрак исәбе бар иде. Әгәр ага-эне риза булса, ул бурычка акча тапмакчы, Исәнбикәнең бирәчәген үз кесәсеннән генә түләп, болынны бөтенләй үзенеке итмәкче, ялгыз үзе хуҗа булмакчы иде. Бармагы белән санап-санап, ике энесенә моны озаклап сөйләде. Ләкин болар һичнәрсә

аңламадылар, агаларына:

— Син безне утыртырга әйтәсең, — дип сүгенеп бәйләнделәр.

Арага староста да катнашты:

— Сезгә барыбер түгелме, бурыч өчен кулыгыздан алалар бит! Алтынбайда калса, сезгә ни зыян? — диде.

Ләкин Закир белән Фәсхи бу эштә үзләренә зыян юклыгын, үзләре отылмавын һичбер төрле төшенә алмадылар. Закир бер сүзне кабатлый бирде:

— Нәрсә син болай?! Исәнбикә дә синә! Бары да синә! Бөтен әйберне үзеңә тартасың, безгә ни кала?.. — диде.

Болар шулай талашып берничә көн югалттылар, түләү вакыты үтте, Исәнбикә, болардан ычкынып, банк аркылы, әле былтыр гына башкорт җиренә утырган хахуллар кулына керде. Алтынбай моның өчен әрнеп бетә алмады, ләкин болын киткән, башыңны ташка орсаң да кире кайтмый!

Исәнбикә артыннан калкып чыккан тимер сабаннар, машиналар бурычы бигрәк тә Хәерниса белән Миңнисаның ачуын кабарттылар. Ике кыз бусын бөтенләй күктән төшкән бер бәла итеп карадылар. Шибай үз заманында башлап тимер сабан кертте. Җилгәрү машинасы алды. Картлар аны ул чакта бу яңалыклар өчен, ата-баба йоласын бетерәсең, элекке сабаннарны ташлыйсың дип, рәнҗеп, тиргәп бетерделәр.

— Ансыз да Алланың каһәре ява... Яңгырлар юк, елдан-ел ачлык... — диделәр. Кытлыкны шул яңа машиналардан күреп, кире кудырырга да маташтылар.

Ләкин тиз өйрәнделәр. Элекке дүрт атлык агач сабаннар, чирәм ачканда алты ат җигә торган төрәннәр урынына ике ат уйнатып йөрткән җиңел тимер сабанга мужиклар үзләре дә тиз күнектеләр. Шибай карт бу эшләре белән үзенең койрыгын бераз бәйләп киткән икән. Земстводан бу сабаннар, машиналар өчен сиксән сум бурыч түләргә кәгазь төште. Вакытында түләнмәсә, тагы малны язарга дип, кот очыралар. Тагы шул үзара бүленергә тиешле атларга, сыерларга барып терәлә. Тагы өлеш кими.

Кызлар моңа чәрелдәп бәйләнделәр: «Сабаннарның безгә кирәге юк, алып китә бирсеннәр, уртак өлештән бу бурычны түләргә без гомердә дә риза түгелбез», — диештеләр. Талаш, үпкәләш тагы кызды. Алтынбай үзенең сеңелләре өстенә акырып килде:

— Ул кирәкми, бу кирәкми! Нәрсә генә кирәк?! Ул сабаннарның миңа да поты бер тиен! Менә дигән яңасы ундүрт сум — барам да киләсе көзгә түләргә алам! Сезгә менә аяклы малны санап тоттыр да тәртә янына бәйләп җибәр! Ай-һай, акылыгыз алтын икән! — дип, Хәерниса белән Миңнисаның авызын капларга, бу сабаннарның түләвен уртак мирастан түләтергә өндәде.

Анның иң курыккан нәрсәсе дә шул аяклы малны таратып бетерүгә бәйләнгән иде, ахыр җиңеп чыкты. Земство бурычларын түләүдә ирләр ягы өстенлек алды. Алтынбай болай куйды:

— Ашлыкның хакы юк, әле дә йөз пот бодайдан колак кактык инде, ике сыерны сатмый булмас, — диде, кайсылары икәнен атап әйтте: — Ак тукал белән симез кара кысырны чыгарсак, капларлар, — диде.

Бу сүз Хәернисаның йөрәгенә бәрелде. Ул бар күңеле белән шул куе сөтле зур ак тукалга багланган иде; агасының сүзенә чәнчелеп, урыныннан ук торды, нечкә, чәрелдек тавыш белән ашыгып-ашыгып, кайта-кайта зәһәрләнде:

— Иштең арыш чумарын: йортның иң яхшы нәсел сыерын базарга чыгаралар димени? — дип кызып, чәрелдәп китте.

Сабира да аны яклады, булмас, тукалны бирмәм, диде. Алтынбай энеләрен сыерларга да, хатыннарга да каршы аякландыра алды, көрәш ачык билгеләнде:

— Ул сыерларны кызгансак, алайса базарга актык атларны чыгарабыз. Шулаймы, Закир? — дип, энесенең-күзенә карады.

Хатыннарга сыер ничаклы якын булса, ир крестьянга ат мең тапкыр якынрак, кадерлерәк иде. Закирның күзе томаланып китте, миенә кан йөгерде, үзен белми сикереп торып, йодрык белән сәке читенә сукты, хәзер кыйнап ыргытырга әзер торган төс белән апасы Хәернисага йотылды:

— Син нәрсә? Закир атсыз калсын дисеңме? Мине бәләкәй арба тартып йөри торган хәерче дип beләсеңме? Әйт, мине җәяүле хәерче итмәк буласыңмы?

Ирләр белән хатыннар, атлар белән сыерлар арасында озак барган бу ызгышның, көрәшнең азагы — атларның җиңүе белән бетте. Земство бурычларын каплар өчен йортның иске нәселле ак тукал белән кысыр калган симез караны мөгезләреннән бәйләп базарга чыгардылар. Хәерниса белән Миңниса өчен дә, тукалны төп йортта калдырып, үзе савып рәхәтләнергә өметләнгән ана карчык Сабира өчен дә бу ике сыерның йорттан чыгып китүләре һичнәрсәгә чагыштырылмаслык зур кайгы, зур ятимлек булып төште, өчесенең дә күзләре яшьләнде.

## XXIX

Бу талашларның кызу көннәреннән берсендә, шимбә иртә белән, Шибай йортының урам як көнчыгыш почмагына иске өй бүрәнәләре, идәннәре, түшәмнәре төялгән дүрт арба килеп туктады. Алтынбай егетләрчә җиңеллек белән кереште, арбаларны китерешкән мужиклар аңа ярдәм итештеләр. Урам як читәнне алып ыргыттылар, бик аз гына нигез ясадылар да уңган кул белән кечкенә дүртпочмак өйне күтәрделәр. Күргән күреп калды, күрмәгән юк: кичкә, көтүләр кайтыр вакытка инде бу кечкенә өйнең кыегы утыртылды, нечкә генә

булса да, салам белән дә ябылды, ишеге, тәрәзәсе, — һәммәсе урынына куелды. Түбән оч Вәли дигән бер фәкыйрь күп еллар инде Уралда эшли иде. Монда өе бикле тора иде. Шул быел кайткан да, бөтенләй күчеп китәргә булганга, юк хакына өен Алтынбайга сатып киткән. Шибайның көнчыгыш почмагына килеп утырган менә шул иде.

Мондый бер башсызлыкны күрүгә Сабираның мие әйләнде. Алтынбай аңа үги тия. Алар гомер буе эт белән мәче кебек әрләшеп яшәделәр. Утыз биш ел буенча берберенә әйтмәгән начар, пычрак, оятсыз сүзләр бик аз калды. Әмма ул оятсызның бүгенге эше инде Сабираның башыннан аша китте. Әле атасының кабер туфрагы суынып җитмәгән, әле үзара мал бүлешү турында бер сүз дә юк, ул оятсыз әллә кайдан тавык кетәге кебек өйләр таба, әллә кемнәр белән монда китерә дә сала. Анайдан сорау юк, энеләре белән киңәшү юк. Бу ни эш бу?

Сабира, менә шулай җенләнеп, иң элек муллага йөгерде. Яулык чите белән авызының ярты ягын гына каплады да:

— Хәзрәткәем, ни эшлим? Мине талыйлар... — дип елап, каргап тиргәнде. Бер ярдәм сорады.

Аллаяр мулла куркак адәм иде. Мәхәлләсендә Шибай урынына калачак Алтынбай белән карулашырга бер дә теләмәде, алай-болай тартты, кат-кат тамак кырды да бутабрак әйтте:

— Бу инде, — диде, — ягъни мәсәлән, дөнья эше, имамнарга мондый эшләргә катнашырга мөфти хәзрәттән әмер юк, — диде.

Елап килгән карчык үзен талаган үгигә каршы бернәрсә дә таба алмады.

Ләкин Сабира җиңелмәде, елап, әрнеп, старостага йөгерде. Аны азбарда атка бутау әзерләп йөргән җирендә тотты, шул ук сүз белән башлады:

— ...Ни эшлим? Мине талыйлар... Көпә-көндез талыйлар... — дип елап, каргап тиргәнде... Аңардан да булышлык көтте.

Староста бу эшне алдан белә иде. Башы әйләнгән усал карчыкны бераз тынычландырырга теләде, Шибай тирәсендәге ызгышлардан җаны өшегәнгә, боларны килешү ягына сөрде:

— Сабира түти, — диде, — юкка йөрисең болай: үз улың бит, үги булса да үз улың бит. Үзара гына килешеп бетерү кирәк иде, — диде.

Ләкин ана моңа якын килмәде, каты телләнде: «Син дә аны яклыйсың, сез ирләр барыгыз да бер-берегезне яклашасыз», — дип рәнҗеп, старостаны үз йортына, яңа салынган кечкенә тавык кетәгенә өстерәде; аның белән тагы күршедән ике аксакал картны да алып килде. Исәбе — шул старосталар, картлар алдында ук ул хәерче тавык кетәген үз туфрагыннан алдырып, кире арбаларга , төятеп җибәрү иде. Юл буенча карганып: «Мин өйдә юк чакта

эшләп өлгергән, аңа шайтаннар булышадыр», — дип рәнҗи барды.

Болар килгәндә Алтынбай үзенең күчереп утырткан кечкенә өенең ишек тупсасына актык кадагын кагып тора иде. Чүкечен ташламый, түбәнчелек белән каршы барып, сәлам алды. Ана карчыкны көтмичә, үзе үк җәберсенгән, рәнҗетелгән тавыш белән сүз ачты:

— Менә, — диде, — ил картлары ни әйтсә — мин шуңа ризамын. Әгәр бу җирдә элек сигез сажинлык тыкрык юк иде дисәгез, өемне җимерәм дә башка урынга, авыл читенә күчереп салам; әйтегез, картлар: монда элек тыкрык бар идеме, юк идеме?..

Крестьян менә шул яктан китереп бәрде. Сабира карчык бөтенләй шашып калды. Ләкин староста да, ике аксакал да моны яхшы беләләр: элек монда тыкрык иде. Кантун чагында Шибай ул тыкрыкны бикләтте дә, сигез сажинны үзенә кушып, йортын киңәйтте, авыл артындагы Үзән елгага төшәр өчен бераз арырактан икенче тыкрык ачтырды. Тыкрыклар — җәмәгать туфрагы саналалар. Боларга берәүнең дә иялеге булмый. Шулай булгач, Алтынбай үзенең атасыннан мирас калган җиргә түгел, җәмәгать туфрагына өй салган булып чыга... Бу сигез сажинга кызларның да, улларның да, ана карчык Сабираның да хакы керми. Бу инде җир белән мие әйләнеп беткән һәрбер крестьянга үзенең аягындагы чабатасы кебек билгеле бер нәрсә. Сүз бу якка таба борылгач, Алтынбай канатланып китте:

— Яшем иллегә бара. Атайның дөньясын менә шул җилкәмдә күтәреп килдем. Дүрт ел патшага солдат булдым... Ил белән бергә ясагын түләп киләбез... Сез, картлар, инде миннән сигез сажинлык тыкрыкны да күпсенәсезме? Алайса миңа башка җирдән урын бирегез... Мин килмешәк түгел, мине авылдан куа алмассыз! — диде.

Ике аксакалның юашрагы кул селекте, кипкән гырылдык тавыш белән:

— Җә, нәрсә урын тагы?! Китереп салгансың, шул тыкрыкта утыра бир, өлешеңә чыккан көмешең, бик әйбәт! — диде дә китү ягын карый башлады.

Карчык елап җибәрде.

Картлар белән староста китеп кенә өлгергән иде, өсте-башы бөтенләй ап-ак онланып, Закир зур йөк белән кайтып төште. Ул Бикьяр белән Караюрга арасында Үзән елгага салынган су тегерменәнә кичә үк егерме биш пот арыш алып киткән иде. Бер җирдән буа ерылды, ташлар эшләми торды, шуның белән болай озак кичегеп калды.

Ул капкага килеп җитү белән, аптырап: «Бу ни эш? Монда нинди тавык кетәге китереп утыртканнар тагы?» — дип, гаҗәпләнеп карады. Аңа каршы Алтынбай килеп чыкты, түбәнчелекле, хәйләле тавыш белән энесенә әйтте:

— Менә, Закир туган, хәерле булсын дип әйт, төп йорт төпчекләргә кала диләр, безгә инде менә шундый тавык кетәге дә ярар, — диде. Кемнән ни хакка алуын сөйләп бирде.

Закир эшнең кая таба барганын сизеп җитмәде, сүз уңаеннан әйтеп куйды:

— Алайса төп йорттан синең өлешең шуның белән бетә инде! — диде. Йөзенә тынычлык чыкты.

Алтынбайга, әйтерсең, инә белән чәнечтеләр. Ул баскан җирендә сикереп куйды, мәсхәрә катыш ачу белән энесенә карады:

— Ничек бетә? Ничек бетә? Кызык икән! Сигез сажин җәмәгать тыкрыгын алу белән мине ничек атай мирасыннан мәхрүм калдырмак буласың?.. Ә?.. Мондый закон бармы? Шәригать бармы? Мин һәммәсен актарырмын!.. Мин ясак түләмәдемме? Мин солдат булмадыммы?.. — Шулай бер-бер артлы тупырдатып, тезеп, Закир өстенә килде.

— Менә кызык! Син булсаң, бүтәннәр булмаганмыни? Фәсхи абзый ничә ел йөрде!

Келәт алдында онлы йөкне бушата-бушата ике туган каты әрләштеләр. Актык чиләкне өсәккә кертеп аударганда Закир кисеп әйтте:

— Мин башкасын белмим... Аерылып чыктың, өлешең бетте. Калганы бары да безнеке! — диде.

Алтынбайның күзләре маңгаена менде, энесе өстенә этәчләнеп омтылды, ләкин моның кыйнап ташлавыннан шүрләде дә урамга чыгып йөгерде. Закир атын туарып, эш бетәргәнче Алтынбай чалмасы-чапаны белән Аллаяр мулланы мирас бүләргә дип җилтерәтеп алып килде. Йортта киленнәр, ага-энеләр арасында гаҗәп бер шау-шу күтәрелде. Сабира карчык, мине талыйлар дип, башын югалтты, һәммәсе урам як өйгә керделәр, Гөлбану белән уртанчы килен юаш Сыйтдикадан башка хатыннар да шунда мал бүлгән җиргә йөгерделәр.

XXX

Мулла үзенең «Фәраиз»[10*] китабы, кара, каләм, кәгазьләре белән корАлланып килгән иде. Алтынбай бик түбәнчелек белән сүз башлады:

— Хәзрәт, — диде, — менә сезнең каршыгызга хөкемгә утырабыз инде, ага-эне талашып хур булдык бит!.. Шәригать ни әйтә — баш өсте, шуңа ризабыз, — диде.

Аллаяр мулла, әзерләнгән чәйне эчеп, майлы коймакны ашый-ашый, акрын гына сүзгә тотынды, элек эшнең ничек икәнен аңлатырга тырышты:

— Тәкъсим тәрикә вакытында[1], — диде, — әүвәлән, тәҗһиз, тәкфин

[1] *Тәкъсим тәрикә вакытында* — калган малын бүлгән вакытта.

мәсарифлары[1] үтәлер, дип әйткән шәригать, — диде. — Аннан соң, — диде, — мәетнең карызлары, ягъни мәсәлән, үзе сәламәт чагында алып та, үтәлмәгән бурычлары әда кыйлыныр[2] дип әйткән, — диде. — Вә салисән[3], — диде, — мәетнең гакылы сәлим, ирадәсе камил[4] хәлендә әйткән васиятләре әда кыйлыныр дип әйткән, — диде. — Вә рабиган[5], — диде, — мәетнең варислары бәйнендә мабәкыяне тәкъсимгә шөруг иделер[6] дип әйткән китап, — диде.

Бу сүзләрдән һичкем һичнәрсә аңламады. Мәхрүм калмас өчен куна-төнә анасыннан китми яткан Хәерниса бөтенләй каушап китте. Мулланың сүзләрендә үлекнең кияүдәге кызларына күпме тиюе турында бер сүз дә булмагач, шулдыр, Алтынбай абзый бу хәзрәтне майлап керткәндер дип куркынды, чаршау артыннан чыкмыйча, кыза төшеп, нечкә, чәрелдек тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Хәзрәт, бу ни эш? Кияүдәге кызларга бер әйбер дә тимимени шулай? — диде.

Аллаяр мулла бу сорауга колак салмады, бертөрле үлек тавыш белән үз сүзен суза бирде:

— Имди әгәр, ягъни мәсәлән, мәрхүм вә мөтәвәффа[7] Шиһабетдин бине Таҗетдин Тамчигуловның варисларына килсәк, ягъни мәсәлән, буйлә булыр: әүвәлән, — ибеннәр[8], болар саләсә булыр, ягъни өч; дәхи — зәүҗә[9], бу вахидә[10]; аннан бәнатлар — ягъни мәсәлән, кызлар — болар иснәтәйни[11] булыр... Бәс, мәрхүм вә мөтәвәффа Шиһабетдин бине Таҗетдин бине Тамчигуловның тәкъсим тәрикәсендә тәкфин, тәҗһиздән, әдаи карыз вә әдаи васияттән мабәкыяне тәкъсим итәчәк булсак[12], җәмгысе өч ибен, ягъни ул, ике бинт, ягъни мәсәлән, кыз, бер зәүҗә мираска иштирак кыйлгайлар...[13]

Алтынбай бу соңгы сүзләрдән калтыранып китте. Ни мәгънәдә икәнен

---

[1] *Тәҗһиз, тәкфин мәсарифлары* — юу-күмү чагымнары.
[2] *Әда кыйлыныр* — түләнер.
[3] *Салисән* — өченчедән.
[4] *Гакылы сәлим, ирадәсе камил* — гакылы сәламәт, ихтыяры камил.
[5] *Рабиган* — дүртенчедән.
[6] *Варислары бәйнендә мабәкыяне тәкъсимгә шөруг иделер* — шуннан соң калган малны варислары арасында бүлү эшенә керешедер.
[7] *Мөтәвәффа* — вафат булган, мәрхүм.
[8] *Ибеннәр* — уллар.
[9] *Зәүҗә* — хатын, ир хатыны.
[10] *Вахидә* — бер.
[11] *Иснәтәйни* — ике.
[12] *Тәкъсим тәрикәсендә тәкфин, тәҗһиздән, әдаи карыз вә әдаи васияттән мабәкыяне тәкъсим итәчәк булсак* — мирас малын бүлү вакытында юу-күмүдән, бурычларын түләгәннән, васиятләрен үтәгәннән соң калган өлешен бүлү эшенә керешәчәк булсак.
[13] *Мираска иштирак кыйлгайлар* — мираска катнашалар, ягъни мираска хаклары бар.

төшенмәде, бу юньсез ак баш мулла атай малыннан тагы берәр нәрсәгә өлеш алмакчы түгелме икән дип коты очты. Еларга да, сугышырга да әзер торган тавыш белән сорады:

— Хәзрәт, — диде, — ул «җәүҗә» дигәнең нәрсә тагын? Безгә мал болай да аз бит, — диде.

Мулла, аз гына да борчылмыйча, шул элекке үлек, тонык сүзләре белән җавап бирде:

— «Җәүҗә» түгел, «зәүҗә» дим, «зәүҗә» дим. Мәетнең, ягъни мәсәлән, үлекнең хатыны дигән сүз була, менә синең үги анаң Сабира була, — диде.

Крестьянның җилкәсеннән авыр тау төште: — Кеше куркытасың, хәзрәт; башта ук шулай үзебезчә генә әйтсәң ни була соң, — дип, маңгаеннан салкын тирен сөртеп алды, тагы, гаҗәп бирелеп, мулланың сүзләренә йотылды.

Аллаяр тагы башлады:

— Әүлад[1] булгач, зәүҗәгә сөмен, ягъни мәсәлән, сигездән бер тия, — диде.

Алтынбай хәзер генә әйтелгән сүзне онытты:

— Бу «җәүҗә» дигәнең кем була әле? — дип кабатлады.

Мулла әйтеп бирде. Аннан икенчеләргә күчте: — Ибеннәр — гасабә[2] булалар, ягъни мәсәлән, зәүҗә белән бәнатлардан[3] күпме мал калса, шуны үзара тигезләп бүлешәләр, — дип бетерде.

Алтынбай урыныннан ук сикерде, кечкенә соры күзләрендә канлы ут ялтырады.

— Ничек алай ул, хәзрәт? Кызлар минем җилкәмне кимереп үсте. Аларга туй итәбез дип минем җилкәләрем чиләнде. Син нәрсә, әллә мужикка мал бит сыйпау белән килә дип беләсеңме? Мин маңгай тирем белән кырык ел көн-төн эшләдем. Хатыным унсигез ел баш күтәреп якты көнгә карый алганы юк, көн эш, төн эш! Ун яшьлек кызым Фагыйлә бар. Инде ул да менә өченче ел утаудан, урактан калганы юк. Бозауга ул йөгерә, яз көне сазда каз бәбкәләрен ул карый... Боларны исәпкә тыкмыйсыңмени?.. Улым Миңлегалим уникегә җитте. Зурлар белән бер уңайдан печән җыя, урак ура, тырма тырмата; ат караган, ат белән кунарга йөргән ул!.. Боларны кая ташлыйсың?.. Имеш, әле кичә генә хатынын китереп эшкә кушкан Закирга да бер, Алтынбайга да бер!.. Минем хатыным, балаларым кем өчен маңгай тирләрен түктеләр?.. Бу гаделлекме? Юк, мин риза түгел...

Мужикның хәзер сугышып үләргә әзер торган ачулы тавыш белән әйтелгән бу сүзләре мулланы куркыттылар. Ул берничә аять, хәдис укыды, «Фәраиз»дан

---

[1] *Әүлад* — уллары.
[2] *Гасабә* — ата ягыннан булган туганнар.
[3] *Бәнатлар* – кызлар.

гарәпчә җөмләләр китерде.

— Бу, — диде көфер була, син Аллаһе Тәгаләнең әмеренә итагать кыйлырга[1] теләмисең. Китап аны мәгъсияте көбра[2] дип әйтә, шәригатьнең әмере менә шул. Әгәр инде шәригать кушканга, ягъни мәсәлән, риза бул-масаң, нәгузе биллаһи[3], урыс каршына, закунга барырсың, — диде.

Крестьянның сакаллары дерелдәде, биленнән кысып бәйләгән чикмәне үзен кыскан кебек булды; боларны салып ташлап, камзулдан калды, яман өметсез, ачулы гайрәт белән мулланың каршына, борын алдына килеп, әллә кемгә кулын бутап әйтте:

— Ходай үзе сакласын, хәзрәт! Инде кяфер каршына бармасак иде, — диде. — Шулай да ни эшлисең соң? Син җәбер итсәң, урыска, кяфергә, закон алдына да барырга туры килер шул, хәзрәт! — диде, үзе кисеп өстәде: — Урыска түгел иблиснең үзенә дә барырмын, иллә-мәгәр маңгай тирем белән тапкан бер тиенемне дә кешегә калдырмам, калдырмам дигәч калдырмам... — дип, сәке читенә зур, кызыл йодрыгы белән каты китереп сукты.

Аның болай гайрәтләнүе Фәсхине аякка бастырды. Бу аңгыра крестьян мулланың сүзләрен бер дә юньләп тыңламады; тыңласа да аңламады, ара-тирә калгып йокыга китеп, борын тишекләрен сызгыртып утырды. «Бүләрләр әле, минем өлешкә кем тисен? Язганын алырмын!» — дигән бер тыныч, ялкау уй аның миен каплап тотты. Ләкин мулланың сүзләреннән юнь чыкмагач, ул күзен ачты. Алтынбайның гайрәте белән кинәт кабынды, абзасы боларның һәммәсенең өлешен үзенә алмакчы бугай: «Бу комсыз мине утыртты бугай!» — дигән куркыныч аның канын кайнатып җибәрде, кинәт:

— Син нәрсә, ананны... — дип, иң начар сүзләр белән сүгенде дә кötелмәгән борылыш ясады: өстендәге чикмәнен, башындагы ак киез эшләпәсен ыргытты, җиңнәрен сызганды, шунда, сәке аягы янында яткан зур үткен балтаны алды да:

— Син ананны... комсыз... гомер буе минем җилкәмә атланып йөрдең... Инде атай үлгәч, минем актык өлешне тартып алырга әйтәсеңмени!.. — дип, барлык җыелган халык алдында агасы Алтынбайның бугазын кисәргә омтылып ташланды.

Аны Хәерниса белән Закир, Сабира белән Миңниса, аягына, кулына асылынып, көч-хәл белән тыеп калдылар. Күзен кан басты, каты тормыштан сөягенә ябышып каткан саргылт-карасу йөзенә ерткыч төсе чыкты, өстендәге керле күлмәгенең җиңнәре, аркалары ертылып, керле тәне бәреп калды. Ямьсез

[1] *Итагать кыйлу* — буйсыну.
[2] *Мәгъсияте көбра* — зур гөнаһ.
[3] *Нәгузе биллаһи* — Алла үзе сакласын!

сүгенде дә, зур кара-кызыл каты кул йодрыгы белән ишек яңагына суга-суга, яман ерткыч тавыш белән Алтынбайга акырды:

— Кара аны! бер бөртек саламымны артык алсаң да, агай димәм, көпә-көндез өеңә басып керермен... Хатын, бала-чагаң алдында балта белән суярмын! Бел! — диде, үзе, кызып-дулап, чыдаша алмый, зур гәүдәсе белән ава-түнә чыгып китте.

Мулланың куркудан каны качты. Башын исән алып китүдән өмет өзде. Калтырап, китабын, кәгазь-карасын, каләмен букчасына кире тыкты да, берәү белән дә исәнләшмичә, тиз-тиз чыгып тайды.

Монда, өйнең астын-өскә күтәреп, ага белән эне, ана белән ул, ир белән хатын талаш, ызгыш уты эчендә калдылар. Мулладан тартынып тышта торган Гөлбану белән юаш килен Сыйтдика да шул тавышка кереп кушылдылар.

XXXI

Уртанчы ул Фәсхи кул сугышына көчле булса да, исәп-хисап ягына бик сай иде. Талашып чыкты да, старостага барып, үзенә урын сорады. Авыл читендә фәкыйрьләр, атадан куылган, аерылган яшьләр арасында бирделәр. Шунда, хәзергә ярар дип, читән алачык үрде; күршенең атын-арбасын алды да, берәү белән дә киңәшмичә, Шибай карт йортыннан зур амбар белән нечкә бүрәнәле сарык азбарын сүтеп ташыды. Бер буй читәнне каерып алды да, өстерәп китереп, алачыгы янына казыклар кагып, терәп утыртты. Ындырдагы дүрт кибәннең иң зурысын шунда, яңа урынга илтеп өйде.

Аның төп исәбе — калган өч атның берсен эләктереп калу иде. Нукта алып, азбарга шул исәп белән кергәндә, Алтынбай аның якасыннан тотып туктатты. Пычакка-пычак килеп, икесе йорт уртасында, күршеләр күз алдында сугыштылар. Алтынбай яланбаш, ертылган күлмәкләре, муенга асып бәйләнгән кулы, канап шешенгән бите белән урамга чыгып акырды:

— Караул! Малымны талыйлар!.. Үземне суялар!..

Тагы халык җыелды. Яралы крестьян битендәге канын ыграк таратты, асылган кулын бөтенләй сынган, менә хәзер өзелеп төшәргә тора кебек салындырып, күлмәк ертыкларын җилләндереп, җәмәгать алдына чыкты:

— Менә, картлар, сез ни әйтсәгез — мин шуңа риза буламын, — диде, санап китте: — Хатын артыннан кара бия килдеме? Килде. Ул бия атай йортына ун ел хезмәт иттеме? Итте. Аннан ике колын асрады. Берсе. — хәзерге кола бия, берсе — кара айгыр! Менә бу минем хатынның малларымы, түгелме? Картлар, нигә мине болай көпә-көндез талатасыз?

Фәсхи моңа аптырап катты, башында кайнаган ачулар эченнән бер кирәкле уй килеп чыга алды:

— Ә, алаймы? Минем хатын артыннан килгән тай нәрсә? Аны атайдан калган бурычны түләргә саттырып җибәрүче син түгелме? Күк бозау кайда? Күк бозау — күк үгез булды. Еллаган үгезгә хак шәп дип мактап, базарга син чыгармадыңмы? Безнекен атай бурычларын түләргә саттырып бетердең... Үзеңнекеләрен — бу минем хатынныкы дип азбарга биклисең... Муеның астыңа килгере... — диде дә агасының бугазыннан алды.

Сугышырга бирмәделәр. Ләкин талаш зурга китте, бер яктан Сабира, бер яктан Алтынбай: «Мине талыйлар!» — дип кычкырындылар. Ләкин җәмәгать тә түзә алмады. Хатын артыннан килгән мАлларны Алтынбай үзенеке дип аерып алса, Фәсхинең хатыны артыннан килгән ат белән үгезне нигә уртак бер бурычны түләргә сатканнар? Моны хәзер ничек ризаландырырга? Һичкем җавап тапмады.

Кызлар бу сугышта арып эт булдылар. Ни эләксә шуңа күнделәр. Хәерниса үзенең җигеп килгән арбасына ундүрт пот карабодай салды, тәртә янына бер печкән үгез бәйләде, әткәйнең төсе булыр дигәләп, Шибайның иске толыбын алды да, күңеле тулмыйча, карганып, рәнҗеп, әрнеп кайтып китте. Зур кыз Миңнисаның өлеше дә шуннан артмады; ул үзен тагы да җәберсенгәнрәк тойды. Моның өчен икесе дә ирләреннән кыйналып, тиргәлеп беттеләр. Кияүләр ел буенча, үпкәләп, безне көпә-көндез таладылар дип, бу авылдан үткәндә дә Шибай йортына керми йөрделәр. Бу уңай белән ил арасында әллә ничаклы сүзләр, гайбәтләр таралды.

Алтынбай гаҗәп бер кызулык белән эшкә тотынды, бер көн кичектерми, кар яуганчы яңа хуҗалыгын аякка бастыру эшенә кереште. Көнен-төнен аермыйча, бил бәйләп, җиң сызганып эшләде.

Бу тавык кетәген ул бик арзан булганга гына, барыбер хакын чыгарыр дип кенә, тик Шибай урынының бер ягын эләктереп калу өчен генә алган, шуның өчен генә күчереп утырткан иде. Үзара сугыш тукталуга, ул энеләре белән килешү, кирәк-яракны үзара алмашу исәбенә төште. Моның өчен Фәсхигә, Закирга нәрсә бирергә, усал карчыкны ничек йомшартырга дип күп уйланды.

Картның ике өе дә урынында иде. Боларның берсе Сабирага, берсе Закирга сымаграк каралган иде. Алтынбай урам яктагысына күз тотты, шуны күчерсәм, Шибай булам дип уйлады. Закирга тигән ат ике яшь ярымлык кечкенә бия генә иде. Моның белән бер дә юньле хуҗалык корырга җай юк иде. Алтынбай менә шуңар уйнарга чамалады, иң ерак кылны тартып карау өчен, келәт алдында тары төеп торган яшь килен Гөлбануга барды да үтешли генә әйтеп салды:

— Читкә китмәсен, атай төсе дип әйтәм. Ике өй нәрсәгә? Кола бияне алсын, эчке өйне миңа бирсен!.. Урыным таррак, әгәр минем тыкрык өстенә атайдан

калган туфракның бер-ике сажинын кушса, камыты-арбасы белән үк бүләк итәм... — дип сөйләнде дә хатынның, каршы телләнмичә, җөпләп тыңлаганын күргәч: «Җиңгәңнең самавыры да кайнаган бугай, йомырка да пешерәм дип калган иде, әйрән дә языпматашты, яңа ак мае да бардыр, Закирга әйт, миңа хәзер чәйгә керсен, ярыймы?» — дип өстәде.

Бу талашлардан яшь киленнең башы бик авыртып беткән иде, үзләренең хәерче кебек бер тай белән торып калуларына да җаны бик әрни иде. «Өе биек, өйрәсе сыек дигән кебек, зур ике өйле ярлы булганчы, ичмаса, рәхәтләнеп җигәргә ат булыр, иген эшенә ярар». — Менә шундый уйлар белән Гөлбану өйгә керде.

Закир элекке атлардан калган зур камытны үзенең хәерче ябык таена каратып, кечерәйтеп утыра иде. Хатын куркыбрак әйтте:

— Тегеләр килешергә маташалар бугай. Алтынбай абзый сине чәйгә чакырган була, самавырым кайнаган, ди. Май да бар, йомырка да бар, ди...

Закир начар сүз әйтте: «Маен эткә ашатсын», — дип сүгенде.

Гөлбану туктамады:

— Менә, ди, җәмәгать, бала-чагам зур, өем тавык кетәге кебек кенә, ди. Ул да иске, ди. Мин, ди, Закирга камыты, арбасы белән кола бияне кулымнан яздырып бирер идем, ди, әгәр менә, ди, шул урам ягындагы иске өйне бирсә, ди...

Ир тагы тиргәнде: «Ярар инде, әле дә җитәрлек талады, туйса туярлык булды», — диде дә, очлы имән шырпы белән бөятнең җилкәгә килә торган нечкә башыннан чәнчеп, җеп үткәрде; шулай азапланганда, Алтынбай үзе үк килеп керде; бик туганча, хәйләле тавыш белән сүз ачты:

— Менә ничек хәзерге заман. Агасы ашарга чакырганда да килмиләр бит; аш олымы, Закир, син олымы? — диде. Көчләп, тарткалап, энесен үз өенә, кайнаган самавырга, май, йомырка белән сыйларга алып китте. Яңа кечкенә өй эчендә бик тәмләп сыйлады. Гаҗәп туганлык, якынлык күрсәтте.

Чәй белән бергә өйне атка алмашу турында сүз кызды. Алтынбай туктамый димләште. Ахыр шулай килештеләр: Закир Алтынбайдан җигүле арбасы белән кола бияне ала, аның бәрабәренә агасына урам як өйне бирә, өч-дүрт сажин туфрак өсти. Бер якка Шибайдан калган зур өй ничаклы кирәксә, икенче якка хәзердән җимертеп җигәрлек таза, симез, зур, көчле, эшчән кола бия аннан да бигрәк кирәгрәк иде. Тик берничә сажин туфрак турында яңадан сүз булды. Өлкән абза бу сүзне азрак төзәтте:

— Инде, туган, — диде, — дүртме-бишме сажин булыр, үлчәп тормабыз, менә синең капкаңның миңа таба караган баганасы төбеннән кисеп алам мин, — диде.

Закир карышмады. Шуңа күнде.

Шуңа килешеп, Сабира карчыкка бардылар. Ул иң элек Закирны миңа киңәшми

эшлисең дип шелтәләде; өйне биреп, ат алырга каршы тормады, ләкин эчке як өйне алмашырга кирәк иде, урам ягында атаң гомер итте, шунда вафат булды, аның төсе итеп саклауны уйламагансың дип орышты, Алтынбай бу сүзгә бик рәнҗегән сыман бәйләнде:

— Нәрсә, әнкәй, син мине алай читкә кагасын?! Атай төсе итеп сакларга инде Закир аны чит урыска сатып җибәрми бит! Үз улыңа китә, үз күз алдыңда тора!.. Рәхим ит, хәзер үк безгә чәйгә, — диде.

Ире үлгәннән бирле Сабираның күңеле авыр, басынкы иде, җылы сүзгә бик тиз эреп китә алмады, әрнеп, бераз каргап, балалар өчен күп хәсрәт күргән ана йөрәге белән рәнҗеп әйтте:

— Елан син, Алтынбай! Кара елан син! Йомшак әйтеп катыга яткырырга өйрәндең!.. Атаңнан калган бар малны энеләреңнең, сеңелләреңнең авызларыннан талап алдың, инде чәйгә чакырасың, оятсыз син!.. — диде.

Моңа Алтынбайның аз гына да исе китмәде, анасы сүзенә карап кире чигенергә башламасын, тимерне кызуында сугып калырга кирәк дип, кулына читәннән нукта алды да Закирга карады:

— Әйдә, туган, хәерле сәгатьтә атны бирим мин сиңа, — дип, азбарга таба китте; Закир аңа иярде. Икәүләп салам түбәле зур читән азбарга бардылар.

Анда кола бия зур улакта бутау ашый иде. Аяк тавышына колакларын торгызды, хуҗаларына карап акрын гына кешнәде дә, көрпә сибелгән сулы арыш башакларын зур авызы белән умырып алып, тагын чәйни башлады.

Алтынбай нуктаны биягә кидерде, аның ялын, койрыгын, маңлай чәчен, апараланган авыз-борынын сөеп уң кулы белән сыйпады, гаҗәп бер кызгану күзе белән актык тапкыр карады да итәге белән тезгененнән тотып энесе Закирга бирде:

— Мә, туган, игелеген күр, — диде.

Закирның шатлыгы башыннан ашты, йөзе, күзе көлде, атның маңгаеннан, сыртыннан иркәләп сыйпады, улакны бутагыч белән яңадан төзәтте дә, үзенең азбары төзәтелгәнче шунда торсын дип уйлап, яңадан бутауга бәйләде. Балта алып, үз өлешенә калган иске хәерче җимерек азбарны тизрәк төзәтмәк булып китте. Яңа атлы Закир шунда эшли калды.

Алтынбай, өенә кермичә, тәрәзәдән хатыны Фәүзиягә кычкырды:

— Иртәгә өй күчерергә кечкенә өмә ясыйм, бер тәкәне суярбыз, әзерлән, — диде.

Үзе Закирдан алган өйнең бүрәнәләрен балта белән төрткәләп карады, тәрәзә асларында, нигездә берничәсен черегән тапты, боларга яңадан имән бүрәнәләр куеп сипләргә кирәк булыр диде. Шуннан туры балтачы Кәбир остага китте,

аның белән килешкәч, Базар Хәйбулласы дигән мужикка барып, эреле-ваклы сигез бүрәнә сатулашып алды. Шул уңайдан, әле яңа аерылып чыгып, авыл читендә читән алачыкта яшәгән энесе Фәсхигә керде. Бу — балта тотып, үзенең буш йортын киртә белән әйләндереп маташа иде. Агасын күргәч, көләргә дә, ачуланырга да белмичә:

— Нәрсә син, әллә мине монда килеп таларга итәсеңме? — дип каршы алды.

Алтынбай ачуланмады, яңа тормышка күчкән энесенең хәлен сорашты, булышлык итәргә хәзер торган тавыш белән:

— Юк, мин сине өйле итәргә уйлыйм, бу алачыгыңда ничек кыш чыгарсың, — дип, бармагы белән салам түбәле читәнгә күрсәтте. — Без, — диде, — Закир белән алмаштык, аның иске, черегән урам як өенә мин менә дигән кола биямне арбасы-камыты белән бирәм, — диде.

Фәсхи ышанмыйча карады, тел төбе кая барганын да сизмәде, Алтынбайның тагы бер этлеге, берәр начар исәбе бардыр дип уйлады:

— Нәрсә сузасың? Кирәгеңне әйт, — дип чәнечте. Алтынбай, акрын атлап, теге йорттан китереп җиргә аударылган, әле корылмаган амбарның нечкә бүрәнәләренә карады:

— Болар нәрсәгә сиңа? Минем кечкенә өйне ал, амбарны кире күчерик! — диде.

Фәсхи тиз аңламады. Эчтән ишек аркылы тыңлап торган юаш килен Сыйтдика акрын тавыш белән кушылды:

— Алай без отылабыз ич, бу амбар зур бит, — диде. Аның үзенең кечкенә булса да агач өйгә чыгасы бик килә иде, ирен шул якка димләде, Фәсхи, чыгымчы ат кебек, акрын чигенде, тик агасы аңа: «Күчерергә атлар миннән», — дигәч кенә алдындагы кара томан ачылды. Шуңа баглап әйтте:

— Башкорт урманында яз кискән утын бар бит; шуның ике өеме миңа булыр, синең атлар белән китерербез, — дип кушты. Алтынбай моңа җиңел күнде.

Шулай итеп, тагы бер-беренә багланып, берничә алмаш, берничә күчеш ясалды, тәкә суеп, кечкенә өмә ясап, Алтынбай энесе Закирның урам як өен үзенә күчереп, сипләп, яңартып керде. Урам буйга, читән урынына, текмә ясады, киң тактадан капка эшләтте, килешү буенча, Закирның капка баганасын төбеннән кисеп алып, ике уртага читән үреп җибәрде; Шибайның киң урыны икегә ярылды, зуррак ягы элекке азбарлары, Фәсхидән кире кайткан амбарлар белән Алтынбайда калды.Үзенең кечкенә өен фәкыйрьләр урамына күчереп куйганның икенче көнендә урманга барырга атлар сорарга дип килгәч, Фәсхи мондагы үзгәрешләрдән бөтенләй шашып калды, аптырап әле бер якка, әле икенче якка карады. Монда, Алтынбайда, сипләп яңартылган такта түбәле өй

урам буенда ялтырап утыра. Яна текмә, такта капка, эчкәрәк барсаң, һәммәсе яңадан ябылып, салкын кышка юнәйтелгән читән азбарлар, салам түбәле бүрәнә амбарлар тезелеп торалар. Анда ике ат, бер тай, берничә сыер йөри. Тавык, кош кайнаша... Читән аша Закирга карасаң, сиртмәсе җимерелгән зур кое, түбәсе ябылмаган иске азбар, шуңа ялгашка бәйләнгән бичара ялгыз кола бия ашарга сорап кешни. Капкага таба килсәң, урам якның ак өе алынгач, эчке өй үзенең капланмаган кыегы, әйләндерелмәгән ишеге белән, маңгае-бите җимерелгән карт батыр кебек, кызганыч төстә урамнан үткән-барганнарга карап тора.

Фәсхинең күңелендә кызгану да уянды, ачуы да килде, агасына ерткычланып карады:

— Ай-яй! Закирны да аяктан еккан икәнсең бит син! — дип сузып, аптырап әйтте.

Алтынбай кызу шелтә ташлады:

— Ни юкны лыгырдыйсың? Череп аварга җитешкән өенә авылда бер дигән кола биямне бирдем. Тагы ни кирәк?

## XXXII

Караюргадагы Чокыр Хәбипнең улы бу Бикьярдан тегермәнче Фәез кызына өйләнгән икән. Кыз белән кияү кунакка килгәннәр. Кичә чишмәдән көянтә белән кайтып барганда шул Чокыр Хәбип килене туктатты да Кара-юрганың хәбәрләрен сөйләде. Фәтхия әбидән бик күп сәлам әйтте: без ат җиккәндә генә белеп калды, күчтәнәч җибәрергә өлгерә алмады, ди. Гөлбануга шул әйтә, әнкәң, әйтә ди, үзара талашып бүлешкәннәрен ишеттек, хәерле булсын инде, агай-эне арасында була торган эш инде, дип әйтә ди. Тагы шундый бик күп сүзләр сөйләгәч, ахырдан сер итеп кенә әйтте: әнкәң әйтә, ди, чана юлы төшү белән кунак чорлары башланыр, казларым бик күп, бик симерттем, сугымга бер ат ашатып суябыз, дип әйтә ди. Кызым Гөлбануга әйт: безне — карт белән карчыкны кунакка чакырырга уйламыйлармы? Алдан белдерсен, әгәр алар безне быел чакырмаска уйласалар, мин үзем Гөлбану кызым белән Закир кияүне чана юлы төшүгә кунакка алдырам, дип әйтте ди.

Көтелмәгән бу очрашу, бигрәк тә әнкәсенең шулай тиздән кунакка чакырырга әзерләнү хәбәре Гөлбануның йөрәген шатлык белән тутырды, соңгы көннәрдә җанына тигән бу талашларны онытты, үзенең бай киленнән бер атлы бичара фәкыйрьгә калу көенечләрен дә хәтереннән чыгарды. Караюргага кунакка баргач, әнкәсе аркылы атасына ялынмак булды; безнең хәзер авыр чак, киявегезнең дә күңеле булыр, усал каенананың да авызы тыгылыр, син безгә әзрәк аякка басарга булышлык ит дип еларга исәпләп куйды. Шул шатлыклар белән, һәммәсен тизрәк иренә сөйләргә уйлап, өйләренә кайтып керде... Ишекне

ачыйм дип тартса, аннан зур самавырны күтәргән Закир чыгып килә, чак хатынының маңгаена бәреп җибәрмәде. Моны күргәч, Гөлбану аптырап калды. Чиләкләрен шунда баскычка ук утыртып, иренә, самавырга ташланды.

— Бу ни эш? Аны кая илтәсең? — дип, Закирның җиңенә, өлкән ак самавырның колагына тотынды. Бар көче белән алырга, кире кертергә тырышты, елардай булып ялына башлады.

Ир, баскан җирендә туктап, хатынын кире этәрде, каты, тупас ачу белән әйтте:

— Нигә ул чаклы исең китте?

— Нигә китмәсен? Әткәй нәрсә әйтер? Мин аны монда сатып ашарга алып килдеммени? Закир кыза башлады:

— Син кем? Минем хатынмы, түгелме? Гөлбану яшьле күзләре белән ялынып иренә карады, ләкин самавыр колагын ычкындырмады.

— Хатының булса, әйберләрен сатып ашарга димени?

Ирнең ачуы кабарганнан-кабара барды:

— Анда синең ни эшең? Синең әйберең — минем әйберем түгелмени?

Гөлбану бөтенләй елап изелде, тавышы кызганыч белән, өметсезлек белән тулды:

— Булса да сатма! Сатма дигәч сатма! — дип кисте. Закир ачу катнаш хурлану белән селтәнде, ләкин хатынның җилкәсенә төзәлгән кул ялгыш битенә эләкте; сул яңагы, күз төбе кара янып, шешеп кабарды. Гөлбану хурлыгыннан кычкырып елап җибәрде, ләкин самавырны һаман коткармады. Закир бераз сабырланды:

— Тиле, нигә елыйсың? Сатарга илтмим, кибетчегә сигез сумга салып кына торам. Ашлык саткач кире алырбыз, хәзер менә ясак түләүне бик кысып тәңкәгә тияләр. Фәсхи абзыйның да түшәк-ястыгы белән самавырын язып киткәннәр, — диде. Хатынның кулын каерып ташлады, иске капчык белән каплады да самавырны алып чыгып китте.

Гөлбану көянтә-чиләген күтәреп өйгә керде. Үзен тота алмый, озак-озак әрнеп елады. Самавырын да кызганды. Аннан да бигрәк иренең болай кыйнавына да хурланды, аннан да бигрәк яңагының шешүенә, күз төпләренең кара януына әрнеде. Тиздән әткәләре кунакка чакырырлар, бу бит, бу күз белән ничек барырсың? Ничек адәмгә күренерсең? Менә шуларны уйлап, аның гарьләнүе тагын артты.

Шул көндә үк йомыш белән кергән берничә хатын күреп чыкты. Алардан бөтен авылга гайбәт китте, килennәр кызганып, каенаналар шелтәләп: «Начар торалар икән! Көн-төн сугышалар икән», — дип сөйли башладылар.

Караюргага кунакка барганда да күз төбендәге ярасы бетмәгән иде. Исәнлек-

саулык сорашуга, һәркем, — дус та, дошман да, — шуңа күз терәде:

— Бик харап бит! Ни булды? — дип сорамый калмады.

Гөлбану бер әкият уйлап чыгарды, Бикьярда да, Караюргада да, сораганга да, сорамаганга да әйтте:

— Баскычларыбызга бик боз ката... Утын күтәреп менгәндә аягым тайды да егылып киттем, күзләремнән утлар күренде, үләм дип торам, — дип сөйләде.

Ләкин һичкайда һичкем моңа ышанмады, һәммәсе эчтән: «Бичара, бәхетсез булды, күрәсең», — дип уйлады. Башкалар белән сөйләшкәндә моны яшермәделәр, Нурыйның Бикьярга биргән кызы Гөлбану белән Закир хакында: «Начар торалар икән, көн-төн сугышалар икән», — дигән гайбәт таралганнан-тарала бирде. Барын арттырдылар. Булмаганын, җитмәгәнен һәр сөйләүче үзенең хыялы белән, үзенең зәүкына карап, үзеннән тутырды.

Мал бүлү талашыннан бирле кияүләр үпкәләп йөриләр. Бикьярдан ничә тапкыр үттеләр, кермәделәр. Хәерниса бик борчылды. Әнкәсе Сабирага кеше аркылы сер итеп әйттерде, әзрәк җае килсә, ике генә кичкә булса, да кунакка чакырсын иде, дип ялынды. Шуның белән ара төзәлер дип өметләнде. Ана Сабира үзе дә моны бик кирәксенә иде, үткән ел да кызларын китерә алмады, бу кыш та чакырмаса, адәмнән оят бит! Башка чыгым әллә кая китми. Иң авыры ит иде. Гомер барынча, һәр ел сыермы, атмы ашатып суеп гадәтләнгән карчыкның үзенә дә быел ничектер сугымсыз, итсез бөтенләй буш кебек, тормышта мәгънә юктыр кебек тоелды, улы белән киңәшеп, язга, актык чана юлына таба, кызларны, кияүләре белән кунакка чакырырга уйлап куйды. Шул көнне үк азбарны Закирдан киртә-салам белән бүлдерде, ялгаш куйдырды да кызыл башмакны сугымга ашатырга аерып япты.

Нурый карт, бик саран булса да, ил йоласына буйсынып, кызына күп бирнә биргән, аның өстенә аяклы малдан дүрт баш сарык, бер башмак җибәрткән иде.

Каенана, Гөлбану бу йортка килен булып төшкән көннән, бик кадерсез кылынды. Аның бирнә ашъяулыкларыннан тегермәнгә йөрергә капчык ясатты, яланга шуларны тотты; биш көре киҗеле салфитларны табак-савыт сөртеп йөртте, кайда, нинди кадерсез нәрсә кирәк булса, анда килен әйбере бирелде. Мал бүлгәндә кызларның ашлык төяп китәргә нәрсәләре җитмәгәч, яшереп, Гөлбануның киҗеле чаршавына салып җибәрделәр. Килен теш кысып боларга түзде, тукта әле һаман алай булмас, менә җыеп алырмын, әйбәтләп селте белән юармын да яңадан сандыкка тутырып куярмын дип өметләнде. Тик менә самавыр гына әрәм китте инде. Ашлык саткач кайтарып алам дигән булган иде. Ничә ай үтте инде, һаман юк, кичә күрше килен сөйләп торды: хәзер инде кибетчеләр аны кунак килгәндә куя да башлаганнар, ди, үз әйберләре кебек

тоталар, имеш, ди. Гөлбану, бу хәлләргә әрнеп, кичкә каршы, ашарга салыйм, эчереп, ябыйм дип, азбарга барса, үзенең Караюргадан китергән башмагын элек тапмый аптырады, аннан акырганын ишетеп, эчкә караса, ялгызы аерылып, ялгашка бәйләнгәнен күрде. Күңеле сизенде, йөрәгенә курку керде. Малларына тиз-тиз ашарга салды, коега эчәргә китереп, кире илтеп япты да, әрнеп, өйгә керде. Анда каенана иске оек ямап утыра иде. Закир җеп ишә иде. Араларында тыныч кына сүз бара иде.

Гөлбану ишектән керә-керә үк сорады:

— Әнкәй, ул кызыл башмакны нигә аерып яптыгыз? — диде.

Сабира ямавыннан башын күтәрмәде, сукранган шелтәле тавыш белән мыгырданып куйды:

— Нәрсә ул чаклы хәлең бетеп кергән? Әйтерсең, үз балаңны суялар!.. — диде.

Килен бөтенләй аңлап җитте, бераз катырак әйтте:

— Балаң түгел дип, мал да кызганыч бит. Язга каршы башмак суялар диме икән?

Сабира ябык, газаплы җыерчыклар белән капланган карт битен күтәрде, эчкә баткан нурсыз күзләре белән килененә карады, зәһәрле тавыш белән кайтарды:

— Алаймыни! Бүтән чакта Хәерниса апай, Хәерниса апай дип кәнтәйләнергә бик яратасың бит! Туеңда аның белән куш беләзекләр, йөзекләр дә алышкансың бит! Башмагыңны суеп кунакка чакырырга булгач, Хәерниса апаң онытылдымыни? — диде.

Гөлбану, тавышын тагы да күтәребрәк җаваплашырга уйлап, авызын ачкан иде, Закир аңа кулындагы дилбегә белән кинәт селтәнде, ачу белән кычкырды:

— Син нәрсә атлаган саен әнкәй белән талашасың?.. Хатын елап җибәрде, ләкин сүзеннән туктамады:

— Нәрсә талашыйм, бер дә талашмыйм. Киҗеле ашъяулыкларымны капчык итте, — аңа түздем; киҗеле чаршавымны кызларына карабодай салып җибәрде, — аңа бер сүз әйтмәдем; менә самавырымны бер айдан алам дидең, кыш үтте, һаман аласың. Инде кунак чакырырга дип минем башмагымны суярга әйтәсез!.. — дип, бер-бер артлы тезеп китте.

Карчык каенана урыныннан ук кузгалды, идәнгә төкереп җибәрде:

— Тфү, оятсыз нәрсә! Тапкан бер сүз: имеш, минем ул әйберем, минем бу әйберем! Синең ирең кая? Аңардан үтеп сүз сөйләргә ничек оялмыйсың, битсез! Саескан шул, затсыз Саескан шул! Саескан үзенең саесканлыгына кайтмый кая барсын?.. — диде дә икенче якка әйләнеп утырды.

Гөлбанунын җанына тиде, ул гомерендә беренче тапкыр каенананың үзе кебек әче телләшеп китте. Ахыр шуны әйтеп ычкындырды:

— Тапкан бер сүз: имеш, Саескан да Саескан, Саескан да Саескан! Син үзең кем соң ул хәтле? Үзеңнең Кәҗә Солтан кызы икәнеңне онытма! — дип әйтеп ташлаганын сизми да калды.

Сабира каенана өчен дөньяда иң начар, иң авыр сүз шул Кәҗә иде. Чөнки бөтен тирә-якта ул Кәҗә исеменә багланган Сабирага карата гаҗәп ямьсез, авыр бер гайбәт сөйлиләр иде. Яшь чагында Сабира бу гайбәт сәбәбеннән үзен әллә ничә тапкыр Үзән елганың тегермән буасына ташлый язган иде. Йөрәгенең иң авыр җирендә бу гайбәт кара кан булып оешып ятты. Моны. ишеткәндә йөрәге кузгала, мие каплана торган булды. Ләкин үз килененнән моны ишетү инде аны бөтенләй шаштырды, агулы хәнҗәр чәнчелгән кебек, йөрәген тотты да:

— Уффф... оятсыз, кәнтәй, — дип, янындагы уклауны алып киленгә бәрде.

Гөлбану иелде, ләкин котыла алмады; анасы ягыннан Закир төште, кечкенә соры күзләрен ерткычландырып, кулындагы дилбегәләре белән хатынга ыргытылды, кызып, үзен-үзе онытып, эштән чыгарганчы кыйнады да, күлмәкчән көенчә, ишектән типкәләп тышка, суык карга этәреп җибәрде, үзе шапылдатып ишекне япты.

Киленнең башы әйләнде, ни эшләрен ачык белеп җитмәстән, тик нечкә күлмәкчән тәннең үзен-үзе суыктан саклап калырга теләве буенча, янәшә өйгә, Алтынбайларга йөгерде. Анда өлкән килен ялгыз гына икән. Бик кызганып каршы алды, үзенчә иң якын күреп, иң юаныч сүзләр сөйләргә тырышты:

— Шулдыр, шул Әремтел Сабира аждаһадыр... — диде. Гөлбануның ертылган күлмәкләрен, яулык астыннан тузгып чыккан чәчләрен, шешенгән битен карап, ни барын, нигә кыйнаганлыгын сөйләтте. Үзенең гомерлек газапчысы кебек ясап, Сабираны тиргәп китте: — Булмас, киленкәем, түзә алмассың! Фәрештә булсаң да ул аждаһа кулында түзә алмассың, — диде, үзенең аңардан күргән газапларын тезде: — Каенатай исән чакта тагын бер хәл иде, ул аны таяклый иде, шуннан бер йомшара иде, хәзер инде ул чылбырдан котылган эткә әйләнде, — дип өстәде. — Үзенең көндәше бичара Бәхрияне мыйшаяк ашатып үтерде ул, киленкәем, — дип бетерде дә, яңадан санап-санап, Гөлбануга акыл бирергә кереште: — Иреңә әйт: мин сиңа урамнан килгән хатын түгел, диген... Минем ил карты — атам бар, ил карчыгы — анам бар, диген, болай эт көненә түзәр хәлем юк, мине аер, мин кайтып китәм, диген... Берүк әйберләреңнең берсен дә калдырма. Сөлгеләреңне дә ал, салфитларыңны да ал, чаршауларыңны да ал... Кибетчегә әйт: мин, диген, атамнан килгән самавырны синдә калдырыр хәлем юк, бир, алып китәм, диген. Бирмәсә, муллага бар, старостага бар, ил картларына бар. Елап әйт: минә, диген, мине көн-төн кыйнап куалар, диген, шешмәгән җирем калмады, сынмаган сөягем калмады, шулай кыйныйлар; ирем

дә кыйный, каенанам да кыйный, диген; үзләре, диген, минем әйберләремне бирмиләр, диген...

Зур килен шулай үзе йөрәгеннән әрнеп, тәмләп тезеп утырганда ишек ачылды, баягы дилбегәсен тоткан килеш, Закир килеп керде. Ирен күргәч, Гөлбануның тәннәре чымырдап китте. Курыккан, елап, хәсрәтләнеп изелгән йөзе, коты очкан күзе белән аңа йотылып карады, тагы кыйный башлый бугай дип, аның кулындагы дилбегәдән аерыла алмады.

Хатын бүген иренең төсендә моңарчы булмаган бер нәрсә күрде: ничектер менә Закирның, гадәттә, сарыкча ахмаграк күзләре бүген астыртын, тискәре дуңгыз ачуы белән карыйлар.

Гөлбануны тагы катырак курку алды... Калтырана башлады. Ир, тешен кысып, ачулы дуңгыз күзе белән батырып карап килде дә хатынның күлмәкчән тәне өстеннән дилбегә белән, сыер куалаган кебек, уратып сукты:

— Өстерәлеп йөрмә! Бар, өеңә кайт, — дип акырды. Гөлбану сүзсез, тавышсыз, каушап, тагы ниләр генә булыр икән, Илаһым хуҗам, дигән бер курку белән өйдән чыгып китте. Закир шунда ук астыртын усал ачу белән җиңгәсенә карады:

— Син нәрсә? Әллә үзеңнең яшь килен чагыңны оныттыңмы? — диде.

Фәүзия әрнеп, зәһәрләнеп җавап кайтарды:

— Бер дә онытмадым, синең аждаһа анаңны кабергә кергәч тә онытмам, — диде.

— Онытмасаң, нигә котыртасың?

— Кем котырта? Бер дә котыртмыйм, син үзен, юньсезсең! Без килен чакта каенатай мәрхүм исән иде. Алланың рәхмәтендә булсын, үлем туфрагы җиңел булсын, синең анаңны ул авызлыклый, таяклый торды. Минем ирем дә синең кебек җебегән авыз түгел иде!..

— Нәрсә син һаман миңа бәйләнәсең?

— Бәйләнми ни эшлим? Син элек җебегән идең, муенсыз идең. Хәзер муенның катты. Әмма туры катмады, анаң ягына кыйшаеп, чалыш муен булып катты... Менә кем син!.. Бик беләсең килсә, миннән ишет! Бер мин түгел, һәммә кеше шулай ди...

Җиңгә белән каене шулай байтак әрләштеләр. Закирның ачуы кабара бирде, сүзне уртасында кисте:

— Мин өйрәтим әле, — дип, Гөлбану артыннан дилбегәсен тотып, үз өенә йөгерде.

## XXXIII

Бәйрәм ашы кара-каршы, диләр.

Кибетче Хәйрулла үткән җәйне Гөлбануны озатканда хатыны белән арчи булып килгәннәр иде. Быел кыш Нурый белән Фәтхиягә туйга барырга әйтте.

Кибетченең бердәнбер улы Насыйбка Бикьярдан Бака Харис дигән крестьянның кызын ярәштеләр. Хәйрулла, гадәтенчә, шаярыбрак Нурыйдан үтенде:

— Былтыр син мине кызыңа арчига җибәргән идең, быел менә минем улымның туена бар, карт кода булып түрнең башында утыр, — диде.

Бу көтелмәгән кодалык башка һәркемнән бигрәк Фәтхия әбине куандырды. Ул үзенең кызы Гөлбану аркылы бераз тамыр тартып карады, Бикьярга үзләрен Сабиралардан кунакка чакыртырга чамалады. Баласының көн итүен үз күзе белән күреп, кодагыйның азрак күңелен йомшартып кайтырмын дип өметләнде, ләкин яңа аерылып чыккан ел дип, карт кодагый моңа бара алмады. Бу эшләр, әлбәттә, болай телдән ачык әйтешеп, сатулашып йөртелмәде, һәммәсе иң сердәш кешеләр аркылы, бик кинаяле сүзләр белән үтәлде. Ничек булса да шулай килеп чыкты, Бикьярлар бу кышта Нурмөхәммәт кодаларны кунакка чакырмадылар. Фәтхия карчыкның бу рәвешле җимерелгән өметләре, икенче яктан, менә шул кибетче Хәйрулланың туе аркылы калкып күтәрелде. Сабира кодагый аңда ни эшләр, үзенең кодалары катнашкан туйны аш мәҗлесенә алып, хөрмәт күрсәтерме, юкмы? Ләкин шул авылга баргач, шундагы кешеләр эчендә кайнагач, ана карчык, әлбәттә, үз кызын күрми дә кайтмас, ничек көн иткәнен белми дә калмас, шул кайгылы гайбәтләр, һаман сугышып, начар торулары хакындагы сүзләрнең дә төбен ачмый да куймас.

Бикьярга өч чана кодалар барыр дип сөйләшкәннәр икән. Төп кода Хәйрулла белән хатыны — бер; Нурый белән Фәтхия — ике; өченчегә матур җиңгә Мәфтуханың ире ончы Гайфулла әйтелде. Бу баш өсте риза булды. Күптән түгел Мәфтуха өстеннән «балам юк» дигән сылтау белән алган яшь келәшнең кунакка йөрергә йөрәге ашкынып тора иде. Уңай чыкканга бик дәртләнеп әзерләнә башлады. Ләкин монда һичкемнең күңеленә килә алмый торган бер киртә баш күтәрде: Фәтхия карчык дөньяга сыймый, дулый. Нурыйга да әйтте, Хәйрулла белән аның хатынына да сөйләде, туйга барырга әзерләнгән Гайфулланың үзен дә тетеп салды:

— Авызыңны да ачасы булма, — диде, — туйга барам дип, синең ул кыланчыгың белән бер табында янәшә утырыр хәлем юк, булмас, башыңа да китермә, — диде.

Гайфулла аңа эне тиешле иде. Шуңа таянып, болай кисеп сөйләште. Нурый картка да, Хәйруллага да барыбер иде. Ике хатынның яше барса ни төзәлә дә, карты барса ни җимерелә! Гайфуллага алай булмады: аның өендә бетмәс-төкәнмәс буран башланды. Ир, ялынып, үзенең апасы Фәтхиягә килде, ләкин бу

гомерендә беренче тапкыр үзенең сүзендә, кирелегендә теше-тырнагы белән ябышып ятты:

— Булмас, атакайгынам, синең ул... белән бер табында янәшә утырыр хәлем юк; Мәфтуха барсын, ул кыланчыгың өлгерер әле, — диде.

Тартыш байтакка сузылды. Хәйрулла үзе барып, Гайфулла белән сөйләште:

— Әгәр, — диде, — инде син, агай — олы, мин — зур, дисәң, Нурый белән Фәтхияне калдырабыз да яшь хатының белән сине җибәрәбез, алар урынын мин Чокыр Хәбипкә әйтермен; әгәр инде бозылышмыйк дисәң, өлкән хатының Мәфтуха белән бар, юкса ул тилергән Фәтхия карчыкның кирелеге бетәргә ошамый, Гайфулланың ул кыланчыгы белән мин бармыйм дигән дә каткан, чыгымчы ат кебек алга да атламый, кире дә чигенми...

Гомерендә беренче тапкыр карчык җиңеп чыкты: Гайфулла, үз өендә бик күп ызгышлар кичергәннән соң, яшь хатынына мең төрле вәгъдәләр тоттыра-тоттыра, өлкән хатыны Мәфтуха белән туйга китте.

Моңа Фәтхия шатланды, аңардан да бигрәк Гөлбануның куанычы дөньяга сыймады. Бу арада бит шул чаклы авыр хәлләр кичерде, шундый кайгылар булды, шул чаклы күп күңелсезлекләр өелеп килде, сердәш матур җиңгәгә сөйләп бер еласа, бәлки, йөрәге азрак ял итәр кебек, бераз җиңеләер кебек тоелды, шул тойгы белән Караюргадан Бикьярга киләчәк кодаларны көтеп алды, шул өмет эчендә җиңгәсе Мәфтуха белән очрашты.

Ләкин беренче күрешүдә ул ике дус, сердәш хатын, һичбер сүзсез үк бер-беренең кайгылы көннәрен йөрәкләре белән үк тойдылар. Беренче сүздә, беренче исәнләшүдә Гөлбану үзенең кызлык серләрен саклаган матур җиңгәнең йөзенә карап хәйран калды: әле менә үткән ел гына алсу битле, яшь матур хатын иде, хәзер ябыгып саргайган, күз төпләренә, авызының ике як почмагында әллә нинди җыерчыклар сузылганнар. Ике сүз әйтә дә үксеп елап җибәрә, ике сүз әйтә дә ирен, көндәшен каргый. Алай-болай сөйләште дә сүзен сихергә китереп терәде:

— Гөнаһлы булсам булырмын, тәмугта янсам янармын, — ди, — шул кыланчакның авызын-борынын чалшайтмый куймыйм мин, ди. Ходай үзе күрә, бер кичермәсә, бер кичерер, ди; син миңа шул күрәзә карчыкның кайда торганын ипләп өйрәт, ди. Мин, ди, теге Мәсәйлебаштагы чуаш карчыгына барырмынмы әллә дигән идем дә, ди, бер дә җае туры килми, ди. Бу Бикьярныкын да мактыйлар, барын-барын әйтеп бирә, имеш, ди, теләсә — сөйдерә, теләмәсәң — биздерә, имеш, ди, тик акчаңны кызганмаска, имеш, — ди.

Гөлбану аптырап калды, ул сихерче Гайния дигәнне бик күп ишеткән иде.

Авылның читендә ташландык бер өйдә тума-сукыр улы белән яши, имеш, диләр иде. Ләкин үзе кайда икәнен анык белми иде. Бу бик сер әйбер. Кем туры килсә, шуңардан сорар хәл юк!

Карт җиңгәсе Фәүзияне, юаш килен Сыйтдиканы уйлады: «Болар беләләр булыр. Шулай да куркыныч шул. Сер тотмаслар, хатын авызында сүз торамыни. Әллә кемгә әйтеп ташларлар. Менә Хәерниса апа монда чак булса, аның белән сөйләшеп карарга булыр иде. Юк, ул да ярамый. Ничаклы дус күренсә дә, Сабира баласы, Закир апасы бит! Үз каны тарта. Талашса, сугышса да, аларга кайта. Менә кечкенә кыз Фагыйлә белән малай Миңлегалим бик ярар иде, болар Гөлбануны бик яраталар, шулай да кыен. Балалык белән сөйләрләр дә ташларлар». Гөлбану шулай озак эзләнде, кем аркылы ул сихерче Гайнияне белү турында күп баш катырды. Ахырда бер дә көтелмәгән җирдән белеп куйды. Көянтә белән чишмәгә суга чыкканда, бер килен сорамый-нитми үзе чәрелдәп китте. «Хәйран инде, — ди, — аның белмәгәне юк, алдыңа сихерле көзгесен китереп куя да, шуннан ни булганын, ни булырын менә уч төбендәге кебек күрәсең, — ди. Сөйдерәм дисәң — бер төрле им-том ясый, биздерәм дисәң — икенчесен ясый», — ди. Гөлбану бо-ларны бер туры китереп матур җиңгәсенә сөйләде, кат-кат ялынып әйтте:

— Берүк, җиңги, сак маташ, барганыңны, кергән-чыкканыңны күреп калсалар, шул гына сихерләтте дип башыңны ашарлар, — диде.

Мәфтуха моны үзе дә ачык белә иде. Шау-шулы туй арасында ул сихерчегә барып кайта алу аңа бик авырга төште. Шулай да гомергә җәбер астында яшәү белән үткенләнгән хатыннар хәйләсе аңа ярдәм итте. Ул: «Гөлбану белән сүзем бетмәде, шуңа барыр идем», — дип, аш мәҗлесеннән калды, дустына бер генә минутка кереп чыкты да, акчасын, бүләген җиңенә, күлмәк эченә тутырып, өйрәтелгән тыкрыклар, кечкенә урамнар буенча, кичнең караңгысы төшеп килгән чакларда сихерче Гайниягә барып кайтты. Шуның белән күңеле бөтенләй тынычланып ук китте, үзен бәхет юлын яңа тапкан кебек сизенде, аның алдына үз кайгысы урынына дусты Гөлбану килеп утырды.

«Эт белән мәче кебекләр икән, һаман сугышалар икән. Каенана да кыйный, ир дә кыйный икән, барлык бирнәсен, барлык мАлларын әрәм-шәрәм итәләр икән, бу елап карыша башласа, дилбегә белән кул-аягын бәйлиләр дә икән, кышкы чиллә суыгында тышка, кар өстенә күлмәкчән чыгарып ыргыталар икән, бу шунда, елап, үксеп ята икән...» — дигән кебек сүзләр Үзән елга буйлап Караюргага да җиткәннәр иде, анда да һәр телдә бу гайбәт бар иде.

Туйга килгәч, Мәфтуха бу сүзләрне тагы куерак рәвештә ишетте. Дусты белән сөйләшкәндә, Гөлбануның болай тиз үзгәрүенә Мәфтуха бик гаҗәпләнеп

карады. Бу бит кыз чагында шат, уенчак иде. Яңгырап торган тавышлы, җиңел йөрешле иде. Хәзер ничектер бик сүлпән күренә. Аяк атлавы ук элекке түгел, басынкы, тупас кузгала. Күзендә аның шатлык нуры уйный иде. Хәзер бөтенләй тонган. Кайгы белән басылып карый. Менә хәзер бер сүз әйтер дә елап җибәрер төсле тора.

Ике сердәш бу туй кайнашы эчендә аз очраша алдылар. Һәр очрашуны үз кайгылары, үз бәхетсезлекләре турында елашып, бергә күз яше түгеп үткәрделәр.

Бу туй уңае белән Бикьярда кунак-төшем аз булмады. Аш-чәй мәҗлесләреннән бушарга вакыт табылмады. Шулай да Нурый карт мәчеттән чыкканда, капка төбендә туктатып, Аллаяр мулла белән каты бер сөйләшеп үтте:

— Хәзрәт, — диде, — гайбәт белән дөнья сасыган бит! Кая барсаң анда Әремтел Сабира дип, муенсыз Закир дип, бичара килен Гөлбану дип сөйлиләр. Сез имам кеше — безнең кияүне чакырып бер үгетләсәгез ни була! Бераз акылга килмәс идеме? — Кызы Гөлбануның түзә алмый ике тапкыр качып кайтуын да кушты.

Мулланы калтырау алды. Бу сүзләрне ул күп ишеткән иде. Аңа кыйналган, аркасы кара янган, шешенгән бит-башы белән, елап, Гөлбану үзе дә ике тапкыр качып килде.

— Хәзрәт, түзәр хәлем бетте, ни эшлим инде? — диде. Мулла аны озак үгетләде:

— Сабыр итәргә кирәк. Сабыр иткән морадына җиткән, әссабры минәррахман, дигән китап, ир хакы — Тәңре хакы, дигән, ирнең суккан җире тәмугда янмас, дигән китап, сабыр ит, түз, килен, — дип кайтарды.

Бу хатынның Бикьярдан Караюргага ике тапкыр, иренең газаплы кыйнауларына түзә алмый качып киткәнен ул ишеткән иде. Закирның, аермыйча, тагын ныграк кыйнап, кире алып килгәнен дә белә иде. Ләкин мулланың зиһене башкага китте. Бу арада шәригатьтән үтеп законга баргалый башлаганнары сизелә. Ул көнне, мал бүлгәндә, Шибай мәрхүмнең улы Алтынбай да шулай дип ычкындырды. Бүген Нурый карт болай каты тавыш белән сөйләшкәч, Аллаярның коты очты:

— Әллә ак сакаллы башы белән бу җүләр дә шул якка каерамы икән? — дип шикләнде.

Ләкин ялгышты. Нурыйда андый исәп юк иде. Ул ун тиен садака биреп дога кылдырды да үтенеп әйтте:

— Хәзрәт, — диде, — төпчегем бит, күңелем бик рәнҗи, кияүне чакырып үгетли күр, әүвәл Аллага, аннан сиңа тапшырам, — диде. Янадан кызы Гөлбану

ике тапкыр түзә алмыйча качып кайтканын сөйләде. Ире Закир, базардан кайтышлый кереп, арбасына салып, кыйнап алып киткәнен дә әйтте: — Үзе кыйный, үзе аермый, авыр хәл, — диде.

Картның сүзе шуның белән бетте. Ул тагы дүрт көнлек туйны бөтенләй каплаган аш-чәй мәҗлесләре эченә кереп китте.

Ана карчык Фәтхия башка һичкем белмәгән караңгы якларны күрде. Кызы Гөлбану үзенең авыр көнен сөйләп анасын күп елатырга теләмәде, бик билгеле булганнарын, бик зурларын гына сөйләде; ләкин карчык аның сөйләргә теләмәгәннәрен дә бөтен төбе-тамыры белән тикшереп белде. Кызы яшерергә азапланса да, башмакның кайчан, нигә, ничек суелганын да аңлады, биш көре киҗеле ашъяулыкларының, кызыл башлы киң сөлгеләрнең, капчык ясалып, яланга, тегермәнгә, кызларның мирас малларын ташырга йөртелгәнен дә чокып чыгарды; самавырның нинди хәлләр, талашлар, кыйнашлар эчендә кибетчегә сигез тәңкәгә илтеп салынганын, әле һаман кире алынмаганын анык эзәрләп тапты; Закир кияү турында: «Электә муенсыз иде, хәзер муены анасы ягына кыйшаеп катты, чалшайды», — дигән сүзләрнең эче мәгънәсен дә ана йөрәге тирән аңлап алды.

Ул берәүнең үтенече белән карт кодагый булып килгәнгә, әлбәттә, туйда, мәҗлестә, кеше алдында берәүгә дә бертөрле дә кыек сүз әйтмәде; очрашканда Сабира кодагый белән дә бик күңелләнеп, бик яратышып сөйләшергә тырышты. Ләкин бар белгәнен, йөрәгенә җыелган барлык әрнүләрен Караюргага күтәреп кайтырга көче җитә алмады: туйның актык көнендә, түбән очтан, бик ерак бер җирдән, мәҗлестән бергә чыкты да сүз ачты, сөйләшергә вакыт иркенрәк булсын дип, аларга каршы килгән чанага да утырмады, озаклап Сабира кодагый белән сөйләшә-сөйләшә җәяү кайтты:

— Инде, кодагый, — диде, — авыр алма, балам бит, күңелем бер дә тыныч түгел. Илдә авыр сүзләр бик күп йөри, — диде.

Сабира аны кырт кисте:

— Җә, кодагый, син дә инде, алтмыш яшькә җиткәнсең, урам сүзен телгә алып йөрисең, — диде.

Фәтхия болай җиңел генә туктарлык түгел иде. Берәм-берәм барын да тезде, ашъяулыкларын, сөлгеләрен дә әйтте, беренче тапкыр кунакка качып баруларын да калдырмады. Башмак турында сүз чыккач, уклау белән бәргәнен дә авызга алды. Кызларымны-кияүләремне сыйлым дип, киленнең актык башмагын сую килешеп бетми шул, дип чәнечте. Зур ак самавырның әле һаман кибетченең түрендә, табыннарында гөжләп кайнап, чәй эчерүенә дә тукталды. Гөлбануның кыйналып ертылган яулыкларын, күлмәкләрен дә телгә алмыйча

китә алмады, үзләренә, әле быел көз генә, ярылган маңгай белән кунакка барып, бөтен ил алдында мәсхәрәгә калганын да китереп кушты. Закир кияү үзе кыйный, үзе аермый, яратмый икән, көчләп тотмасын иде, аерсын да җибәрсен иде, дип өстәде. Гөлбануның болардагы газапка түзә алмыйча качып кайткач, ир, үзе барып, кыйнап, көчләп алып киткәнен дә арттырды.

Шулай бер акрынлап, бер зәһәрләнеп барган бу әче әрләшнең ахыры нык кызып, дулкынланып китте. Сабира сабырын югалтты, тагы шул Саесканга барып терәлде.

— Кызың юньсез, затсыз! Кулыннан бер эш килми, бер сүз әйтсәң, елап, Алтынбайларга йөгерә, син мине талаганчы кызыңны үгетлә, ул адәм рәтле булса, берәү дә тимәс; күңелеңә авыр алма, кодагый, алма агачыннан ерак төшми, диләр, Гөлбануың да шул Караюрга Саесканнарына тарткан, рәтсез, затсыз нәрсә, — диде, туйда киселгән ат койрыкларынача хәтерләп үтте.

Бу сүзләрдән Фәтхиянең күңеленә авыр таш утырды, теле киселде, тагы бер башлап, бу Әремтелне утлы күмергә бастырыйммы дип, авыз ачкан җиреннән үзен тыйды; бу талашлардан Сабираның җене тагын ныграк котырачагын, Гөлбану өстенә тагы начаррак ташланачагын уйлады; шуны исәпләп, ирененә килеп җиткән кәҗә гайбәтен дә әйтми кире йотты.

Шул көн, туйдан китәргә җыенып йөргәндә, ананың йөрәге чыдамады, Нурыйга барын сөйләп бирде, ахырдан өстәде:

— Безнең артык балабыз юк. Бу тәмуг утында калдырганчы, әйберләрен төйик тә үзебез белән алып кайтыйк, — диде.

Уртада иң кыен нәрсә шул иде: ир аермаса — хатын китә алмый, әгәр башбаштаклык белән хатын үзе китеп барса, аның барлык әйбере ир кулында кала.

Менә бу хәл Нурыйны аяктан екты. Карт шул якка кагылды:

— Нәрсә сөйлисең син, карчык? Хатынны аерып алу җиңел дисеңме? Ир аерырмы, юкмы? Ул аермаса, ничек алып китәсең? Бирнәсен, мәһәрен ни эшләтәсең? Ул өч йөз сум уенмыни?

Нурый үзенең гадәттәге каты кирелеген күрсәтә алмады, төрле яктан китереп кыскан, бер-беренә каршы әйберләрнең эчендә ни кылырга, кая барырга белми газапланган адәм кебек әрнеп, йөрәк белән әзләнеп сөйләде.

Иренең болай йомшарганын күргәч, Фәтхия катырак кагылды, ныграк атларга тырышты:

— Җә, — диде, — мал дип, мәһәр, бирнә кала дип бердәнбер кызыңны ут эчендә яндырмассың бит, язган мал табылыр әле, — диде.

Карт, үзенең бөтен гомерен сыгып китереп чыгарып салган кебек, газаплы

тавыш белән тагы ирнең аермавына килде. Хатын үзе баш тартып китсә, барлык әйбере, бирнәсе, мәһәре ирдә кала. Аның өстенә, ир теләсә аера, теләмәсә — юк. Талак бөтенләй ир кулында. Аның мие менә шунда әйләнде:

— Их, карчык, карчык, — диде, — сиңа әйтергә генә җиңел ул. Ул бирнәгә әз көч, әз акча түгелдемени? Базар саен: җеп ал, киҗе мамык ал, буяу ал, җитен ал, дип колагыма тукып торучы син булмадыңмы? Аяклы малны нигә исәплисең? Өч йөз сум мәһәрне ничек ул убырлы Сабирага ташлап китәсең? Бүтән мужиклар кыз биреп йорт төзәтәләр. Без бит Гөлбануның мәһәр акчасыннан бер тиен, әйтәм бит, сукыр бер тиен дә үз кирәгебезгә тотмадык. Бары да аның үзенә, өс-башына, бүләгенә китте. Инде барын да, барын да шул хәерче көязләргә ташла да кит, имеш! Бу уенмыни?! Ярый, ташларга да риза булыйк, анда да ир аерырмы әле? Ир — баш, хатын — муен; талак ир кулында, ул аермаса, — хәзрәт белән сөйләштем мин, — ир аермаса, ди, Алла да аермый, мулла да аера алмый, ди... Менә бит, карчык, ничек төенләнеп беткән ул... Күз алдында бит, Гөлбану ике тапкыр, монда чыдаша алмагач, үзебезгә иреннән качып кайтты бит. Ни булды? Тагы эт урынына кыйнап кире алып китмәдеме? Җепнең очы бик чуалган шул!..

Сүз озак барды, ләкин чуалчык төеннәрнең очын ничек табарга, ничек сүтеп, кызлары Гөлбануның авыр язмышын җиңеләйтергә юл таба алмадылар.

## XXXIV

Гөлбану игез бала тапты. Икесе дә үле тудылар. Алтынбайның хатыны, өлкән килен Фәүзия, моны эләктереп алды. Бөтен Үзән елга буена гайбәт чәчте: йөкле дип тормады, кыйшык муен Закир һаман типкәләде, кыйнады, корсагына ни туры килсә шуның белән бәрде дип, сораганга да, сорамаганга да чәрелдәп йөрде.

Гөлбану үзе бала бик теләгән иде: ул туса да ярый, кыз туса да ярый, тик бәхете, исәнлеге белән генә тусын дип, шатланып көткән иде. Игез дигәч, шатлыгына гаҗәпләнү катнашты; үле туганын белгәч, һушыннан язды, чак акылдан шашмый калды. Авырлы чагында ул, бөтен дөньясын онытып, үзенең күңелең тик шул туачак балага баглап бетергән, аңа искеләр, күлмәкләр, юрганнар әзерләп куйган иде. Ул булса ничек исем кушарбыз, кыз булса ничек исем кушарбыз дип, көннәр-төннәр тик шул турыларда гына уйлый торган булып киткән иде. Берничә тапкыр, ул булса... ул булса... ул булса... Лотфи дип кушарга ярамасмы икән дип тә куйды. Ләкин моны бик тиз башыннан чыгарды, ярамас та, кирәкмәс тә дип беркетте. Исеме табылыр, әнкәйләр белән дә киңәшербез, аларны исем туена чакырырбыз дип уйлады. Бала тудыруның бөтен газапларын менә шул матур өметләр белән бергә кичерде, бу күңелле

уйлар аның авырлыкларын җиңеләйттеләр...
Балаларның үле икәнен белгәч, һәммәсе берьюлы җимерелгән кебек булды. Дүрт сәгать һушына килә алмады. Әбиләр, үләме, каламы дип, куркыныч астында тордылар. Гөлбану үлмәде, ләкин авызында тәм бетте, тормышыннан ямь тапмас булып калды.
Тирә-ягында кайнап торган кешеләр үзләре дә, аларның сүзләре, шелтәләре, гайбәтләре дә ничектер аңа кагылмый үтеп торалар кебек тоелды. Әле авырып яткан чакта ук Фәүзия киленгә каршы Сабира каенана зәһәрләнеп, кара ачу белән ташланды:
— Син, — диде, — илдә юкны пешекче хатын булып йөрмә. Имеш, корсагына кыйнадылар, имеш, шуннан балалар үле туды! Эт тә кыйнамаган, үзе черек, нәселе, ата-бабасы черек аның. Кем туры килсә шуның белән өстерәлгән дә череп беткән. Шуңа балалары да череп чыгалар! — дип озак такылдады.
Шул талаштан бераз үткәч, карт җиңги Фәүзия ялгыз вакытны туры китереп керде. Озак утырды, әллә ниләр сөйләп бетерде:
— Синең Кыйшыгың, — ди. Ул Закирга үзе элек «муенсыз» дип әйтә иде, соңгы заманда, аның муены анасына таба кыйшаеп каткан, дип сөйли башлады. Шуннан үз сүзеннән үк алып, аңа “кыйшык муен” дип, тагы кыскарак, Кыйшык дип кенә йөртә торган булды. — Синең Кыйшыгың, — ди, — үзенең хәерчелеген белмичә, хатын өстеннән хатын алырга йөргән булган иде. Түбән очның теге, үлгән солдат хатыны яучының борынына сугып кайтарган, ди. Әйтә икән, ди: баг алмасы кебек бер хатыны бар, элек шуны туйдырсын, аннан икенчене эзләр, дип әйтә икән, ди. Шулай борынына чиртеп җибәргән, — ди...
Гөлбану моны, үзенең авыру түшәгендә, кызган баш белән тыңлады. Ләкин бу да аның күп газаплы күңеленең әллә кай почмагына барып утырды да акрын сызланып яткан кайгы булып кына урынлашты. Тик менә ике баланы гына бик сагынды.
Кечкенә кыз Фагыйлә белән малай Миңлегалим аның башыннан чыкмады. Ике еллар вакыт бит инде. Болар үстеләр, зураеп баралар. Шулай да Гөлбану, үзенең авыру түшәгендә ятып, аларның теге, беренче көн печән җыеп, кибән салгандагы чакларын сагынды. Кечкенә кыз Фәгыйлә, кояшлы көндә эсседә янып-көеп, тырмасын ташлый да Исәнбикә уртасындагы күлгә китә. Аннан акрын гына төн ягындагы тау битенә сыза. Кызыл чикмән кибек җиләк каплаган җиргә бара. Аннан кызу кояшта кызарып пешкән эре, тәмле җиләкләр алып килә. Болар шундый тәмлеләр, әле менә хәстә көйгә дә иренендә, телендә шул чакның тәме сизеләдер кебек...
Гөлбану үзенең кечкенә дусты Фагыйләне бүген авыру кызуында менә шул

вакыты, шул җиләкләре белән сагынды. Малай Миңлегалим дә кибән салганда, болыт, яңгыр килеп басканчы ташып бетерик дип, ат өстендә уйнап, шаярып, Үзән елга буен яңгыратып, чүмәлә тарттырган чагы белән күз алдына килеп басты. Әнә шунда ат батты бит. Чыгарам дип Закир буялып бетте, Гөлбану аны Үзән елгада кырып-кырып юды. Аннан соң малай тагы, тагы атка сикереп менде дә, ике бармагын тешенә куеп, әче сызгырды. Юк, анда түгел бугай. Кич, атка куна китәр алдыннан тәрәзә аркылы күрше малай Апушка сызгырып җибәрде бугай...

Менә шул чаклары белән кечкенә кыз Фагыйлә дә, малай Миңлегалим дә, ничектер, Гөлбануга якын, бик якын булып тоелдылар. Башка бер әйбер дә аны алай тартмады, бернәрсә дә исен китәрмәде; әйтерсең, җанның ике канаты берьюлы сынды да, ул хәзер, имгәнгән кош кебек, үлә алмый җирдә өстерәлеп йөри. Әллә алай түгелме — менә йөрәкнең тамырлары бар икән бит, шулар киселгән шикелле. Ничек тә әллә кайда, әллә нинди бик кирәк, бик төп бер әйбер җимерелепме, сыныпмы төшкән иде.

Әле торып йөри башлаганның өченче көнендә үк каенанасы орышты; чәй янына китерелгән самавырның өстендә көл калган икән, шуны күрсәтеп әйтте: «Ничә ел өйрәтәм, аңгыра сарык кебек, бернәрсә белмисең, шуны сөртеп китергәч нәрсә була!» — ди. Нәрсә булсын, бернәрсә дә булмый, әйбәтрәк кенә була!

Кичә он иләп, камыр басып, икмәкләр салды. Җиде икмәкнең алтысы әйбәт, тигез булып кабарып пештеләр. Берсе култыккарак кереп калган, күчерергә хәтеренә килмәде, менә шуның бер чите әзрәк чиерәк булган. Харап бит, каенана дулый: «Затсыз Саескан, — ди, — үзең белмисең, кеше өйрәткәнне колагыңа элмисең, шулай икмәк пешерәләрме? Адәм түгел, эт тә ашамас бит», — ди.

Гөлбану талашмады, шулай да бу Әремтел каенанага: «Эт ашамаса, син ашарсың! Синең кебек котырган этләргә ярый ул!» — дияргә авызын ачкан иде, Закир килеп керде дә, сүз икенчегә күчте, килен үзенең уйлаганын каенанасына әйтә алмый калды. Ләкин ир белән сөйләшмәде, бер почмакка утырып, ямавын кулына алды да үзенең дөньяга килмәс борын үлгән ике игезәк баласын уйлады. «Ходаем, нигә мин болай бәхетсез яратылдым икән», — диде; күңеле йомшарды, ябык, ярты үлек битеннән эре бөртекле, салкын яшьләр берәм-берәм тәгәрәп төшә башладылар. Балаларга исем дә бирелмәде, җеназа да укылмады, шулай гына илттеләр дә җир астына ялгызларын күмеп кайттылар.

Яшь ана менә шул турыда озак-озак уйлап, акрын гына елап, иске күлмәген ямый бирде. Аннан, тегүен ташлап, тышка чыкты, өйнең баскычында ялгызы

утырды.

Көзге караңгы төн килде. Ерак аяз күк йолдыз белән тулды. Каршы өйнең кыегы өстендә ялгыз ябалак берничә талпынды да тынычланып катты. Тирә-якта тынлык, йокы белән багланган тынлык башланды. Ләкин Гөлбануны ире дә, каенанасы да: «Өйгә кер, йокларга ят!» — дип чакырмады. Башкача сүз әйтүче дә булмады... Шулай йомшак, ләкин бераз шомлы караңгы төн эчендә, ялгыз башын кая куярга белмичә, бер елап, бер әрнеп, озак — бик озак торды.

Бер якка таба да юл күрмәде, кая барып, кемгә киңәш итәргә аптырады; күңеленә үз язмышы белән ни эшләргә белми йөдәгән бичара матур җиңгә Мәфтуха килде, аның белән багланып, күрәзә карчыкны хәтерләде: ни булганын дөрес әйтә, имеш, ди. Кирәксә — сөйдерә, ди, кирәксә — биздерә, ди. Тик бүләгеңне, акчаңны гына кызганма икән, ди.

Мәфтуха барып кайтканнан бирле Гөлбану моңа хәзерләнеп килә иде. Яшерен акча җыйнады. Үзенең иң яхшы бер сөлгесен аерып атап куйды. Болар гына җитмәсә, дип, кичә генә ун йомырка аерып билгеләде.

Өйдә гырылдап йоклыйлар. Хатын, ишек ярыгыннан колак салып, иренең, каенанасының ике урында, икесе дә әлбәттә гырылдавын аерым ачык ишетте. Аяк очы белән генә басып керде. Түрдә стена буенда торган зур сандыкның капкачын күтәрде, билгеле урыннан билгеле сөлгене алды, яшерелгән җитмеш тиен көмеш акчаны эзләп тапты, почмактагы тубалдан ун йомырканы җиңенә салды да, ишекне бик сак ябып, яңадан йортка чыкты.

Вакыты җиттеме, әллә аяк тавышыннан курыктымы, өй кыегындагы ябалак кузгалды, тавышсыз азбарга таба талпынды, кое баганасы өстенә кунды, шуның белән тынычланды.

Хатын, әйберләрен яшерә төшеп, утынлыкка килде, эт-коштан сакланырга бер нечкә имән таяк алды да азбарга, аннан ындырга чыкты. Аннан тыкрык белән курка-курка барып, бер яклы тар урамны кичте, ялгыз торган шомлы ике кара мунчаны үтте. Шулай каушап, калтырап, авылның читенә җитте.

Су буенда, кара мунчадан ерак түгел, ялгыз иске өй. Җимерек чолан. Яртылай җиргә баткан кабык ишек. Хатынга кемдер: «Сихерчегә төн уртасында барырга кирәк, сорап, ишек кагып тормыйча, туры басып керергә кирәк», — дигән иде. Гөлбану шуны хәтерләде; каушап калтырануын җыйды. Ишекнең бавыннан тартты; эленмәгән икән; ни күрсәм дә күрермен дип, барып керде.

Ярты караңгы өй. Ишеккә якын бер җирдә, сәке читендә утырган сукыр яшүсмер малай агып, әйләнеп чыккан куркыныч күз урыннарын моңа таба терәде. Ләкин бер сүз дә әйтмәде.

Сихерче Гайния утырган почмак караңгы иде. Тик аның күптән башланган

сүзен яңа очлаган кеше кебек бер рәвештә, ерактан, түбәннән кысылып килгән тавыш белән алып китте.

— Кайсы бәхетсезе йөри анда?.. Минем җырымның кайгылы җиренә тап килдең ләбаса! Йолдызың каралып бара...

Аяз да гына булса, әй, айга көч,
Болыт та гына булса, көнгә көч;
Кайда гына барсаң, әй, бер кояш,
Күбәләккәй кебек җанга көч, —

дип, моңга катнаш буылу белән күрәзә үзенең җырын кисте, тагы ялгап китте:

— Синең, — диде, — аяк атлап килүеңнең җиле минем миемә сугылды... Болыт килә. Йолдызың каралып бара синең... Бәхетсезлегең зур, кара көнең күп... Атлаган саен сәдака бир, бик күп яр яфрагы яндыр, аяз караңгы төннәрдә якты йолдыз астында утыр... Синең артыңда бер хатын күренә. Яше өлкән, буе зур, йөзе җыерчыклы, кара. Бу — каенанаң булыр. Тагы бер хатын бар. Анысы әле йөзен ачмый... Таный алмыйм, ирең синең өстеңнән көндәш эзли түгелме икән...

Күрәзә карчыкның, караңгы өй эчендә, саташулы тавыш белән әйткән бу сүзләре Гөлбануның хыялын ярып керделәр, миенә кара эз салдылар, йөрәгенә куркулы дулкын китерделәр. Ул ни эшләргә, ничек аңларга белмәде, иң элек сихерчегә үзенең җитмеш тиен акчасын сузды. Гайния моны киез астына тыкты.

— Хәзер дога кылырга ярамый, хәбәрем бүленә, — диде дә тагы алып китте: — Синең, — диде, — күңелеңдә тирән шигең бар. Каенанам сихерләтмәдеме икән, дисең, кемнән икәнен белү авыр. Әмма сихер кулының эзе бар. Иреңнең күңелен синнән суытканнар. Шуннан аның муены анасына таба кыйшаеп каткан... Кайткач кара: күлмәгеңнең инечендә яка буйлап кечкенә, тар бер чүпрәк тегелгән булыр. Шуны сүтеп ал. Эченнән үрдәк җәдәче чыгар, бөтен түгел, кечкенә кисәге генә. Аны ал. Тагы бер дуңгыз кылы чыгар. Аны да ал. Боларны кызган мичкә үзең ягарсың, янып беткәнче күзеңне алма, карап тор. Сихерең тирән. Йортыгызда кое бармы? Шуның сиртмәсен кара... Очырмагызда киселгән тырнаклар, чәчләр сала торган кечкенә капчык бармы? Көл түгә торган урын бармы? Һәммәсен кара. Кызыл чүпрәк булыр, аның эченнән тагын дуңгыз кылы чыгар, үрдәк җәдәче чыгар... Таратмый алырсың, бисмилла әйтми генә тагын утка ягарсың. Янып беткәнче күзеңне алма, карап тор! Сихере каты, озак кайтыр, сабырлы бул; бәхетең каралып бара, йолдызыңны болыт каплый, алда күз яшең күп, сәдаканы күп бир, яр яфрагы яндыр...

Гөлбану, җиңеннән чыгарып, сөлгесен, йомыркаларын бирде, сихерче тагы дога

кылмыйча ук сүзен алып китте:

— Кара юллар берничә яктан үзеңне әйләндереп алалар... Тагы бу ни... Менә тирән яту, аның артында кабер ташлары... Анда ике бала күренә... Чү, болар үләләр түгелме?..

Сихерче күрәзә Гайния шулай сөйләп барганда кинәт ишек ачылды, карчык, куркып, аякка басты, эре җыерчыклар белән капланган карт, кипкән битен ишеккә борды, тирән чокырга баткан тонык күзләре белән шул якка йотылып карады. Гөлбану ни эшләргә белми аптырап катып калды: анда, ишек төбендә, кулына атасы Шибай кантуннан калган иске каеш чыбыркыны тотып, Закир тора. Башы-аягы ялангач, җилкәсендә ак чикмән, йөзе, күзе усалерткыч төсе белән каралып көйгән. Карчыкка бер генә карады, хәзер тиз генә сихерли алмавын күрде дә, ачу белән Гөлбануның чәч толымыннан өстерәп, ишеккә тартты:

— Шулаймы син?! Шулаймы син! Мине сихерләтеп йөрисең икән син, йөзең кара булгыры! — дип, бусагага этәрде, шунда тибеп екты. Каеш чыбыркы белән күлмәкчән хатынны чаж-чож яра башлады. Үзе урысча катнаштырып, ямьсез, кара, пычрак сүгенде. Шулай ярып, алып чыгып китте.

Анасы Сабира Закирга һаман әйтә иде: «Синең хатының сихерче ул. Аның анасы Фәтхия карчык та сихерче. Алар бөтен нәселләре белән сихерче, алар шул сихер белән генә дөньяда торалар, сине шул бозды, агаларың белән араңны шул сихерләп бозды», — ди иде. Егет моңа ышаныр-ышанмас йөрде, кайбер вакыт, йә, шул хатын-кызның әкияте бетмәс инде, дип кул селкә иде. Игез баланың икесе дә үле тугач, ирнең күңелендә бер шом уянды. Гөлбану авырып ятканда, аннан терелеп йөри башлагач, бу шомлану көчәйде, хатынының әллә нинди кызыграк, ярты дивана сымаграк кылануы ирнең шөбһәсен арттырдылар. Кичкә каршы яманган булып почмакта уйланып торуы, аннан соң караңгы төн астында баскыч төбендә ялгызы утыруы Гөлбануның сихерче икәнендә шик калдырмады.

Закир сынарга теләде, белгән догаларын кат-кат укыды, сихердән саклый торган аятелкөрсине туктаусыз кабатлады, йоклаган булып күренер өчен гырылдап ятты. Хатынның, кереп, сандык актаруын, акча, йомырка, сөлге алуларын һәммәсен сизеп торды. Ул сихерче Гайниянең өен белә иде. Кечерәк чакта атка куна киткәндә ул күрәзәнең морҗасына ут кереп йөргәнен үзе дә күргән иде. Бераз каушады, сихеренә эләксәм, авызым чалышайса, кул-аякларым тартышса ни эшләрмен дип куркынды; шулай да чыдамады, баш-аягына кимәстән, өстенә чикмән генә салды да, бер кулына каеш чыбыркы, икенчесенә зур казык алып, күрә-күрә генә Гөлбану артыннан китте. Башы

әйләнде, йөрәге сукты, мунчалар янында, шикләнеп, кире кайта язды; юк, һаман да барды, ишектән аз гына тыңлады да, аятелкөрси укып, басып керде.

Керү белән шиге-шөбһәсе бетте, анасының сүзләре дөрес: аның хатыны Гөлбану сихерче икән, дөньяны шул бозган икән, абзасы Алтынбайлар белән дә, апалары Хәернисалар белән дә шул Гөлбану сихерләп бозыштырган икән.

Бу уйлар берьюлы аның башын каплады, күзен караңгылык басты, чыбыркы сугуына туймады, битен-башын кочаклап бөтәрләнеп егылган Гөлбануның йөрәген, күкрәген аяк белән таптап изәргә омтылды.

Шулай юл буенча изеп, кыйнап, чыбыркылап алып кайтты да өйнең идәненә, сәке буена ташлады; үзе, арып, ахылдап, җәюле урынына менеп ауды. Уффф... итеп түшәккә капланды да саташулы авыр йокыга чумды.

Гөлбану идәндә җаны-тәне белән әрнеп озак ятты. Башында тик бер нәрсә генә әйләнде: «Илаһым хуҗам, нигә мине болай азаплыйсың?! Нигә минем җанымны алмыйсың?!» — диде.

Күрәзәнең сүзе йөрәгендә кара канлы агу белән катып торды. Кая гына атласа да, кемгә генә барса да, ничек кенә күз яше түксә дә, якты чырай тапмас кебек булды, һәммәсе, һәммә нәрсә бәхетсезлек белән капланды; йолдыз каралды, кара көн басып килде.

Ватылган тәнен кыенлык белән күтәрде. Башына иске кара шәлен ябынды, туачак балага дип алдан теккән кечкенә күлмәк кисәген алды да йортка чыкты.

Болытлар түбәннәр. Җил исә. Төн караңгы. Тик бикерактан гына, болыт арасыннан таңга ошаган бер якты бар кебек.

Гөлбану таягын алды, кара шәленә ныграк төренде дә тыкрыктан тар урамга төште; аннан Үзән елга буйлап, тегермән буасы аша Караюрга ягына юнәлде.

## XXXV

Балалар су буеннан куркышып кайттылар. Капкадан керер-кермәс, елашып:

— Нурый бабай, Нурый бабай, тизрәк бул!.. Анда басмага әллә нәрсә килеп эләкте... — дип акырыштылар.

Бу айларда картның күңеле борчулы иде. Игез балаларның үле туулары аның күңеленә бер шом биргән иде. Төшләре дә яман булды. Сәдака биреп карады, кергән хәерчеләрне икмәкме-онмы бирмичә чыгармады. Ләкин һаман да күңеле тынычланып җитмәде.

Шундый билгесез шомнар эчендә торган чакта маланларның килеп кычкырулары аның йөрәген алды, башын томалап җибәрде.

— Ходаем, шулдыр, тәкъдирем килеп җиткәндер, — дип, кулына тоткан сәнәген ташлады да кибәннәр, саламнар арасыннан Үзән елгага, басмага таба йөгерде. Үзе бертуктаусыз карт, калтыраган тавыш белән: — Ходаем, шулдыр,

тәкъдирем килеп тоткандыр, — дигән сүзләрне кабатлап, билгесез борчу эчендә барды.

Атаның йөрәге ялгышмады.

Нурый барып җиткәндә, басмадан аз тына югары, кара ятуның текә яры өстендә әллә ничаклы ирләр, хатыннар җыелганнар иде. Һәммәсенең йөзендә аптырау катнаш бер борчу бар иде. Карт берәүгә дә карамады, атылган кебек омтылып килде. Аңа, икегә аерылып, юл бирделәр. Ул:

— Ходаем, бу нихәл? — диде дә, Үзән елганың тирән ятуыннан әле яңа чыгарылып, яр башына сузып салынган хатынның балчыклы, сулы гәүдәсе өстенә: — Балам, Гөлбанукаем! — дип ташланды. Үбә дә алмады, кочакларга да кулы бармады, тезләнеп, йөрәген, кулын ашыгып тотты, күзләренә карады, ләкин җан әсәре тапмады.

Шул минутта ук, кайгы хәбәрен ишетеп, ана карчык Фәтхия килеп җитте. Үксеп, күз яшенә капланып, кызының үлек гәүдәсен кочаклады. Тышка калкып каткан күзләрен йомдырырга тырышты. Яңгырга, салкын һавага карамастан, өстендәге бишмәтен салды да Гөлбану тәненә каплады.

Хәбәр тиз таралды. Күзләре кызарып, елап, үксеп, матур җиңгә Мәфтуха килеп төште. Аның артыннан назлы килен Гыйззелбәнат, Төхфәтнең хатыны усал тел килен Мәрфуга, аларга ияреп бергә үскән кызлар, яшь киленнәр, иң азактан арып, ахылдап, үзенең челеме белән төтенләп, коры сызлаудан хәлсезләнгән аякларын чак кузгата-кузгата Шәвәли карт, тагы бераз ирләр, бабайлар килделәр.

Үлекне хәзер үк өйгә кайтармадылар. Хөкем килер, карарлар, ансыз, табылган урыннан күчерергә ярамый, диделәр. Авылдан кизүләп каравыл куйдылар.

Фәтхия берничә сәгатьтән ун еллык картайды, күзләре әллә кая эчкә батып, кайгы белән тулдылар. Йөзе, тагы да ныграк җыерчыкланып, тиресенә батып кипте. Ниндидер үле сары төс чыкты. Карчык эшен, дөньясын онытты. Хөкем килгәнче үткән дүрт тәүлектә кызының үлеге яныннан китмәде, иртә-кич, төн-көн шунда булды, шуның янында күз яше түкте.

Бишенче көндә доктор, урядник, хөкем иясе килеп җавап алдылар. Яздылар. Шуннан соң гына күмәргә рөхсәт бирделәр.

Башта бик зур аптыраш чыкты:

— Үзенә-үзе кул салган кеше мордар китә, дөньядан имансыз үтә, мәңге тамуглык була, — диделәр.

«Мондыйларга җеназа укырга ярамый, мөселман каберлегенә куярга да ярамый», — дигән сүз китте. Челем бабай Шәвәли гаҗәпләнеп карады:

— Сез нәрсә? Кешегә үлгәч тә тынычлык бирмәскә әйтәсезме? — диде.

Бу сүзнең мәгънәсен, бабай нәрсә әйтергә теләгәнен берәү дә аңламады. Тик мәзин генә моны яклады:

— Картныкы дөрес! Күрәсе газабын күргән бит инде, җитмиме? — диде.

Бу сүзне дә аңламадылар. Ләкин болай да яр башында дүрт көн кабер көтеп яткан үлекне кайда да булса, ничек тә булса күмәргә, әлбәттә, кирәк иде. Балалар да курка башлады. Карчыклар өрәк турында, төнлә морҗа аркылы кереп йөри торган утлар турында сөйләнергә керештеләр.

Эшнең төбе Шәрип ахунга барып терәлде. Ул ни эшләргә дә кыенсынды, үзен ике ут арасында күрде: үзен-үзе суга ташлаган бу бичара хатын үлеген җеназа укып мөэмин-мөселман каберлегенә күмсә, Алладан курыкты, баш тартса, мәхәлләсенең зур карты һәм гомер буенча гошерен, сәдакасын алып килгән Нурмөхәммәттән курыкты. Ахыр бер якка да ята алмады, юк эшне бар итеп:

— Мине мөфти чакырткан, шуңа барам, — дип, калага сызды.

Ул киткәч эш Фәйзулла мәзин кулына калды; бу бик нечкәләп торырга яратмый иде, Нурыйга туры әйтте:

— Гөнаһны өстемә йөклим. Фидиягә ат бирерсең, җеназа өчен ун сум сәдака итәрсең, — диде.

Карт крестьянның күз алды караңгыланып китте, тез буыннары йомшарды, калтыраган тавыш белән:

— Чү, мәзин, син ни сөйлисең? Бер ат белән ун сум акча! Моны кайда ишеткәнең бар? — дип, Фәйзулланың күзләренә ялынып, бераз кимет дип карады.

Ләкин мәзин киметмәде, карт крестьян, бугазына пычак ышкып, малын талаганга ошаш хәлдә, аның сораганын бирде. Үзе эчтән ватылды, гомере кимеп барадыр кебек сизенде.

Гөлбану үлеме — аңа да хәбәрдер, әҗәл киләдер, газраил шунда, югарыда сагалап йөри торгандыр, дип уйлады. Кемгә җәбер иттем икән, кемнең хакын алдым, кемнең тиярен кыстым икән дип, йокы арасында саташып бетте. Барын да бәхилләтергә күңелен беркетте.

Шул җеназа мәшәкатьләре белән кайнаганда Челем карт Шәвәлине атап эзләп күрде:

— Син, кода, — диде, — минем Шәйхелгә хәбәр җибәр. Кайтсын, фатыйха да бирәм, бер имана белән кечкенә өемне дә бирәм. Җитәр, күп йөрде. Оя корыр, мин үлгәч артымнан догачы булыр, — диде. — Алда кыямәт бар, Алла каршында җавап бирәсе бар бит, — дип өстәде.

Шәвәли, челемен төтенләтеп, озак дәшми торды, аннан гына авыз ачты:

— Синең сүзгә ышаныч бармы? Мин кайтарырмын, син тагы куарсың, — диде.

Нурый эчке әрнү белән, йөрәк белән кисеп әйтте:

— Юк. Алай димә. Хәзер кумам, кайтсын, фатыйха да бирәм, җир өлешен дә бирәм, — диде.

Җеназага бөтен Караюрга җыйналды. Бикьярдан Хәерниса белән теге ике бала — кечкенә кыз Фагыйлә белән малай Миңлегалим килгәннәр иде. Болар, елашып, шешенеп беткәннәр. Сүзләрен әйтә алмыйлар.

Күмәргә килгән халык, кара болыт кебек булып, бөтен каберлекне каплап алды. Кызу яңгырга карамастан, һәммәсе Гөлбануга актык сәламнәрен бирергә агылдылар.

Телләрдән «бичара» дигән, «әрәм булды» дигән сүз төшмәде; туктаусыз яңгыр астында, кичкә каршы Гөлбануны гүргә куйдылар.

Караңгы төште. Яңгыр кызуланды. Җәй көне кибә төшкән Үзән елга көзнең бу бай яңгырлары белән ярларга күтәрелде; шул төнне Бикьяр белән Караюрга арасындагы тегермәннең бөясен[1] ерып алып китте.

1909-1929

[1] *Бөясен* - буасын